ХАТ ӘЗЕННӘН

Киров авылы халкы начар истән зарлана

> 5

ВАТАН ӨЧЕН!

Россия Герое Рөстәм Сәйфуллинның тормыш сәхифәләре

> 16



СӘХНӘСЕЗ ИҖАТ

Татарстанның иң зур ансамбле игътибар көтә

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 186 (28959) | Җомга | 16 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

КИЕМЕҢӘ КАРАП...

ЧИТ ИЛ БРЕНДЛАРЫН КЕМ АЛМАШТЫРЫР?

Сыйфатлы да, арзан да күлмәк-чалбар каян сатып аласы? Дөньядагы хәлләрдән башлары әйләнгән чит ил кибетләре ябылып беткәннән соң, илдә яшәүчеләр арасында әнә шул сорау «көн кадагы»нда тора. Нәрсә киярбезʔ Республика җитештерүчеләре ни хәлдә? «ВТ» хәбәрчесе әлеге сорауларга җавап эзләде.

> 6

Ишетми калмагыз

Татарстанда, сулыш юлларын зарарлаучы вируслы авырулар (ОРВИ) һәм грипп йоктыручылар саны нык күбәю сәбәпле, кайбер чикләүләр кертелгән. Роспотребнадзор идарәсе мәгълүматларына караганда, республикада ОРВИ һәм грипп белән чирләүчеләр саны эпидемия баскычыннан (чирләүчеләр саны төбәктә яшәүчеләрнең 5 процентыннан артса, эпидемия баскычын узган булып санала) 82 процентка арткан. Грипп йоктыруның 198 очрагы теркәлгән, шуның 92 проценты дуңгыз гриппына туры килә.

Карар нигезендә, хастаханәләргә сырхаулар янына кертмәячәкләр (авыр хәлдәге якыннарын караучылардан тыш). Шулай ук тәүлек әйләнәсе эшләүче социаль һәм мәгариф учреждениеләренә (балалар приютлары, интернат-йортлар һ.б.) юлны ябачаклар. Барлык медицина оешмаларына мәҗбүри битлек режимы кертелә. Тәүлек әйләнәсе эшләүче учреждениеләрнең хезмәткәрләренә дә битлектән йөрү таләп ителә. Моннан тыш хастаханәләрдә, приютлар һәм мәктәпләрдә (тәүлек әйләнәсе эшли торган) тән температурасын көненә ике тапкыр үлчәү мәҗбүри итеп куела. Балаларның 20 проценттан артыграгы чирләгән очракта, мәктәпләр һәм балалар бакчаларында укыту-тәрбия эшләре туктатылып торачак.

Быел Татарстан «Агросәнәгать комплексы продукциясен экспортка җибәрү» федераль проекты кысасында барлыгы 313 миллион долларлык азык-төлек саткан. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Наил Залаков әйтүенчә, 2022 елда республика алдына барлыгы 330 миллион долларлык продукцияне чит илләргә сату бурычы куелган булган. Әмма ашлыкны, шикәр комы, үсемлек маен экспортлауга чикләүләр кертелү, дустанә булмаган илләрнең хезмәттәшлектән баш тартуы, логистиканың катлаулануы сәбәпле, максатчан күрсәткеч алынган. Ләкин министрлык экспорт буенча эшне дәвам итеп, шундый зур күрсәткечкә ирешкән.

Россия Мәгърифәт министрлыгы һәм Рособрнадзор 2023 елга бердәм дәүләт имтиханы расписаниесен раслаган. БДИ тапшыруның төп чоры итеп 26 майдан 20 июньгә кадәрге чор билгеләнгән. Шулай итеп, чыгарылыш сыйныф укучылары 26 майда – география, химия, рус әдәбияты, 29 майда – рус теле, 1 июньдә – математика, 5 июньдә – тарих, физика, 8 июньдә – җәмгыять белеме, 13 июньдә – чит телләр, биология, 16–17 июньдә – чит телләр (телдән), 19–20 июньдә информатика буенча имтихан тапшырачак.

Иртәгә Татарстанда кар-буран, якшәмбе көнне бозлы яңгыр көтелә. Гидрометеоүзәк фаразына караганда, шимбә – 17 декабрьдә көндез –1...–6, төнлә –5...–10 градус салкын. Якшәмбе – 18 декабрьдә республикага бик җылы һәм дымлы һава үтеп кергәнлектән, һава торышы нык бозылачак: юеш кар, бозлы яңгыр, урыны белән көчле яңгыр. Дүшәмбе – 19 декабрьдә явым-төшем акрынлап туктаячак. –6...–11 градуска кадәр салкынайта. Башлангыч фараз буенча, 20 декабрьдә һава температурасы көндез –8...–13, төнлә –13...–18 градус чикләрендә тирбәләчәк.

КАИга – 90

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин КНИТУ-КАИ ветераннарын һәм укытучыларын, әлеге уку йортын тәмамлап чыгучылар һәм студентларны вузның 90 еллыгы белән котлады. Юбилей уңаеннан Казан илкүләм тикшеренү-техник университетында гыйльми һәм попечительләр советларының тантаналы утырышы узды.

– Вузның 90 еллык тарихында бик күп эш башкарылган, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Әмма иң мөһиме – яңаны булдыру юлында ныклы традицияләр салынган. КАИ кебек төп югары уку йортлары күпкырлы икътисадыбызның, зур фәнни казанышлар таләп итүче, көндәшлеккә сәләтле производстволарыбызны үстерү нигезе булып тора.

КАИның күренекле галимнәре арасында – Сергей Королев, Николай Четаев, Валентин Глушко, Хәмид Мөштәри һ.б. Югары уку йорты авиация сәнәгате һәм халык хуҗалыгының башка төп тармаклары өчен 110 меңнән артыграк инженер әзерләгән. Вузны тәмамлаучылар арасында 30дан артыграк кеше Советлар Союзы, Россия һәм Социалистик Хезмәт Геройлары исеменә лаек булган. Югары уку йорты инженерлар әзерләүдәге һәм фәнни тикшеренүләрне үстерүдәге казанышлары өчен Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Халыклар Дуслыгы орденнары белән бүләкләнгән.

Хәзерге вакытта биредә 200дән артыграк юнәлеш буенча Россиядән, якын һәм ерак чит илләрдән 13 меңнән артыграк студент белем ала. Аларга 900дән күбрәк укытучы белем бирә. Югары уку йортында аталкы фәнни мәктәпләр булдырылган. Үзенең конструкторлык бинасы эшләп килә. Университет пилотлы һәм пилотсыз авиация буенча илнең стратегик яктан әһәмиятле проектларында катнаша.

Фәрит Мөхәммәтшин вузның актив тикшеренү эшчәнлеге алып баручы профессорлары һәм укытучыларына дәүләт бүләкләре тапшырды. КНИТУ-КАИ коллективы Россия Президенты Рәхмәтенә лаек булды.

Хәзерге вакытта университет составына 5 институт һәм 1 факультет: Авиация, җир өсте транспорты һәм энергетика институты; Автоматика һәм электрон приборлар төзү институты; Компьютер технологияләре һәм мәгълүматны саклау институты; Радиоэлектроника, фотоника һәм цифрлы технологияләр институты; Инженер икътисады һәм эшмәкәрлек институты; физика-математика факультеты керә. Вузның Әлмәттә, Яшел Үзән, Лениногорск, Чаллы һәм Чистайда 5 филиалы эшләп килә.

ЗУР ЭШНЕҢ БАШЫ

tatarstan.ru

«Ислам хезмәттәшлеге оешмасының Яшьләр форумы» халыкара оешмасы президенты Таха Айхан белән Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та очрашты. Сөйләшү барышында хезмәттәшлекне ныгыту, оешма кысаларында эшлекле элемтәләрне җайга салу мәсьәләләре каралды.

Төрле телдә сөйләшсәләр дә, дуслык телендә аңлашалар. Казанда «Ислам хезмәттәшлеге оешмасының Яшьләр башкаласы» программасы кысасында еллык чараларга нәтиҗә ясалды. Дистәләгән илдән килгән фикердәшләр, бер казанда кайнап, нәрсәгә ирешкән?

Хәтердә яңартып үтик: 2021 елда Ислам хезмәттәшлеге оешмасының яшьләр форумы идарәсе утырышында Казанга «Ислам хезмәттәшлеге оешмасының Яшьләр башкаласы – 2022» исемен бирү турында карар кабул ителгән иде. Бер ел дәвамында Татарстан башкаласы шушы статуста эшчәнлек алып барды.

Татарстанның яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов сүзләренчә, Казан әлеге мәртәбәле статуста халыкара мөнәсәбәтләрне тагын да ныгытты.

– Бу елның төп нәтиҗәсе – фән һәм мәгариф, иҗат һәм сәнгать, эшмәкәрлек, киберспорт, дипломатия һәм башка юнәлешләр буенча Татарстан, Россия һәм ислам дөньясында мөнәсәбәтләрне ныгыту, – диде ул елны йомгаклау чарасы кысасында узган «түгәрәк өстәл»дә.

Сан теленә күчсәк, «Ислам хезмәттәшлеге оешмасының Яшьләр башкаласы исеме» астында 10лап зур чара оештырган. Әйтик, Коръән уку ярышы, яшьләр өчен глобаль саммит, форум-очрашулар, белем бирү чаралары.

Тимур Сөләйманов билгеләп үткәнчә, бу елның чараларында катнашырга 136 ил гариза биргән. Казанга 70 илнең вәкилләре килгән. Аның сүзләренчә, хәзерге сәяси шартларда быелгы чараның кыйммәте аннан калачак мираста һәм күтәрелгән мәсьәләләрдә чагыла.

«Түгәрәк өстәл» барышында Казан мэры Илсур Метшин да катнашты. Ул да ислам дөньясы илләренә рәхмәтен әйтте.

– Хәзерге сәяси шартларда сез безгә каршы чикләүләргә кушылмыйсыз, киресенчә, илебез белән эшлекле фикер алышу юлын сайлыйсыз. Бу сөенечле. Халыкара вазгыять кысасында борчыган сорауларны уртага салып сөйләшү мөмкинлеге булу безнең өчен бик кадерле, – диде шәһәр мэры.

Елны бүләкләр белән озаталар. Чара кысасында «Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең яшь лидерлары» премиясен тапшыру тантанасы да булды. 7 номинациядә (фото, медиа, эшмәкәрлек, тикшеренү, спорт, сәнгать, мәдәният) дистәләгән ил вәкиле ярышты.

УРТАГА САЛЫП СӨЙЛӘШҮ

Берләшү әһәмияте, мәгълүмат чараларына ышаныч, илдән киткәннәр турында уйлану. Татарстан Президенты Мәскәүдә кайчандыр республикада туып-үскән, эшләгән, укыган журналистлар белән очрашты. Бу очрашу Татарстанның Россиядәге Тулы вәкаләтле вәкиллеге каршындагы медиаклуб утырышы кысасында узды.

«Российская газета» баш мөхәррире Владислав Фронин мәгълүмати һөҗүм турында һәм бу көрәштә журналистларның роле турында сөйләде. «Үзебез үк Россиягә каршы мәгълүмати сугыш ачуларын тойдык. Бу – яңача сугыш. Сүз, сурәт, фото – куркыныч корал. Мондый шартларда журналистларга да яңача эшләргә туры килә», – дигән фикердә ул.

Нишләргә дигән сорауга да җавапны әйтте баш мөхәррир.

– Тышкы басымның максаты – җәмгыятьне эчтән таркатырга омтылу, шуңа күрә бер территориядә яшәүче дин, мәдәният һәм халыклар арасында җанлы һәм туры диалог кору мөһим, – диде Владислав Фронин.

«Татмедиа» агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәраев тә хәзерге шартларда мәгълүмат чараларының нинди әһәмияткә ия булуларына тукталды. Җитәкче әйтүенчә, блогерлар белән журналистика арасындагы чик сызыла, шулай да дәүләт басмаларының ихтыяҗы да арта. Соңгы елларда ил-көн кичергән вакыйгалар халыкның тикшерелгән, дөрес мәгълүматка сусавын күрсәтте дә бит. Айдар Сәлимгәраев билгеләп үткәнчә, бүгенге укучыны тегe яисә бу вакыйгага карата автор фикере кызыксындыра.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та илдә барган вакыйгаларга, мәгълүмат чаралары эшчәнлегенә карата үз фикерен белдерде.

Президент искәрткәнчә, намуслы һәм ышанычлы мәгълүмат чаралары Россиягә каршы ялган мәгълүмати һөҗүм белән көрәштә аеруча әһәмияткә ия.

– Фейк, мәгълүмати һөҗүмнәр бик күп. Россиягә каршы көрәш бара, бу бик начар. Бу – Россия белән аңа каршы булган кешеләр арасындагы көрәш. Украинадан файдаланалар, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент сүзләренчә, әлеге вакыйгалар республикага үз көчен бәяләргә дә мөмкинлек биргән.

– Без импортны алмаштыру җәһәтеннән нинди проблемалар барлыгын аңладык. Кем безгә хезмәттәш, ә кем юк икәнен белдек. Барысын да узарбыз. Бу катлаулы чорда без бердәм, ватанпәрвәр булырга тиеш. Әгәр дә без зарлансак һәм кемнедер мыскыл итсәк, бернәрсә дә барып чыкмас. Бу җиңүгә һәркем үз өлешен кертергә тиеш. Җиңү булыр, башка юл юк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Республика Президенты билгеләп үткәнчә, Татарстан үсешен дәвам итә, барлык тармакларның күрсәткечләре дә үтәлә. «Киләсе ел да авыр, ләкин уңышлы булырга тиеш дип ышанам. Илебез чәчәк атсын өчен тырышачакбыз. Бездән башка беркем дә безне бәхетле итмәс. Республика, зур Россия файдасына эшләячәкбез», – диде Татарстан Президенты.

Мәскәүдә бу көнне Татарстан Мәдәният министрлыгы белән Дәүләт Третьяков галереясы арасында хезмәттәшлек турында килешү имзаланды. Документ республика белән илнең иң зур музейларының берсе арасында мәдәни өлкәдә хезмәттәшлекне киңәйтү юнәлешендә план булып тора.

ХАЛЫККА ЯКЫНАЮ

Дәүләт оешмалары социаль челтәрләргә күчәчәк, ә таганнан егылып имгәнгән өчен җаваплылыкны көчәйтәчәкләр. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин җитәкчелегендә узган утыз сигезенче утырышта яңгыраган мәсьәләләрнең кайберләре генә бу. Сессия эшендә Президент Рөстәм Миңнехановта катнашты.

Президиум утырышының көн тәртибенә 14 мәсьәлә тәкъдим ителгән иде, шул исәптән алтысы – республика законнары проекты, бер федераль закон проекты һәм Оренбург өлкәсе закон чыгару җыелышының закон чыгару тәкъдиме. Республика законнарының барлык алты проекты да беренче укылышта каралды.

Тик көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләрне карауга керешкәнче, Татарстан Конституциясе суды рәисе Фәрхәт Хөснетдинов үзенә сүз бирүләрен сорады. Ул яңа гына махсус операция зонасыннан кайткан икән. Яу кырындагы якташларыбызга гуманитар ярдәм алып барганнар.

– Татарстанда яшәүчеләр хәрби операция башланганнан бирле мобилизациягә эләккән солдатларга, Украина халкына даими ярдәм күрсәтә. Бу солдатларга шул исәптән ике машина да алып барып бирдек, – дип сөйләде ул. Яу кырыннан сәлам да алып кайтканнар.

Дәүләт Советы депутаты Эдуард Шәрәфиев, билгеле булганча, үз теләге белән махсус операциядә катнаша. Ул видеоязма төшереп җибәргән. «Махсус операциядә катнашучыларга һәм тыныч халыкка ярдәм күрсәткәннәре өчен Татарстан Президентына, республика җитәкчелегенә, бөтен халыкка рәхмәтебезне белдерәбез. Без тынычлык мөмкин кадәр тизрәк урнашсын өчен хәлдән килгәннең барысын да эшләячәкбез», – диде Эдуард Шәрәфиев. Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстаннан мобилизациягә киткән солдатларга, аларның гаиләләренә, Россиянең яңа төбәкләрендә яшәүчеләргә алга таба да бергәләп ярдәм күрсәтик, дип мөрәҗәгать итте.

Татарстандагы барлык хакимият органнары һәм аларга караган оешмаларның социаль челтәрләрдә үз сәхифәләре барлыкка киләчәк. Хәтерләсәгез, ил күләмендә түрәләргә мондый таләпне бу җәйдә Россия Президенты Владимир Путин куйды. Гади халык хакимият органнарының эшчәнлеге турында белеп торсын, дип тә әйтте илбашы ул чакта. Моның өчен ил күләмендә техник мөмкинлекләрне җайга салып бетергәннәр. Чират – сүзне канунлаштыруда.

Татарстанның цифрлы үсеш, дәүләт идарәсе, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин сүзләренә караганда, республика законын быелның 1 декабрендә үз көченә кергән шундый ук эчтәлектәге федераль законга туры китерәчәкләр.

– Татарстан Дәүләт хакимияте органнары бердәм порталы 1 меңнән артык рәсми сайтны берләштерә. Былтыр порталга керүчеләр саны 80 миллионнан да артып киткән. Республикадагы 5500гә якын оешманың, ә бу – гомуми санның 93 проценты, социаль челтәрләрдә үз сәхифәләре бар инде, – диде министр.

Шунысы да бар: ил хакимияте карары нигезендә, дәүләт органнарына «ВКонтакте» һәм «Одноклассники» социаль челтәрләрендә генә сәхифәләр ачарга ярый. «Ә интернет белән дус булмаган өлкән яшьтәгеләргә нишләргә? Алар кирәкле мәгълүматны социаль челтәрләрдән эзләп таба алмаячак», – дип тә кызыксындылар Айрат Хәйруллиннан. «Бу – өстәмә мәгълүмат чыганагы гына», – дип тынычландырды депутатларны министр. Закон проекты беренче укылышта һәм тулаем кабул ителде.

Таган, карусель ише аттракционнарның техник торышы һәм аларны куллану өлкәсендә дә контрольне көчәйтергә җыеналар. Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсе башлыгы урынбасары Мөнир Халиков сүзләренә караганда, балалар арасында аттракционнан егылып имгәнү очраклары күп. «Бу өлкәне тикшереп торучылар болай да җитәрлек, Прокуратура да, полиция дә бар. Ике кеше пешерсә, аш тозсыз була, дигәндәй, эшнең киресе килеп чыкмасмы?» – дип борчылды депутатлар. Мөнир Халиков төгәл генә җавап бирә алмады. «Аттракцион» атамасына төгәл нәрсәләр керүен дә ачыклап бетерергә туры киләчәк. Закон проектын беренче укылышта һәм тулаем кабул иттеләр.

Билгеле булганча, ел азагында ил төбәкләрендә Конституция судлары юкка чыгарылачак. Бу уңайдан Дәүләт Советы Рәисе борчылуын да яшермәде. «Төбәкләрдә бу хакта зур кызгану хисе белән сөйлиләр. Әлеге юнәлештә бик җитди эш алып бардык, әмма федераль үзәк тарафыннан карар кабул ителде», – диде ул. Аның әйтүенчә, алга таба хокук саклау органнарына, гомуми юрисдикция судларына, Прокуратурага эш артачак. «Бөтен кеше дә, үз хокукларын яклап, Санкт-Петербургка, Зорькин (РФ Конституция суды рәисе Константин Зорькин. – **Ред.**) янына чыгып китә алмый», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Утырыш ахырында кабат ватанпәрвәрлек турында сөйләшүгә әйләнеп кайттылар. КПРФның Татарстан бүлеге җитәкчесе Хафиз Миргалимов Чаллыда шәхси мәктәптә Иосиф Сталинга һәйкәл ачу тирәсендә купкан шау-шуны туктатуларын сорады. «Бу хакта нәрсә генә сөйләмиләр. Мәктәпнең лицензиясен дә тикшерә башлаганнар ди инде», – дип ачынып сөйләде ул. Министрларга, Чаллы мэрына мөрәҗәгать итеп, тарихтан курыкмаска өндәде депутат.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларын раслау турында

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм**:

1. Түбәндәге затларны Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары итеп расларга:

Баһаутдинова Наилә Гомәр кызы – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Идарә, икътисад һәм финанслар институты директоры;

Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызы – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе;

Вәлиева Әлфия Фуат кызы – «АК БАРС СОЗИДАНИЕ» хәйрия фонды директоры;

Гайнетдинов Азат Галимҗан улы – «Социаль яраклашуга һәм хокукларны торгызуга ярдәм итү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры;

Гафиятуллин Мөнир Минхәйдәр улы – «Спорткультавтотовары» акционер җәмгыяте генераль директоры;

Кабыш Евгений Григорьевич – «Әфганстан ветераннарының Россия берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан республика оешмасы рәисе;

Какохо Тимур Геннадиевич – «Россия юристлар ассоциациясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе Башкарма комитеты рәисе;

Крюкова Мария Викторовна – «Татарстан Республикасы яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең «УРАМ» яшьләр экстрим-паркы директоры;

Мөбарәкшина Анна Вячеславовна – «Без бергә» авыр тормыш шартларында калган кешеләргә ярдәм итү фонды директоры, «Медиклар-волонтерлар» бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан төбәк бүлекчәсе төбәк координаторы;

Патеев Ринат Фаикъ улы – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесенең «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Исламны өйрәнү үзәге» аерымланган структур бүлекчәсе директоры;

Сабитова Наталья Михайловна – «Татарстан Республикасының мордва милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе;

Самойленко Владимир Михайлович – «Рус Православие Чиркәвенең Казан епархиясе Казан православие дини семинариясе» дини оешмасы – дини югары белем бирү мәгариф оешмасы ректоры;

Скобельцына Елена Германовна – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф югары белем бирү учреждениесенең «Н.И. Лобачевский исемендәге лицей» гомуми белем бирү мәктәп-интернаты директоры;

Софронов Алексей Николаевич – Татарстан Республикасының «Универсаль көрәш» спорт федерациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасы төбәк бүлекчәсе президенты;

Тимирясова Асия Виталий кызы – «В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесе ректоры;

Фәтхуллина Эльмира Вадимовна – «Россия Федерациясе Театр әһелләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте)» гомумроссия иҗтимагый оешмасы бүлекчәсе – Татарстан Республикасы Театр әһелләре берлеге рәисе урынбасары;

Хәсәнов Илфар хәзрәт (Хәсәнов Илфар Ренат улы) – Татарстан Республикасы мөфтиенең беренче урынбасары;

Шакиров Данис Фәнис улы – «Бөтендөнья татар конгрессы» төбәкара иҗтимагый оешмасы Башкарма комитеты рәисе;

Шакирҗанов Рафаэль Мәҗит улы – «МЭЛТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең тышкы икътисадый эшчәнлек буенча киңәшчесе;

Яруллин Тәбрис Мөдәррис улы – «Татарстан Республикасының Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры урынбасары.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 15 декабрь, № ПУ-877

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларын раслау турында

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 159 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары итеп түбәндәге затларны расларга:

Александровская Ирина Алексеевна –	Казан шәһәре Совет районының «93 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры
Әхмәтова Әдилә Марат кызы –	«Казан ачык талантлар университеты 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасы башкарма директоры вазыйфаларын башкаручы
Әхмәтова Ирина Гәрәй кызы –	«Казан дәүләт энергетика университеты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең үсеш һәм инновацияләр буенча проректоры
Бикмуллин Тимур Альберт улы –	Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Республика клиник хастаханәсенең нейрохирургия бүлеге мөдире
Габдрахманов Фәнил Исхак улы –	«МАОТ» укыту-методика үзәге» өстәмә һөнәри белем бирү автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры
Исаева Анастасия Георгиевна –	Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары
Кадыйров Тимур Рәфкать улы –	«Татарстан Халыклар дуслыгы йорты» дәүләт бюджет учреждениесенең балалар һәм яшьләр белән эшләү бүлеге мөдире, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре Ассамблеясы каршындагы Татарстан халыклары яшьләр Ассамблеясы» региональ яшьләр иҗтимагый оешмасы советы рәисе
Камалетдинов Тимур Ренат улы –	«Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләренең республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры
Кузнецов Артем Викторович –	«Энергия» фәнни-җитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, «Татарстан Республикасының күпбалалы гаиләләре» региональ иҗтимагый оешмасы рәисе, «Казан дәүләт энергетика университеты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең Дәүләт имтиханнары комиссиясе рәисе
Мостаев Артур Ратнер улы –	«Карадуган» үреп ясалган җиһаз фабрикасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры, «БрусчаткаПремиум» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры, «ТатарМастер» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры
Мостафина Фәйрүзә Зөфәр кызы –	«Менеджмент академиясе» өстәмә һөнәри белем бирү автоном коммерциячел булмаган оешмасының беренче проректоры
Нургалиева Розалия Миргалим кызы –	«Татарстан Республикасы дәүләт сынлы сәнгать музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры
Расческова Лариса Владимировна –	«Халыкның сәламәтлеген саклау һәм социаль тискәре күренешләрне булдырмау өлкәсендә профилактика һәм инициатива» Татарстан Республикасы региональ иҗтимагый оешмасының проектлар координаторы
Романов Дмитрий Сергеевич –	«Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә җәмәгать контроле региональ үзәге» ассоциациясе башкарма директоры, «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең «Муниципаль менеджмент» кафедрасы өлкән укытучысы
Сәгетдинов Айдар Фаит улы –	«Татэнерго» акционер җәмгыяте Стратегик үсеш һәм инвестицияләрне гамәлгә ашыру идарәсенең инвестиция программаларын гамәлгә ашыру бүлеге баш белгече, «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмалары яшьләр берлеге» региональ иҗтимагый оешмасы советы рәисе
Туманов Дмитрий Александрович –	«Созвездие – Йолдызлык» Татарстан Республикасы региональ яшьләр иҗтимагый оешмасы генераль директоры
Федорова Тамара Трофимовна –	«ТИСБИ» колледжы» һөнәри белем бирү учреждениесе директоры
Шувалова Диләрә Даниял кызы –	«Татарстан Республикасы аграр яшьләр берләшмәсе» региональ иҗтимагый оешмасы рәисе
Шулаев Алексей Владимирович –	Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең гомуми гигиена кафедрасы мөдире
Юнусов Зөфәр Зәкиулла улы –	«Эко-Агент» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 15 декабре. № 1722-IV ДС

Әйтеп кенә бактым

«Папаша»

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Шифаханәләргә 72 яшь тулгач кына йөри башладым. Кайчак, күп нәрсә югалтканмын икән, дип тә уйлап куям.

Менә хәзер «Васильевский» дигәнендә ял итеп ятыш. Әлбәттә, хатыным белән. Минем яшьтәгеләрнең барысы да диярлек парлы монда, чөнки «Курортный роман» геройлары булу яшеннән уздык инде. Бер язучы дустым: «Курорт романнары хатын-кыз аягы белән языла», – дигән иде. Бу сүзләрнең мәгънәсен аңлаган кеше аңлар. Хәзер төп таянычыбыз, мәхәббәтебез – үз хатыннарыбыз.

Килгән көнне үк җитәкләшеп табибка бардык. Ул безгә нинди дәвалар аласын билгеләргә тиеш иде. Табиб кабинеты янында чират юк, хатын алдан керде, мин аңа иярдем. Табиб хатынга: «Проходите, садитесь», – диде дә, мине күргәч, монысы кем инде тагын, дигәндәй, аптырап калды. Нидер әйтмәкче дә иде бугай, әмма хатын: «Он со мной», – дигәч, авыз чите белән елмайгандай итте. «А-а, вы с папашей приехали?» Табибның бу сүзләре бераз кәефне җибәрде, әлбәттә. Тапкан папаша! Таякка таянып, бераз бөкрәеп йөрим, кәнишне, димәк, «папаша» кебек күренүемә үзем гаепле. Ну, барыбер күзгә бәреп әйтмәскә иде инде. Көндәлдән генә шуны уйладым, әмма үпкәмне табибка сиздермәдем. Минем тормыш принцибым шундый, әгәр нидер килеп чыкмый, эш бармый икән, гаепне иң элек үземнән эзлим. Кайчан нәрсә эшләп җиткермәдем, нинди хата җибәрдем икән, дип уйланам. Сезгә дә шундый ук киңәш бирәм.

Кыскасы, әйбәт ял иттек без, дөресрәге, дәваландык. Шифаханә ял йорты түгел шул, вакыт узды да китте. Нарат урманы эчендәге иң яхшы отельдә, аның люкс номерында рәхәтләнеп иҗат белән шөгыльләнермен, әллә ниләр язармын кебек иде, тик барып чыкмады.

Без монда Татарстанның халык шагыйре, Тукай бүләге лауреаты, университеттагы сабакташым, тулай торактагы бүлмәдәшем Зиннур Мансуров белән килдек. Әлбәттә, ул да хатыны Роза белән. «Берәр нәрсә яза алдыңмы?» – дип, Зиннурдан көн саен сорашып тордым. Ә ул көн саен: «Әллә ни язып булмады шул», – дип әйтә килде. Һәм беркөнне СССР вакытында илдә язучылар өчен дистәдән артык иҗат йорты булуын сагынып искә алды. Ә хәзер андый йортлар юк. Ни өчен бетте алар? Зиннур: «Элек әдәбияты, сәнгате, мәдәнияте идеологиягә хезмәт итте, ә хәзер тәгаен генә идеология юк», – диде.

Алда «коммунизм кыры» күренми шул хәзер. Соңгы берничә ел эчендә кыйблабыз, бишектәге бала кебек, бишкә төрләнде. Совет чоры идеологиясен күпме генә тәнкыйтьләсәк тә, аның уңай яклары да шактый иде. Идеологиягә хезмәт иткән шул ук язучыларга менә дигән шартлар да тудырылды. Каләм әһелләре идеология фронтының алгы сызыгында булып, язучы сүзе бик кадерле, әһәмиятле саналды. Хәтта, Зиннур дустым әйтмешли, әдәбият дәүләт идеологиясенең бер өлешен тәшкил итте һәм дәүләт, үз чиратында, язучы хезмәтен зурлады, аңа югары бәя бирде. Язучылар өчен төзелгән иҗат йортларында аерым бер мохит барлыкка килде. Өлкән буын язучылары илнең төрле почмакларыннан җыелган каләмдәшләре белән бергә үзләре үк оештырган иҗат кичәләрендә әдәбият турында кыза-кыза бәхәсләшүләрен, ярыша-ярыша үз шигырьләрен укуларын бүген дә сагынып искә алалар. Иң яхшы, иң күләмле әсәрләребез шул иҗат йортларында языла иде, диләр. Үткәннең яхшы якларын сагынып сөйләргә генә калмасын иде ул.

Шунысы кызык: әдәбиятыбызның алтын фондына кергән әсәрләрнең күбесе «цензуралы» совет чорында язылган, классикларыбыз да – нигездә, совет чоры кешеләре. Бүген бездә «татар әдәбияты атасы» саналырлык шәхесләр бармы? «Папаша» исемен күтәреп йөрткән Риман бу сорауга җавап бирми, дөресрәге, бирергә теләми. Аның максаты кеше күңелен бер кытыклап алу гына иде һәм сөйләшүнең дәвамы булыр дип ышана.

АЛТЫН ГАСЫРГА ТАБА БАРГАНДА,

ЯКИ СУКЫР ТЫЧКАН КӨМЕШКӘСЕН ӘЧӘРГӘМЕ, ЮКМЫ?

Укучылар язманың исеменә карагач аптырарлар: алтын гасыр белән ниндидер сукыр тычкан эчемлеге арасында нинди бәйләнеш бар, диярләр. Бәйләнешне без язманың ахырындарак шәрехләрбез, хәзергә исә алтын гасыр турында бераз сөйләшеп алыйк.

Даими күзәтеп баручылар авторның бу атаманы – кешелек җәмгыятенең муллыкта, иминлектә яшәячәк чорының исемен язмаларында еш кына искә алуын хәтерлидер. Юк, сүз коммунизм турында бармый, утопик ул җәмгыятьне тормышка ашырырга булган омтылышларның ни рәвешле тәмамлануын үз тәҗрибәбездә күрдек бит инде. Әмма якын киләчәктә җәмгыять шундый кыска бер чор кичерәчәк (һәм мин ышанам: Аллаһ теләсә, бу язманы укучылар арасында ул чорга барып җитүчеләр булыр әле): адәм баласына күпме теләсә, шуның кадәр алтын тәкъдим ителәчәк, ләкин кызыгучылар булмас. Хакимиятләрнең күпме теләсәң, шуның кадәр акча алырга килергә чакыруына бары тик бер кеше җавап бирәчәк. Аның алдына күп итеп алтын китереп өячәкләр, шунда аның күңелендә оялу пәйда булачак. «Никадәр кеше арасыннан берүзем акча алырга килдем бит», – дигән үкенечле уйга батачак ул һәм бирелгән алтыннарны кире тапшырырга теләячәк, әмма аннан кире кабул итеп алмаячаклар: «Без биргәнне кире алмыйбыз», – диячәкләр. Ул чакта байлык шулкадәр күп булачак: кешеләр, аның бетмәячәген аңлап, ярышудан туктаячак. Бөтенләй башка кыйммәтләр өстенлек алачак. Вәләкин исегезгә төшерәм: коммунизмнан аермалы буларак, акча – товар мөнәсәбәтләре сакланып калачак.

Әйдәгез, хәзер бергәләп фикерләп алыйк: бу хәл мөмкинме, мөмкин булса, аның мәйданга чыгуы өченниләр кирәк? Акча күп кирәк дип әйтә күрмәгез, чөнки, бердән, акча хәзер дә бик күп. Үзәк банклар аны тонналап басып тора, ул гына җитмәсә, телгән һәр кеше, кирәкле җиһазлар сатып алып, үз өендә криптовалюталар «баса» ала. Бәяләре шактый гына төшсә дә, андый валюталар һаман да кыйммәт йөри әле. Акчаның күплеге проблема гына тудыра: товарларга һәм хезмәтләргә бәяләр үсә һәм инфляция безнең барыбызның да баш авыртуына әверелә. Менә әле яңа гына Әрмәнстан Үзәк банкы процент ставкасын 10,75кә кадәр күтәрде, чөнки россиялеләр илне сумнар, доллар һәм евролар белән тутырды. Кичкенә генә илгә быелның 10 аенда 4,1 миллиард доллар акча күчергәннәр. Акчаның күплеге күчемсез милеккә һәм башка товарларга бәяне шулкадәр итеп күтәрә: җирле халык үз илендә үзенә фатир сатып ала алмаслык хәлгә килә. Такси бәяләренә кадәр котырып үсә. Уртаазиялеләр көләләр әнә, россиядәге үз ватандашларын илләренә кайтырга чакыралар: «Мәскәүдә таксида эшләүдән туктагыз, россиялеләр безгә килде, таксига күпме сорасаң, шуның кадәр түлиләр», – диләр. Процент ставкасын күтәргәч, кешеләр акчаны товарга түгел, ә банк депозитына салып сакларга тырыша. Бу базардагы акчаны алып, инфляцияне вакытлыча булса да басып тора.

Дәүләтләрнең бүген нәрсә өчен үзара бугазлашырга ашкынуларын искә төшерик әле. Нәрсәгә бәяләр котырып үсә? Энергия чыганакларына. Энергия җитәрлек булса, арзанлы товарны күпләп җитештерү хәзерге технологияләр белән берни дә түгел. Димәк, муллыкка ирешүнең бер шарты булып (беренчесе дип әйтмәс идем мин), арзанлы һәм шул ук вакытта экологиягә зыян салмый торган энергиягә ирешү тора. Энергияне күпме теләсәң, шулкадәр тотасың, әмма ул бетми. Мөмкинме бу хәл?

Бүген төнлә (чәршәмбе иртәсендә язам бу юлларны) Америка телевидениесе аша рәсми рәвештә игълан иттеләр: АКШта тарихта беренче тапкыр термотөш синтезы реакциясе вакытында аны үткәрүгә таләп ителгәнгә караганда күбрәк энергия эшләп чыгарылды. АКШның Энергетика министрлыгы моның Калифорниядәге Милли лабораториядә тормышка ашырылуын һәм XXI гасыр уңышы буларак тарих дәреслекләренә язылачагын хәбәр итә. Ак йортның фән буенча киңәшчесе Арати Прабхакар тәҗрибәне «инженерларча фикерләүнең акылга сыймаслык зәбәрҗәте» дип бәяләде. Галимнәр әйтүенчә, бу тәҗрибә Кояшта барган реакциягә охшаган эффект бирәчәк һәм кешелек дөньясын бетми торган чиста энергия белән тәэмин итәчәк. Аны гамәлгә кертүгә берничә дистә ел кирәк булыр, диләр.

Кытай инженерлары да бу өлкәдә зур уңышларга ирешеп киләләр. Алар күптән түгел генә сыек торийда эшли торган атом реакторын сынады. Торий уранга караганда күпкә куркынычсызрак булып санала, һәм аның реакторын суыту өчен су кирәк түгел. Бу уңайдан төрекләр сөенә: МАГАТЭ отчетына караганда, дөньядагы торий запасларының 11 проценты – Төркиядә. Бары тик Ыспарта-Аксу төбәгендәге 20 мең тонна торий запасы гына да Төркияне йөз елга энергия белән тәэмин итәргә җитәчәк икән. Торийның бөтен планетадагы запасы 6,7 миллион тонна тәшкил итә. Бетмәс-төкәнмәс энергия чыганагы дигән сүз бу. Галәмнән Кояш энергиясен Җиргә тапшыру буенча уңышлы тәҗрибәләр үткәрелеп килә. Башка технологияләр дә үсештә. Нәтиҗә ясыйбыз: алтын гасыр өчен кирәкле энергия проблемасы якындагы елларда хәл ителерлек.

pixabay.com

Чын акча басу өчен кирәкле алтын исә җир астында тулып ята. Аны өскә чыгарып тигезләп җәйсәләр, без тездән алтынга батып йөрер идек. Хәзерге технологияләр исә шундый: теләсә нинди катлаулы җиһазны (хәтта кеше әгъзаларын да) 3Д принтерлар зур тизлектә басып чыгара алачак. Күрәбез: мәсьәләнең матди ягы технологияләр ярдәмендә хәл ителерлек.

Ләкин матди байлыклар күпме генә артмасын, кешелек җәмгыятен бәхетле итмиләр һәм алтын гасырга китермиләр. Эпохага аяк басу өчен иң төп шарт – гаделлек тантанасы. Шул булмаса, адәм балалары үзара сугыштан, ярышудан, көнчелеккә нигезләнгән конфликтлардан айный алмаячак. Гражданлык технологияләренә караганда хәрби технологияләр кызурак темплар белән үсә бүген. Аларны туктатып, тыныч яшәүгә күчү өчен акыл җитми. Әйе, адәм балаларында бүген иң катлаулы технологияләрне үстерерлек интеллект бар, әмма акыл юк. Шул булса, бүген үк инде алтын гасырга күчеп булыр иде.

Акыл юклыкка бер мисал китерик әле. Роспотребнадзор (кулланучыларның хоукларын якларга тиешле шундый оешма барын беләсездер инде) үлгән сукыр тычкан төнәтмәсеннән ясалган «кротовуха» дигән исерткеч эчемлекне куллануның куркыныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкинлеген искәртте. Башыгызга: «Тычкан үләксәсе салынган аракыны кем эчә инде?!» – дигән уй килмәдеме? Килсә һәм бераз укшып та куйсагыз, котлыйм: сез – нормаль кеше. Әмма бер блогер «сукыр тычкан үләксәсе салынган көмешкә»не рекламалаганнан соң, эчемлек популярлык яулый башлаган. Роспотребнадзор шуңа күрә рәсми кисәтү ясарга мәҗбүр булган. Менә шундый акылдан язган кешеләрдән торган җәмгыять безнең алтын гасырдан бик ерак булуыбызны дәлилли.

Атаклы бер шәхес, тормышта зур уңышларга һәм байлыкка ирешкән бер кеше интернетта: «Мин балаларыма болай дидем: «Минем сезгә әләкмәгән бер өстенлегем бар иде: балачагым авырлыкта үтте», – дип язды. Кеше шәхесен чын уңышка китерү өчен, авырлыклар белән камчылану, һичшиксез, мөһим һәм кирәк. Җиңел килгән уңыш гадәттә һәлакәткә илтә. Шуңа күрә соңгы елларда тормыш безне катлаулы сикәлтәләр өстендә сикертә икән, гаҗәпләнмәгез. Күп тапкырлар ачыргаланырга, гаҗизләнергә, зур югалтулар аша узарга туры киләчәк барыбызга да. Әлегә исә хәл шундыйрак: сәяси лидерларның рәсми белдерүләрен тыңлаганда шаккатасың: патология бит бу, авыру симптомнары, дисең. Нишләтәсең, гомуми акылдан язу пандемиягә әверелде. Шулай булгач, алтын гасыр кайда да, без кайда?!

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

«БЕЗНЕҢ АВЫЛ МОНДЫЙ ТҮГЕЛ ИДЕ»

КИРОВ ХАЛКЫ САСЫ ИСТӘН ЗАРЛАНА

«Сасы искә тончыгабыз. Зинһар, килеп бер чарасын күрегез». Актаныш районының Киров авылы халкы безгә әнә шулай дип мөрәҗәгать итте. Хәлне ачыклар өчен, юлга кузгалдык.

«Чыдар хәл юк»

Халыкны борчыган сасы иснең сәбәпчесе Актаныш сөт комбинаты булып чыкты. Тагын да төгәлрәге, оешмадан аккан пычрак сулар. Алдан аңлатып китик, 2019 елга кадәр ташландык хәлдә булган завод – белорусларның һәм актанышлыларның уртак проекты. Бик зур суммаларда инвестиция кертелгән заманча, югары технологияләр белән җиһазландырылган комбинатта атланмай, эремчек, коры сөт, 40 процентлы каймак, коры эремчек сывороткасы, сыр җитештерелә.

– Дөрес аңлагыз, без заводның эшләвен телибез, – дип сүзен башлады безне каршы алган халык арасыннан Айдар Минхәйдәров. – Авыл, халык өчен аның булуы бик яхшы. Чөнки ул кешеләрне эш урыннары белән тәэмин итә. Заманында шушында эшләүчеләр өчен ике катлы йортлар салып бирделәр хәтта. Аннан соң ул берничә ел ябылып торды. Менә хәзер яңартылып, кабат торгызылды. Бу бик яхшы. Тик ул тиешле таләпләргә җавап бирсен иде. Йорт салганда бәдрәфне дә эшләп куябыз бит. Ә монда анысын эшләргә «оныттылар». Нәтиҗәдә сасы исе авылга тарала. Күрше-тирә авыл халкы да: «Сез анда ничек яшисез? Яныгыздан узып киткәндә дә чыдап булмый бит», – диләр.

Әлеге вакытта заводның барлык пычрак сулары бинадан берничә чакрым ераклыктагы, ян-якларын балчык белән күтәртеп куйган бассейннарга ага. Завод зурайган саен, аларның саны да арта тора. Шулай итеп, хәзерге вакытта шундый су җыела торган сигез урын барлыкка килгән. Янына якын ук барып карау мөмкинлеге булмаса да, махсус җиһаз белән төшереп карый алдык. Ул вакытта да без суның бер бассейнга саркып агып ятуын күрдек. Язын ул ярларыннан ташып, басу-кырларга агачак, дип тә әйтүчеләр булды. Якында гына күл дә, халыкның печәнлекләре дә бар.

– Мин шушы авылдан көн саен сөт җыям, – диде Ләйлә Бәхтиева. – Сасы искә чыдамалы түгел. Без үзебез заводтан шактый ерак, авылның икенче башында торабыз. Исе безгә кадәр килеп җитә. Җәен бигрәк тә кыен. Тәрәзәләрне ачып булмый, тамак төбенә утыра. Җил авылга таба искәндә бөтенләй авыр. Ул ис киптерергә элгән керләргә кадәр сеңә. Безнең авыл мондый түгел иде. Гомер-гомергә эшләделәр, тик авылыбыз мондый сасы булмады. Җитмәсә, заводта, каргалар килмәсен өчен, төрле ят тавышлар чыгаралар. Эте дә өрә, маймылы да, филе дә кычкыра. Яныннан узганда шул тавышлар кинәт ишетелсә, курыкып китәбез.

Халык әйтүе буенча, әлеге җыелып тора торган сулыклардан канализация исе килә.

– Ул әшәке ис бөтен авылга таралып, тәнгә кадәр сеңә, тамак төпләренә утыра. Минем балаларым күп, шуңа күрә ризыкларны әрҗәләп, капчыклап алабыз. Аларның маен ярминкәдән сатып алган идем. Тик авызга ала торган булмады, тәмсез иде. Кире илтеп бирергә туры килде, – диде Мәрьям Сабитова.

Киров авылы халкы сүзләренчә, язын биредәге пычрак сулар 5 чакрым ераклыктагы Сәфәр авылындагы елгага да, Кадермәт һәм Сәфәр авыллары уртасындагы күлгә дә ага. Габидин абый умарта кортлары тота икән. Аның фикеренчә, авылда экология үзгәрүнең кортларга да зыяны бар.

– Мин моны экологик катастрофа дип кабул итәм, – диде ул. – Соңгы елларда корт чаккач, кешеләр авырый башлады. Корт агулангач, агуы тагын да әшәкеләнми микән, дип уйлыйм.

Безнең белән очрашуга заводка якын булган иң кырыйдагы Алматау урамында яшәүче Рәмзия Ялалова белән Ләйсән Сәетова да килгәннәр иде. Алар да зарланды.

– Авылга таба җил искән көннәрдә өйдә тын алмаслык сасы була. Әле ярый менә берничә көн ис басылды. Ризык җитештергәч, барлык таләпләргә туры китереп эшләсеннәр иде, – диде апалар.

«Тамак төбенә утырырдай, күзләрне ачыттырырдай» сасы исне шәхсән үзебез сизмәдек. Бәлки бу һава торышына бәйле булгандыр. Без барган көнне урамда салкын иде. Халык та, кышка кергәч, әлеге иснең бик күпкә кимүен әйтте. Тик алар бу күренешне вакытлыча гына булыр, сасы ис авылны кабаттан чолгап алыр дип шикләнә. Чөнки әлегә кадәр заводның чистарту корылмасы эшләнмәгән. Анысын завод җитәкчелеге дә инкарь итмәде.

Киләчәктә булачак

Авыл халкы заводка чит кешеләрне якын китермиләр дисә дә, тәвәккәлләп карарга булдык. Сакчылар җаваплы кешеләрне чакырып чыгарды. Җитәкчеләре авырып тора икән, шуңа күрә безнең янга заводның баш инженеры Евгений Андреевский чыкты. Дөрес, оешмада карантин булу сәбәпле, эчкә уздырмадылар. Комбинат вәкиле белән завод ишек төбендә аралаштык.

– Авыл халкының борчуын беләбез, без аралашуга һәрвакыт ачык, – диде ул. – Тик чистарту корылмасы төзелгәнче ис чыгу проблемасы булачак. Без моны аңлыйбыз, килешәбез, «ул юк» дип инкарь итәргә җыенмыйбыз. Безгә «мирас» булып шушы бассейннар гына күчте. Аларны рәткә китерер өчен дә шактый чыгым чыгарырга туры килде. Күп эшләр эшләнде, аларны киңәйттек, ярларын ныгыттык. Сасы исләрдән котылыр өчен быел, технологларны җәлеп итеп, су чокырларына махсус бактерияләр җибәрдек. Һәм чыннан да, 2021 ел белән чагыштырганда, җәен ис күпкә кимеде. Ә кышка кергәч, бөтенләй бетте дип әйтергә була, чөнки салкын һава үз эшен эшли. Киләсе елда җыелып тора торган суларга тагын шундый ук бактерияләр җибәрәчәкбез. Ис азмы-күпме басылып торыр, дип уйлыйбыз. Булдыра алганча көрәшәбез.

Евгений Андреевский заводның электән калган чистарту корылмасының бик начар хәлдә булуын әйтте. Әлеге вакытта яңасын эшләр өчен проект ясала.

– Мин үзем бу эшкә Белоруссиядән 2019 ел ахырында килдем. Шуннан соң техник биремнәр, проектлар ясау эшенә тотындык. Хәзерге вакытта килешү төзелгән, проект буенча эшләр бара. Республиканың Гидрометеоүзәге белән дә кулга-кул тотынышып эшлибез. Технологияләр, җиһазларны да сайлап куйдык. Ә менә төзелеш турында сөйләргә иртәрәк әле. Аның өчен акча табасы бар.

Чистарту корылмасы кайчан булачак соң? Әлеге сорауга төгәл җавап ишетмәдек.

– Проектның төп бүлекләрен миңа киләсе елның маенда бирергә ышандырдылар. Ләкин чистартылган суны чыгару өчен сулыкларны килештермәү сәбәпле, Гидрометеоүзәк белән эшебез октябрьдән дә иртәрәк бетмәячәк. Проектны экспертизага җибәргәннән соң инвестиция турында уйларга мөмкин булачак. Бу мәсьәләне хәл итәр өчен ниндидер дәүләт программаларында катнашып, финанслау аласыбыз килә, – дип аңлатты Евгений Андреевский.

Әлегә заводның дүрттән бер өлеше генә төзелеп килә. Икенче этапка киләсе ел башында тотынмакчылар. Беренче һәм икенче чиратта төзелгән оешмада тәүлегенә 450 тонна сөт эшкәртү планлаштырылган. Әлегә биредә 140 тонна сөт эшкәртелә. Комбинат тулысынча заманчалашкан. Кызганыч, эшчеләр, хезмәткәрләр генә җитми. Чимал белән дә әлегә авырлыклар бар икән.

– Кызганыч, чимал җитми, кыйммәт. Җитештерү куәте 220 тоннадан 140 тоннага калды. Без эшли башлагач, заводта яңа эш урыннары барлыкка килде, җитештерү куәте артты. Соңгы ике елда аякка басып, матур нәтиҗәләр белән сөендерергә ниятлибез, – диде Евгений Андреевский.

Әлеге мәсьәләгә карата Актаныш районы хакимиятенең дә фикерен ишетәсебез килде.

– Киров авылындагы Актаныш сөт комбинаты – Актаныш районы икътисадында әһәмиятле урын алган, район халкын эшле иткән зур предприятиеләрнең берсе. Бүген биредә 200дән артык кеше хезмәт куя, – дип хәбәр иттеләр безгә районның матбугат үзәгеннән. – 5 млрд сумнан артык инвестиция җәлеп итеп, бүген комбинат проектның беренче этап егәрлегенә чыкты. Заводның әлегә дүрттән бер өлеше генә төзелгән. Төзелеш эшләре дәвам итә. Шул исәптән чистарту корылмаларын ясау буенча да эш бара. Проект һәм документациясе әзер. Әлеге мәсьәлә буенча район башлыгы Ленар Зарипов та комбинат җитәкчелеге белән очрашып сөйләште. Якын арада тиешле корылмалар булдырылып, вазгыять уңай хәл ителәчәк.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Белгеч фикере

Эколог **Наил НАЗАРОВ**, сөт заводларының һәркайсында чистарту корылмалары булырга тиеш, ди. Чөнки алар барысы да табигатькә зыянлы матдәләр бүлеп чыгара.

– Атмосферага нинди зыяны бар? Сөт эшкәртү комбинатларында лактоза тузаны хасил булып, һаваны пычрата. Моның өчен заводларда һава чистарту җайланмалары кулланыла. Эшкәртелгән суларның елга-күлләргә, рельеф өслегенә чыгуы – шулай ук зур игътибар таләп итә торган мәсьәлә. Җитештерү барышында барлыкка килгән сулар шулай ук чистарту корылмалары аша узарга тиеш, чөнки аларда зарарлы матдәләр бик күп. Аксым, углеводлар, майлар, органик кислоталар елга-күлләргә, җир асты суларына эләгеп, табигатькә зур зыян сала, – диде белгеч.

Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең (Росприроднадзор) Идел-Кама төбәкара идарәсе җитәкчесе **Фаяз ШАКИРОВ**тан да заводның чистарту корылмасыз гына эшләвенең табигатькә нинди зыян китерүен сорадык.

– Урынга барып күрмичә, ниндидер нәтиҗәләр чыгару авыр, – диде ул. – Аларның закон бозу-бозмауларын да технологияләрен үз күзебез белән күрмичә, тикшермичә әйтеп булмый. Сез рәсми хат язган очракта, барып тикшерә алабыз. Сулыкларга агызган очракта, заводтан чыккан сулар чистарту корылмалары аша узарга тиеш. Алардагы пычрак матдәләрнең нормативтан артмавы мәҗбүри. Җиргә исә суларны чистарту корылмасыннан соң да агызырга ярамый.

КИЕМЕҢӘ КАРАП...

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ике кешенең берсе – интернетта

Белгечләр исәпләп чыгарган: яздан бирле илдән 15 зур чит ил бренды киткән. Кайберләренең берьюлы бернича кибет тотуын искә алсаң, бүген зур сәүдә үзәкләренең ярым буш торуларына гаҗәпләнәсе түгел. Дөрес, кайбер кибетләр, кем әйтмешли, бер аяклары белән – бездә, икенчесе белән – читтә. Башкаладагы «Мега» сәүдә үзәгендә, мәсәлән, кайбер ишекләрдә әле дә «вакытлыча ябылдык» дигән игъланнар тора. Тик бу кибетләрнең кайчан ачылачагы гына билгесез. Бездән китәргә теләмәүләре дә аңлашыла кебек. Ни генә дисәләр дә, Россия халкы зәвыклы киенергә ярата. Безнең илдә брендлы кием-салым кибетләре Европага караганда да зуррак керем ала. Бу беркемгә дә сер түгел.

Бу хәлдән чыгу юлын табучылар да бар. Кайберләре, кибет исемен кыскартып, кабат ачылдылар. Ни генә булса да, илдәге вазгыять сатучыларга да, сатып алучыларга да тәэсир итте, ди белгечләр. Кибеттә күлмәк-чалбар бар анысы, тик бәясе генә кыйммәтләнде. Җитештерүчеләр моны чимал хакы, бигрәк тә тукымаларга бәя артуга бәйләп аңлата. Сатып алучылар да акчаны әрәм-шәрәм итәргә артык ашыкмый. Иртәгә нәрсә буласын кем белгән. Ел ахырына кадәр Россиядә кием-салым һәм аяк киеме сату күләме 15 процентка кимеячәк, дип фаразлый белгечләр.

Кибет булмаса ни, хәзер сәүдә интернетка күчте. Өйдән чыкмыйча гына, диванда кырын яткан килеш «кибеттә йөрү»дән дә рәхәте юк. Маркетплейс, ягъни интернет сәүдә мәйданнарында җаның теләгән бөтен нәрсә бар. Сатучыларга да отышлы: интернет аша сәүдә итү чыгымнарны бермәбер киметә. «Вайлдберриз»да, мәсәлән, быел сатучылар саны – өчләтә, тәкъдим ителгән кием-салым күләме икеләтә арткан.

– Соңгы тапкыр кием-салым кибетенә кайчан барганымны да хәтерләмим, бөтен кирәк-яракка интернет аша гына заказ бирәм, – ди башкаладагы идарәче оешмаларның берсендә икътисадчы булып эшләүче Аида Байтимерова. – Чит ил брендлары бездән китә башлаганчы ук маркетплейсларга күчкән идем. Интернетта кием-салымны кибеткә караганда күпкә арзанрак саталар. Иң элек кибеткә барып, ошаган күлмәк-чалбарны киеп карап, аннары өйдә заказ бирә идем. Хәзер болай эшләп булмый, билгеле. Фотосына карап кына сайлыйсың. Шөкер, килгән әйберләр сыйфатлы. Ошамаганын кире җибәреп тә була бит.

«Анкетолог» иҗтимагый фикер институты үткәргән сораштырудан күренгәнчә, ил халкының 53 проценты соңгы ярты елда бер тапкыр булса да интернеттан кием-салым сатып алган. Һәр ике кешенең берсе дигән сүз бу! Кесә телефоны аша гына киенергә теләүчеләрнең 44 проценты нәкъ менә бездән киткән чит ил брендларын эзли. Барыннан да бигрәк, халык сыйфатлы спорт аяк киемнәрен сагына икән. Интернетка шуны эзләп керәләр. Икенче урында – хатын-кызлар киемнәре. Беренче өчлеккә балалар киемнәре дә эләккән.

Казан – Төркия арасы

Гөлназ Мостафина – Яшел Үзән кызы. Илдә мобилизациягә бәйле хәлләр башланганчы ук гаиләсе белән Төркиягә күченеп киткән алар. Тормыш иптәше читтән торып эшләсә, Гөлназ Төркиядән кием-салым, урын-җир әйберләре, сөлге ише өй кирәк-яраклары, күн аяк киемнәре, сумкалар сата. Социаль челтәрләрнең берсендә үз сәхифәсе бар аның.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Яшел Үзәндә яшәгәндә дә сату-алу белән шөгыльләнә идем. Шуңа күрә миңа бу эш ят түгел. Ә Төркия товарлары сыйфаты ягыннан башкалардан аерылып тора. Чит илгә күченеп киткәч тә, туганнар, танышларым үзләре үк: «Безгә тегене, моны җибәр әле», – дип мөрәҗәгать итә башлады. Шул рәвешле дуслар арасында оештырган кечкенә генә сәхифәм зур сәүдә мәйданына әйләнеп китте. Бүген төркемдә 500ләп кеше бар. Самара, Уфа кебек шәһәрләрдән дә сатып алалар. Заказларны җыеп, Казанга җибәрәм. Аннан туганым посылкаларны төрле шәһәрләргә озата, – дип сөйли Гөлназ.

Товарлар Төркиядән Мәскәүгә карго, ягъни йөк ташучы логистика компаниясе хезмәте аша кайта. Бу очракта сатып алучыга заказ биргән кием-салымның авырлыгы өчен түләргә кирәк. Йөк машинасы белән кайтартканда (юлга ике-өч атна вакыт китә. – **Ред.**) күлмәк-чалбарның бер килосы, мәсәлән, 500 сум чамасы. Очкыч белән тизрәк, аның каравы чыгым да 200–250 сумга арта. Мәскәү – Казан арасы да түләүле. Гөлназ күннән аяк киеме, сумкалар җитештерүче фирма хуҗалары белән дә эшләү җаен тапкан.

– Әле яңа гына Казанга 40лап кышкы сапоги кайтарып җибәрдем. Кунычы озын булмаган күн сапоги дүрт мең ярым сумга төшә. Казанда бу бәягә сыйфатлы аяк киеме гомумән табып булмый, – ди Гөлназ.

Брендлы кием-салымны да үзебездә булган кибетләрдән сатып алганчы, Төркиядән кайтарту очсызракка төшә икән. Бу чит ил валютасы арзан булуга бәйледер, мөгаен. Мондый сәүдәнең бердәнбер кимчелеге ягы шул: көтәргә кирәк.

Энәләре тик тормый

Республика җитештерүчеләре халыкны кием-салым белән тәэмин итәрлек хәлдәме? Татарстан Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының матбугат хезмәтеннән алынган мәгълүматларга караганда, былтыр республикада 390 җиңел сәнәгать предприятиесе теркәлгән. Быел гыйнвар – октябрь айларында тармакта 7 миллиард сумлык продукция җитештерелгән. Шул исәптән, 3,2 миллиард сумлык кием-салым, 934 миллион сумлык күн һәм күн эшләнмәләре эшләп чыгарганнар. Татарстанның җиңел сәнәгать предприятиеләрендә өлкәннәр һәм балалар киемнәре, махсус кием, мәктәп формасы, бер тапкыр кия торган медицина киемнәре, оек-оекбаш җитештерелә. Кыскасы, саннар кечкенә түгел.

Әлмәтнең «Алсу» оек-оекбаш фабрикасында гына да елына 20 миллион пар оек җитештерәләр. Ул – ил күләмендә иң зур оешмаларның берсе. Хәзер урын-җир кирәк-яраклары, махсус кием тегүне дә җайга салганнар. Мобилизациягә эләккән солдатларга махсус хәрби оекбашлар да тегә башлаганнар хәтта. Эшләре баштан ашкан, ахры. «Моңарчы ничек эшләгән булсак, хәзер дә шулай дәвам иттерәбез», – диде алар. Шуннан башка мәгълүмат булмады.

Булганнары белән берләштән, эшкә яңа тотынучылар да бар. «Түбән Кама» социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты булган «Бикотекс» оешмасында безнең җитештерүчеләр өчен бик тә кирәкле чимал – микрофибра тукымасы чыгара башлаганнар. Быелның өченче чирегендә сәнәгатьтә җитештерү куәте 20 процентка арткан. Татарстанда төпләнгән «IDA PROSPORT» спорт киемнәре җитештерүче оешмада быел яшьләр таләпләренә туры китереп, кепка, озын футболка, худи (капюшонлы киң свитер. – **Ред.**) ише киемнәр дә тегәргә керешкәннәр.

Кием-салымсыз калмаячакбыз, дип ышандыра белгечләр. «Татарстан Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы ел дәвамында җиңел сәнәгать тармагы предприятиеләре белән даими элемтәдә тора, аларга импортны алмаштыру, чимал кайтарту юлларын җайга салу кебек мәсьәләләрдә ярдәм күрсәтелә. Мәсәлән, апрель аенда республиканың әйдәп баручы җиңел сәнәгать предприятиеләре вәкилләре Үзбәкстанга барды. Нәтиҗәдә ике арада трикотаж тукыма, мамык җеп кайтаруга бәйле килешүләр төзелде», – дип сөйләделәр министрлыкның матбугат хезмәтендә. Кем белә, бәлки тиздән баштанаяк үзебездә җитештерелгән киемгә күчәрбез әле.

Эльвира ВӘЛИЕВА

КИЕМ-САЛЫМНЫ КАЯН САТЫП АЛАСЫЗ?

Исемнәре таныш булган чит ил һәм Россия кибетләренә өстенлек бирәм	31%
Сәүдә маркасы булмаган кибетләргә йөрим	30%
Базардан киенәм	27%
Булганын киям, өсте-өстенә кием җыя торган чак түгел	12%

(«Анкетолог» иҗтимагый фикер институты үткәргән сораштырудан)

Фикер

Раилә ЯКУПОВА, «Кукмара тегү фабрикасы»ның профсоюзлар оешмасы җитәкчесе:

– Без брендлы кибетләргә алмаш булырга әзер. Эшләргә теләгән кешегә элек тә мөмкинлекләр җитәрлек иде. Без балалар, хатын-кызлар һәм ир-атлар киемнәре тегәбез. Бүгенге вазгыятькә бәйле рәвештә солдатларга йокы капчыклары, җылыны саклый торган эчке кием тегүне дә җайга салдык. Безнең продукциягә сорау зур һәм ул һәрвакыт тотрыклы. Бигрәк тә көзге-кышкы чорда. Без шундый бит: башта ашыйсы килә, аннары өс-башны кайгырта башлыйбыз. Дөньялар тыныч булсын, эшсез калмаячакбыз. Безнең фабрикада чимал сатып алуга бәйле кыенлыклар юк. Мәскәү оешмалары аша эшлибез. Хәзер тукыма да, төймә, молния ише фурнитура да нигездә Кытайдан кайта. Татарстанда электән эшләүче зур тегү фабрикалары калмады инде. Безнең кебек утызлап оешма исәпләнә иде. Фабрикада йөздән артык эшче бар. Замана таләпләренә туры китереп тегәргә тырышабыз. Бүген сатып алучыга ярау өчен шактый тырышырга туры килә.

Ләйсән ХӘБИБУЛЛИНА, «Азнакай киемнәре» тегү фабрикасының җитештерү буенча генераль директоры урынбасары:

– Безнең сәнәгать үзенчәлекле. Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнары нефтьчеләре өчен махсус эш киемнәре тегәбез. Эш киемнәре җитештерүнең үз тәртибе бар. Тегүдә махсус тукыма кулланыла. Дөньядагы вазгыятькә бәйле рәвештә безнең оешмада да үзгәрешләр булды. Бу, иң беренче чиратта, чималга бәя артуга бәйле. Аны Россия җитештерүчеләреннән сатып алабыз. Фурнитура белән тәэмин итүче арадашчылар Кытай белән эшли. Ә чимал бәясе арттымы, җитештергән продукция дә кыйммәтләнә, билгеле. Шөкер, безгә «Татнефть» оешмасы зур ярдәм күрсәтә. Гомумән алганда, бу ел уңышлы узды. 200дән артык кешене эш белән тәэмин итәбез. Махсус өс киемнәре тегү бер урында тора торган эш түгел. Бу өлкәдә гел ниндидер яңалык гамәлгә керә, яңа тукымалар чыга, җиһазлар үзгәрә. Шуңа күрә замана таләпләренә туры килүче продукция җитештерергә тырышабыз. Гади халыкка да якын без. Илдә коронавирус башлангач, кулдан битлекләр тектек. Быел «Татнефть» кушуы буенча солдатларга йокы капчыклары, рюкзаклар җитештердек.

Тимерхан ЗЫЯТДИНОВ, «Alga» брендын оештыручы:

– Без төрле катлау вәкилләре өчен кием җитештерәбез. Тукыма һәм фурнитура сатып алуга бәйле кыенлыклар юк. Дөрес, аның бәясе кыйммәтләнде. Үзбәкстаннан кайтарылучы чимал – 20, Төркия тукымалары – 30, Италиянеке исә, җитештерүчесенә карап, 50дән алып 100 процентка кадәр артты. Соңгы арада халык арасында ватанпәрвәрлек хисе артты. Безгә Татарстан, Россия әләмнәре төшерелгән киемнәр сорап мөрәҗәгать итәләр. Чит ил брендларының китүе – безгә файдага гына. Көрәштәге кебек: көчле көндәш ярыштан төшеп калса, җиңү мөмкинлеге тагын да арта. Заманасына күрә бөтен маркетплейслар белән дә эшлибез. Бу – яхшы реклама. Интернет мәйданнарда комиссия күләме 20 проценттан да артмый, кибет тотуга караганда күпкә отышлырак бит. Татарстанның үз сәнәгатен аякка бастыру өчен көче дә, куәте дә җитәрлек. Үзебездә дә сыйфатлы итеп киенергә мөмкин икән, ник чит ил товарларына кызыгырга? Гомумән, чит ил кибетләре безгә гел аларның товарлары яхшырак дип кабатлап килде. Моңа ышандык та. Бүген әнә шул мәҗбүри тагылган фикердән котыларга вакыт җитте. Россиядә тегелгән кием чит илнекеннән бер дә ким түгел. Хәтерләсәгез, 1990 еллар башында бөтен кеше USA дип язылган һәм бөркет төшерелгән кепка киеп йөрде. Әйтүләренә караганда, ул вакытта шундый 100 миллион баш киеме сатылган булган. Бәлки, чит илнеке шәп, дигән фикер безгә әнә шул чорда ук сеңеп калгандыр. Хәзер исә безнең вакыт җитте.

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

Бурыч җыйгансың икән, аны вакытында кайтарырга да кирәк. Әмма соңгы чиккә җиткән булсаң, нишләргә? Бу очракта белгечләр үзеңне закон нигезендә банкрот дип тану ягын сайларга куша. Эшне югалту, хезмәткә яраклы булмау яисә алдагы ярты елда акча мәсьәләсен уңай хәл итеп булмаган очракта, шушы юлга басарга туры килә. Банкротлыкка чыгуның уңай һәм тискәре яклары, бу эшне нидән башларга, кемнәр әлеге мөмкинлектән файдалана ала, кемгә мөрәҗәгать итәргә? «ВТ» шушы сорауларга ачыклык кертә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

БАНКРОТ

БУРЫЧЛАРДАН КОТЫЛУ: УҢАЙ ҺӘМ ТИСКӘРЕ ЯКЛАРЫ

Кимеми

Россия судлары бу елның тугыз аенда 194145 кешене һәм шәхси эшмәкәрне банкрот дип таныган. Бу узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда 41,2 процентка артыграк. Әлеге статистик мәгълүмат белән Банкротлык турында белешмәләрнең бердәм федераль реестры (Федресурс) уртаклашты. Саннар шуны дәлилли: әҗәт йөге бик күпләр күтәрерлек дәрәҗәдә түгел.

Гыйнвар – сентябрь аралыгында гражданнарны судтан тыш банкрот (внесудебное банкротство) дип тануга бәйле 4710 эш кабул ителгән. Бу да узган елгы саннардан 43,3 процентка күбрәк. 3647 кешенең эше каралып беткән.

Компанияләргә бәйле вазгыятькә дә күз салыйк. Федресурс мәгълүматларына караганда, бу елның тугыз аенда корпоратив банкротлык күрсәткече кимегән. Быел ул 7227гә калган. Бу былтыргы саннардан 2,4 процентка кимрәк. Март – апрельдә 700әр эш каралса, сентябрь аенда нибары 208 эш кабул ителгән.

Мәгълүм булганча, банкротлыкка мораторий чорында (бу елның 2 октябрендә гамәлдән чыгарылды. – **Авт.**) әҗәтле кешеләр үзләренең хәле турында бары тик үзләре генә белдерергә хокуклы иде. Шул рәвешле кредиторлар ярдәме белән банкротлыкка чыгуга бәйле эшләрнең саны да кимегән. Әйтик, бер ел элек андый күрсәткеч 74,7 процент булса, быел – 66,8 процент.

Россия Югары суды рәисе Вячеслав Лебедев әле күптән түгел генә булып узган Үзәк федераль округ судлары судьяларының X Бөтенроссия съездында быел банкротлык буенча карала торган эшләр саны 33 процентка артты дип белдергән иде. Димәк, банкротлыкка чыгучылар саны чынлап та арта. Нигездә андыйлар зур шәһәрләргә, әйтик, Мәскәү һәм Санкт-Петербургка туры килә.

Банкрот булуның ние бар?

Бер әҗәт алып, аны унлата кайтарасын кайчагында онытып та җибәрәләр бугай. Аннан терсәкне тешләргә генә кала: кредит буенча процентлар арту, штраф белән очрашырга туры килә... Банкрот дип тану процессын кайчан башларга соң? Бу эшнең үзенчәлекләре нәрсәдән гыйбарәт? Ул кемгә файда китерә? Шушы һәм башка сорауларга җавап эзләп, арбитраж идарәче ярдәмчесе **Алсу ӘХМӘТОВА**га мөрәҗәгать иттек.

:: Банкротлыкка чыгу процедурасы буенча мөрәҗәгать итүчеләр күпме? Нигездә сезгә кемнәр ешрак мөрәҗәгать итә?

– Татарларда курку хисе бар. Нәкъ тә безнең халык бу процедурага еш һәм күп мөрәҗәгать итә димәс идем. Тик бит бу процедура законга таянып башкарыла. Бернинди дә мошенниклык түгел. Асылда бик җитди, җаваплы эш ул. Банкротлыкка чыгу процедурасына ышаныч булмау бик үк дөрес түгел. Банкротлык турында закон 2015 елда гамәлгә керде. Әмма аны бөтен матди бәлаләрдән коткара торган дару итеп кабул итәргә кирәкми.

Гадәттә, консультациягә дип, бик авыр тормыш хәлендә калучылар килә. Әйтик, кредит алганда физик зат бурычларын кайтара ала торган хәлдә булган, ди. Әмма кайбер сәбәпләр аркасында (эштән китү, кереме киму, кыскартылуга дучар булу, чир) түләү мөмкинлеге авырая.

:: Әлеге төшенчә турында җентекләбрәк аңлатып үтсәгез иде.

– Гади генә әйтсәк, әҗәтләрдән котылу ысулы бу. Банкротлык – Арбитраж суд тарафыннан кешенең кредитларын түли алмавын тану ул. Кеше кредитларын гына түгел, заем, салымнарын да, гомумән, бурычын түли алмас дәрәҗәдә икән, ул үзен законлы рәвештә банкрот итеп игълан итәргә хокуклы. Болар барысы да 127 нче Федераль законга нигезләнеп башкарыла.

:: Үзен банкрот дип тану барлык кешеләргә дә туры киләме?

– Юк, әлбәттә. Банкротлык процедурасын үтәр өчен шактый юл узарга туры киләчәк. Шуңа да башта очрашып, консультация үтәргә кирәк. Аннан документлар белән эш башлана. Кеше факторы дигән нәрсә дә бар бит. Кайбер нәрсәләр онытыла, хәтердән җуела. Ә документта барысы да язылган.

:: Нинди очракта әҗәтләрдән бу ысул белән котылып булмый?

– Әйтик, ипотекага алынган фатирыгыз бар, ди. Сез әле аны тулысынча түләп тә бетермәгән. Банкротлык әҗәтләрне дә «кичерә» ул. Тик ипотека очрагында, банкротлыкка чыгып, банк алдындагы бурычны юк итеп, фатирлы булып калу мөмкин түгел.

Тагын бер сәбәп әҗәт суммасының күләменә бәйле. 350 мең сумнан артмаган бурыч белән банкротлыкка чыгу отышлы түгел.

Бик күп милек иясе булу да банкротлыкка чыгуга киртә. Поручительләр өчен дә банкротлык процедурасын башлап җибәрү отышлы түгел. Әйтик, сез 1 млн сум күләмендә кредит алдыгыз, ди. Поручитель буларак сезнең туганыгыз теркәлгән, ди. Банкротлык процедурасын узгач, сезнең барлык әҗәтләрегез юкка чыгачак, әмма туганыгызда алар калачак. Аңа да бу юлны узарга кирәк булачак дигән сүз.

:: Эшне нидән башларга?

– Иң элек – консультациягә килергә, бу эш белән шөгыльләнүче яхшы белгеч табарга. Сер түгел, бу өлкәдә дә кырыгалдарлар бик күп. Алар кеше баласеннән бизнес ясый. Акча алып, килешү төзиләр дә, бу эшне башка кешеләргә тапшыралар. Мөрәҗәгать иткән кешенең хәле болай да мөшкел, ул тагын да зуррак упкынга тәгәри дигән сүз. Шуңа күрә теләсә нинди белгечләргә, ялган мәгълуматка ышанмаска киңәш итәм. Әҗәтләрдән котылырга булышучылар тәкъдим иткән кызыктыргыч түбән бәяләргә дә кызыгырга ярамый. Уяу булырга кирәк.

:: Бик күпләр бу процедурадан курка да әле. Банкрот дип танылгач, хәлләр тагын да мөшкелрәк булачак дип фаразлаучылар бар. Ә чынлыкта ничек соң?

– Чынлап та, шулай. Әйткәнемчә, безнең халыкка бигрәк тә хас бу. Әлеге процедураны авыр дип кабул итәләр, шул рәвешле үзләренең хәлләрен катлауландыралар. Әҗәтләрсез тормыш рәхәтрәк бит. Кеше тапкан акчасын бурычка түгел, үзенә сарыф итә ала дигән сүз.

:: Физик затның даими эш урыны һәм хезмәт хакы бар, ди. Андыйларны банкрот итеп танырга буламы?

– Әҗәтле кешенең рәсми эштә эшләве һәм даими тотрыклы кереме булуы банкрот итеп тануга киртә була алмый. Җыелган бурыч күләме айлык керемнән күпкә артыграк булырга мөмкин. Штраф һәм пеняларны да исәпкә алсак, ул сумма бигрәк тә зур була бит. Әйтик, бурычлы кеше 100 мең сум хезмәт хакы ала һәм 200 мең сумлык бурыч белән банкротлык процедурасын үтәргә җыена икән, бу бик үк мантыйкка туры килә торган гамәл булмас. Ә инде 2 млн сум бурычы белән айлык кереме 50 мең сум булган кешегә бу кирәк.

:: Белгеч буларак, бу җәһәттән нинди киңәшләр бирер идегез?

– Кабатлап әйтәм: әлеге процедура – бик җитди һәм җаваплы хезмәт. Кеше ахыр чиктә әҗәтләрсез калган кебек үк, административ җаваплылыкка да җәлеп ителергә мөмкин. Әйтик, ялган мәгълүмат һәм ялган документлар биргән өчен. Бу эшкә җаваплы карарга кирәк.

Кеше кырыгалдарлар кулына да калмасын иде. Алар бик актив реклама алып бара. «Бурычларны 100 процент юк итәбез», «булдыра алмасак, акчагызны кире кайтарабыз», янәсе. Менә шулай алдап, кешегә килешү төзетеп, хәлне катлауландырырга да мөмкиннәр. Түбән бәягә кызыгып, үзегез теләгәнне генә ишетеп алданмагыз.

:: Банкрот булып танылгач, кредит алып буламы?

– Кредит алуга юридик чикләүләр юк. Банклар, киресенчә, банкротларга кредит бирү яклы. Банкротлыкка чыкканнан соң, банк, әлбәттә, физик затның мондый процедура узганын беләчәк. Бу мәгълүмат аның кредит тарихында күрсәтеләчәк. Бурычлардан котылгач, биш ел дәвамында кредит алган вакытта физик затка банклар алдында банкротлыкка чыгуы турында хәбәр итеп торырга кирәк.

Ни өчен банклар банкротларга кредит бирергә ашкынып торамы? Банк кешенең кредит тарихы чиста булуын, бурычларсыз калуын күрә. Димәк, аның кредит йөге нульгә тигез. Моңа өстәп физик затның керем китерә торган хезмәт хакы да булса, бу кеше банк өчен – «алтын» клиент.

НИНДИ ДОКУМЕНТЛАР КИРӘК?

Арбитраж судка гариза бирү өчен түбәндәге кәгазьләрне әзерләргә кирәк:

- ✓гариза;
- ✓бурыч барлыгын раслаучы документлар;
- ✓кредиторлар исемлеге;
- ✓милеккә документлар (ЕГРН, опись, милеккә ия булуны раслаучы документларның күчермәсе);
- ✓керем күләме турында белешмә, түләнгән салымнар турында белешмә (эш урыныннан);
- ✓банк счетлары;
- ✓ИНН һәм СНИЛС күчермәләре.

19 декабрь | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00 ТВ фондыннан. «Беренче театр» 6+
10.00, 23.00 «СВОЙ ЧУЖОЙ СЫН» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «25 НЧЕ СӘГАТЬ» (Татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
17.00, 00.20 «Таяну ноктасы» 16+
17.30 «Татарстан без коррупции» 12+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Куньлунь Ред Стар». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Рыцари вечности». Борис Пастернак 12+
00.05 «Фолиант в столетнем переплете». К 290-летию Ж.-П. Бомарше 12+
00.00 «Ватандашлар» 12+
01.10 «Кәмит Җәвит» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.50, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «КАЗАНОВА В РОССИИ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Елена Яковлева, Сергей Перегудов, Александр Балуев, Ирина Таранник, Александр Дзюба. «ДАМА С СОБАЧКОЙ» 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
00.00 Ко Дню работника военной контрразведки РФ. Премьера. «Арнольд Дейч. Последняя легенда». Фильм Сергея Брилёва 12+
01.00 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.40 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. АСА. Виталий Слипенко против Абубакара Вагаева. Трансляция из Москвы 16+
07.00, 10.00, 12.55, 15.35 Новости
07.05, 21.50, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 Голевая феерия Катара! 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00 Специальный репортаж 12+
13.20 Футбол. Чемпионат мира-2022. Финал. Трансляция из Катара 0+
15.40 «Громко». Прямой эфир
16.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Салават Юлаев» (Уфа) – «Авангард» (Омск). Прямая трансляция
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Нефтехимик» (Нижнекамск) – «Барыс» (Астана). Прямая трансляция
22.55 «Здесь был Тимур» 12+
01.50 Karate Combat 2022. Трансляция из США 16+
02.55 Новости 0+
03.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. УНИКС (Казань) – «Пари НН» (Нижний Новгород) 0+
05.00 «Громко» 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «АДМИРАЛЫ РАЙОНА» (S) 16+
22.10, 00.00 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
02.40 Сериал «МЕЧ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.20 «Понять. Простить» 16+
13.25 «Порча». «Плесень» 16+
13.55 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.05 «ВСЁ К ЛУЧШЕМУ» 16+
19.00 «КОГДА УМРЁТ ЛЮБОВЬ» 16+
22.45 «Порча». «Фатальная ошибка» 16+
23.50 «Знахарка» 16+
00.25 «Верну любимого» 16+
00.55 «Понять. Простить» 16+
01.45 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
02.35 «Тест на отцовство» 16+
04.15 «Давай разведёмся!» 16+
05.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. ЛИСЬЯ НОРА». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 23.25 «ВАРИАНТ «ОМЕГА». 1-я серия 12+
10.45, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25, 15.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!» 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Битва оружейников». Док. сериал. «Многоцелевые атомные подводные лодки. Проекты 671 и 705 против «Трешер» и «Стёджен» 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Русский казак Реза Шах Пехлеви» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
00.50 «20 ДЕКАБРЯ». 1-я и 2-я серии 12+
03.00 «Перелом. Хроника Победы». Док. сериал 16+
03.25 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!». 1-я и 2-я серии 16+

20 декабрь | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «СВОЙ ЧУЖОЙ СЫН» 12+
11.00 «Азбука долголетия» 6+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «25 НЧЕ СӘГАТЬ» (Татар телендә) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – Казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «АЛМАШ» 12+
21.00 «Соотечественники» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Алтер Литвин. Реабилитированный дважды 12+
00.40 «Рыцари вечности». Муса Джалиль 12+
00.55 «Фолиант в столетнем переплете». О фонде филолога- слависта Петровского 12+
01.10 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
12.35 «Ватандашлар» 6+
15.30 «Татар халык җырлары» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
18.50 «Яшәргә дә әле, яшәргә». Зөһрә Шәрифуллина концерты 6+
21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «КАЗАНОВА В РОССИИ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 «Бомба. Наши в Лос-Аламосе» 16+
00.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Елена Яковлева, Сергей Перегудов, Александр Балуев, Ирина Таранник, Александр Дзюба. «ДАМА С СОБАЧКОЙ» 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 «Судьба человека» 12+
04.00 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 16.20 Новости
07.05, 14.25, 21.50, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00, 04.45 Специальный репортаж 12+
10.25 Профессиональный бокс. IBA Champions' Night. Баходир Жалолов против Даниса Латыпова. Трансляция из ОАЭ 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «География спорта. Катар» 12+
13.50, 05.30 «Футбол на все времена» 12+
16.25 «Ты в бане!» 12+
16.55 Борьба. Борцовская Лига Поддубного. Прямая трансляция из Киргизии
19.00 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Динамо» (Москва) – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция
22.55 Футбол. Кубок Испании. 1/32 финала. «Сестао Ривер» – «Атлетик». Прямая трансляция
01.50 Смешанные единоборства. UFC. Джаред Каннонир против Шона Стрикланда. Трансляция из США 16+
02.55 Новости 0+
03.00 «Мэнни». Док. фильм 16+
05.00 Матч! Парад 16+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «АДМИРАЛЫ РАЙОНА» (S) 16+
22.10, 00.00 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
00.45 «Основано на реальных событиях» 16+
02.00 Сериал «МЕЧ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.50 «Тест на отцовство» 16+
12.05 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «ВСЁ К ЛУЧШЕМУ 2» 16+
19.00 «ЛЮБОВЬ ПО КОНТРАКТУ» 16+
23.10 «Порча». «Лишённый рода». «Хороший дядя» 16+
00.15 «Знахарка» 16+
00.45 «Верну любимого» 16+
01.15 «Понять. Простить» 16+
02.05 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
02.55 «Тест на отцовство» 16+
04.35 «Давай разведёмся!» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!» 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 23.25 «ВАРИАНТ «ОМЕГА». 2-я серия 12+
10.45, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25, 15.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!» 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Битва оружейников». Док. сериал. «Межконтинентальные баллистические ракеты. Р-7, Р-9А и Р-16 против SM-65 «Атлас» и SM-68 «Титан». Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
00.50 «20 ДЕКАБРЯ». 3-я и 4-я серии 12+
03.00 «Перелом. Хроника Победы». Док. сериал 16+
03.25 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!» 5-я и 6-я серии 16+

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз сигезенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утыз сигезенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
2. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларын раслау турында.
3. «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 354-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 356-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 31 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 358-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 362-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы территориясендә аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турында» 351-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» 364-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
9. «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 9 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 361-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы аерым нигезләмәләренең һәм «Татарстан Республикасында беренче бала тууга (уллыкка алынуга) бәйле рәвештә айлык түләүне билгеләүне һәм гамәлгә ашыруны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану хакында» 365-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. 2023 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы турында.
12. 2023 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы турында.
13. Вәкаләтләре туктатылган Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы таныклыгы турында.
14. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
15. «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
16. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 11.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 195018-8 номерлы федераль закон проекты турында (тимер юллар буенча билгеләнмәгән урыннарда йөргән өчен салына торган административ штрафлар күләмен арттыру өлешендә).
17. «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законның 49 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында (кисәтүдә күрсәтелгән таләпләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар хакында мәгълүмат тапшыру өлешендә).
18. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 15 декабре
№ 1720-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында

«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законының 7^1 статьясы һәм «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Татарстан Республикасы Арча суд районы буенча 1 нче суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруны бер елга отставкадагы судья Вәлиева Гөлназ Дамир кызына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 15 декабре
№ 1721-VI ДС

САЛКЫННАН ДА БУЛА

Салкыннан аллергия башланды. Кышкы чорда бу сүзне еш ишетергә туры килә. Белгечләрнең бер ише аллергиянең мондый төре дә була дип саный. Икенче берләре исә салкыннан аллергия – салкын бизгәгенең халык телендә йөргән атамасы гына дигән фикердә. Бу фикерләрнең кайсы дөрес? Салкыннан да аллергия була аламы? Аны ничек кисәтергә?

КФУ Университет клиникасының аллерголог-иммунологы, медицина фәннәре кандидаты Алия КЛЮЧАРОВА шул сорауларыбызга җавап бирде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Алия Рафаиловна, салкыннан аллергия буламы?

– Фәндә «салкыннан аллергия» дигән төшенчә юк. Ник дигәндә, салкынның аллергенмы-түгелме икәнлеген ачыклау максатыннан бер генә лаборатор тикшерену дә уздырылмаган. Әмма медицинада «салкын бизгәге» дигән күренеш бар. Салкынга чыккач яисә салкын кар, суга кагылгач, кешенең тәнендә кычыткан чаккандагы кебек кабарып чыккан, шешкән урыннар пәйда була. Алар кычытып интектерә. Җылыга кергәч, ярты сәгать эчендә бу билгеләрнең эзе дә калмый. Салкын бизгәге әнә шуннан гыйбарәт.

:: Ул өшүдән нәрсәсе белән аерыла?

– Өшегәндә тән тиресе башта кызара, аннары агарып чыга. Җылытканда ул урын чәнчи, авырта, сүл тулы шарчыклар пәйда була. Бу билгеләр җылыга кергәч тә юкка чыкмый. Тора-бара өшегән урын кубалаклана.

:: Салкын бизгәгенә кемнәр ешрак бирешә?

– Гаиләсендә аллергиядән, кычыткан бизгәгеннән интегүчеләр булган кешеләр аңа ешрак бирешә.

:: Нәрсәдән тыелырга?

– Салкын бизгәге вакытында яңа гына суыткычтан чыгарылган туңдырма, боз, салкын эчемлек һәм ризыклар кулланырга ярамый. Аллергия билгеләре пәйда булса, аллергиягә каршы дару эчәргә кирәк.

САЛКЫН БИЗГӘГЕННӘН САКЛАНУ ӨЧЕН КИҢӘШЛӘР

✸Аңа тиз бирешүчән кешеләргә кыш көне тәнне булдыра алган кадәр каплап йөрергә кирәк. Кышкы киемегез җил һәм су үткәрми торган булсын. Тәнгә сыланып торган эчке киемнең җитен һәм мамык тукымадан булганына өстенлек бирегез;

✸урамга чыгарга ярты сәгать кала аллергиягә каршы дару эчеп, тәннең ачык өлешләренә майлы крем сөртергә, иренгә гигиена иннеге тидерергә дә онытмагыз;

✸салкын яисә кондиционерлы бүлмәдә утыру да файдага түгел. Боз сарае, шугалак, тау, мәгарә, елга буйларында, бассейнда озак булган кешедә дә салкын бизгәге башланырга мөмкин.

Абау!

ТЫЕЛЫРГА ЯРАМЫЙ

Төчкерүдән тыелырга кирәкми, ди белгечләр. Монда эш хәтта авыздан зарарлы матдәләрне куып чыгаруда гына да түгел, ә анда барлыкка килгән һәм тышка чыгарылырга тиеш булган басымның (уртача тизлеге – секундына 100–120 метр!) кабат эчкә кереп, андагы кан тамырларын яки бронхларны зарарларга мөмкин булуында. Төчкерүдән тыелган кешеләрдә еш кына яшь юллары ялкынсына, ишетү каналларына зыян килә, хәтта үңәч бүсере күзәтелүе бар.

Шешенмәс өчен

Шешенүдән котылу өчен, түбәндәге ризыклардан баш тартырга кирәк, ди галимнәр.

✓**Сөт ризыклары.** Гадәти сөтне соя яки миндаль сөтенә алыштырырга кирәк. Каһвә һәм йогыртның да шул сөтләрдән эшләнгәнен алыгыз.

✓**Су.** Организмда суның ким булуы да, артык булуы да файдага түгел. Галимнәр һәркемгә көн саен ярташар литрлы өч шешә суны янында тотарга киңәш итә.

✓**Спиртлы татлы эчемлекләр.** Коктейльләрдәге артык баллы сироп өстәмә шешенүгә китерә.

✓**Ак дөге.** Аны, иң яхшысы, коңгырт дөге белән алыштырыгыз. Чөнки коңгыртында файдалы минерал һәм витаминнар күбрәк.

✓**Тозлы ризыклар**ны чама белән ашагыз. Бутерброд эчендәге кечкенә бер тозлы кыяр зыян китермәс, билгеле, ә инде бер утырганда ярты банканы бушатсагыз, иртәнгә битегез шешенеп чыгуы бар.

БУЛМАСЫН АГУ

Күпләр бик күп чирнең дәвасын дару үләннәреннән таба. Ләкин алар да, дару кебек, белмичә кулланса, агуга әверелергә мөмкин.

➤Алоэ согын авырлы хатыннарга, геморрой, бөер авыруларыннан интегүчеләргә кулланырга ярамый.

➤Гранат согы теш эмален боза һәм ашказанын ялкынсындыра.

➤Сары мәтрүшкә кан басымын күтәрә.

➤Житен орлыгыннан сары авыруы (гепатит) һәм холецистит вакытында баш тартырга кирәк.

➤Бөере авырткан, туберкулез диагнозы куелган, йодтан аллергиясе булган кешеләргә диңгез кәбестәсе ашарга ярамый.

Белеп тор!

Кабыгы да шифалы

Мандарин С витаминына бай. Ул сусауны баса, депрессия вакытында бик файдалы. Күңел болганганда да мандарин ашарга киңәш итәләр. Ул кан тамырларындагы холестеринны да киметә. Мандарин табигый антисептик санала. Аның составындагы аскорбин кислотасы иммунитетны ныгыта, клетчатка белән пектин ашкайнату эшчәнлеген яхшырта. Әмма аллергиядән интеккән кешеләргә мандаринны чамасын белеп кенә ашарга киңәш ителә. Ашказаны җәрәхәте булганда, шикәр чире вакытында да мандарин ашарга киңәш ителми.

Бронхиттан. 2 аш кашыгы кипкән мандарин кабыгына 1,5 стакан кайнар су салып, шуны сүлпән утта 5 минут тотарга кирәк. Аннары аны уттан алып, бер сәгать төнәтәсе. Әлеге төнәтмәне ашарга ярты сәгать кала, җылытып, көнгә өч тапкыр яртышар стакан эчегез.

Салкын тигәннән. Бер уч кипкән мандарин кабыгына кайнар су коеп, тар авызлы савытка салып, 10 минут буе шуның парын иснәгез. Әлеге процедурадан соң бер сәгать буе урамга чыгарга ярамый. Фитонцидка бай мандарин пары инфекцияләрне тиз арада куа.

Аяк табаны гөмбәчегеннән. Мандарин кабыгы белән тырнакларны һәм бармак араларын көнгә ике тапкыр ышкырга кирәк.

Хәлсезлек һәм йокысызлыктан. Мандарин кабыгын вак-вак кисәкләргә бүләләп, пакетка салыгыз да 15 минут иснәгез. Ул шулай ук баш авыртуларыннан да коткара. Цитрус исе һәм эфир майлары арыганлыкны бетерә, стресстан коткара, тынычландыра һәм йоклап китәргә булыша.

Үзем сынадым

Ашказаны авыртса

Соңгы арада ашказаны җәрәхәтеннән түбәндәге төнәтмәнең файдасын күрәм. Аны ясау өчен 1 литр сөткә 1 стакан солы салып кайнатып чыгарам да шуны 40 минут чамасы пешерәм. Аннары сөзеп, җылы килеш, ашарга 30 минут кала ярташар стакан эчәм. 1–2 ай буе шундый солылы сөт эчсәң, ашказаны җәрәхәте төзәлә, авырту басыла. Аны көн саен яңаны әзерләп эчү яхшы. Кичтән калганын җылыту файдасыз.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

БӘЙРӘМ СЫЕ СЕРЛӘРЕ

Яңа ел табынына гадәттә затлы ризыклар куела. Мәсәлән, кызыл уылдык. Ләкин аның сыйфаты кайчак затсызрак булып чыга. Әйбәт кызыл уылдыкны кайдан табарга һәм ничек сайларга? Шушы сорауга җавап эзләүчеләргә Роскачество белгечләре киңәшләренә таянырга тәкъдим итәбез.

ЯСАЛМА УЫЛДЫК. Кибет-базарларда, чын уылдыкка караганда, охшатып ясалганы (имитированный продукт) күбрәк сатыла. Тышкы «кыяфәт»е чынына охшаш, ә бәясе дистәләрчә тапкыр арзан. Ләкин, белгечләр аңлатуынча, ялган продукт түгел бу. Имитацияләнгән уылдык советлар чорында ук уйлап табылган. Баштарак аны йомырка агына буяп, үсемлек мае өстәп кенә ясаганнар. Вакытлар узу белән, технологиясе камилләшкән. Хәзер имитация-уылдык аксымнан гына түгел, ә желесыман матдәләр (мәсәлән, агар-агар), коңгырт һәм кызгылт төстәге суүсемнәр сыгынтысы, балык ите, шулпа, тоз һәм тәмләткечләр, консервантлар өстәп ясала. Ясалма уылдык тәме ягыннан, әлбәттә, чыныннан нык калыша. Барыннан да элек, бик тозлы булуы белән. Өстенлекләре дә бар анысы: калориясе азрак һәм бәясе күпкә арзанрак. Зур банкаларда сатылуы да шуңа бәйле.

ТАБИГЫЙ УЫЛДЫК. Безнең илдә кызыл уылдыкка өстенлек бирелә. Ә ул сөләйман балыклардан (лосось) алына. Балыкның бер төре генә түгел, ә тулы бер семьялыгы ул. Аңа горбуша, кета, форель, кижуч, нерка, чавыча керә. Шуңа күрә банкасына тәгаен төре, әйтик, «Икра горбуши» дип язылганын алу хәерле. «Лососевая» дип кенә күрсәтелсә, берничә төрен кушып ясалган дигән сүз. Ә бу, әлбәттә, ризыкның сыйфатын киметә.

Кижуч уылдыгы иң тәмлесе һәм туклыклысы булып санала. Уылдык бөртекләре куе кызыл төстә, әчкелтем. Горбуша икенче урында: уылдык бөртекләре эрерәк, әфлисун төсендәрәк. Элпәсе йомшаграк булу сәбәпле, тиз шартлый, шуңа күрә банкада сыеклыгы күп булырга мөмкин. Кета балыгы уылдыгы – иң каты, форель уылдыгы – иң вак.

ҖИТЕШТЕРҮ УРЫНЫ ҺӘМ ВАКЫТЫ. Сыйфатлы уылдык кызыл балыкны тоту урынында җитештерелә. Россиядә бу – Япон, Охот һәм Баренц диңгезләре. Берочтан җитештерү вакытына да игътибар бирү зыян итмәс. Иң яхшысы – сөләйман балыкның уылдык чәчү айларына туры килүе. Балык түренә карап, май уртасыннан октябрь – декабрьгә кадәрге чор бу. Әйтик, июльдә җитештерелгән уылдык яңа тотылган балык уылдыгыннан ясалган, дигән сүз. Башка вакыт күрсәтелсә, катырылган уылдык кулланылганын аңлата.

БӘЯСЕ. Чын уылдык арзан була алмый. Ләкин беренче сортлы табигый продукт урынына төрле уылдыктан ясалган икенче сортлы катнашма да «төртергә» мөмкиннәр. Калай банкадагы уылдыкның нинди икәнен күреп булмый. Шуңа күрә пыяла банкадагысын яки үлчәп сатыла торганын алу хәерлерәк. Анда сыекчасының күпме булуы да, башкасы да күренәчәк. Сыекчасы 5 проценттан артмаска тиеш, юкса суы өчен түләгән булып чыгабыз.

ӨЙДӘ НИЧЕК ТИКШЕРЕРГӘ? Әлбәттә, имитация-уылдыкны табигые буларак сату очракларына юлыгырга да туры килгәли. Шулаймы-түгелме икәнлеген бары тик өй шартларында гына тикшереп карарга мөмкин. Моның өчен ярты чәй кашыгы чамасы уылдыкка кайнар су агызырга кирәк. Табигый булса, аксымы (ә чын уылдык асылда шуннан тора) оеп төшү сәбәпле, суда ак «күбәләк»ләр барлыкка киләчәк. Ясалма уылдык икән, су кызгылт төскә керәчәк.

КАЙДА СИН, КРАБ?

Яңа ел – салатлар һәм тәмле кабымлыклар чоры да. Аларның кайберләре краб таякчыкларыннан ясала. Ләкин таякчыкларда крабның «к» хәрефе дә юк, алар ак балыктан җитештерелә. Өстендәге кызгылт төсе генә краб кыскычларын хәтерләтә. Әлеге дә баягы – сыйфатлысын ничек сайларга?

Инде әйткәнебезчә, ризык гадәттә тәрәч балыгы (треска) фаршыннан (сурими) ясала. Җитештерүчеләр шуңа тагын байтак кына «химия» өсти. Кайвакыт таякчыкларда балык фаршы 25–30 проценттан артмый. Шуңа күрә иң элек составына игътибар итәргә кирәк. Беренче итеп нәкъ менә сурими күрсәтелү продуктның сыйфатлы булуын аңлата. Икенче урында икән, сыйфаты ташка үлчим дәрәҗәсендә генә. Составына соя аксымы, крахмал кергән таякчыкларны да читләтеп үтү хәерле.

Тест

АКЧА ЯГЫ НИЧЕК БУЛЫР?

Яңа ел төнендә Курантлар сукканда, күпләребез хыял түрләрендәге теләкләренең чынга ашуын тели. Алар исемлегендә беренче урынга сәламәтлек чыкса, икенчесе, әлбәттә, финанс хәленә бәйле. Бәхет акчада түгел, дисәләр дә, ул булса, яшәү күпкә күңелле. Шуны истә тотып, «1000 советов» журналыннан гади генә тест тәкъдим итәбез.

Үзегез сайлаган чыршыга сугылган тәртип номерына карап, аның нәрсәләр вәгъдә иткәнен укыгыз.

1. Көтмәгәндә акча ишелеп керер. Мирас, зур күләмдә премия яки хәтта лотерея отышы булырга мөмкин бу.

2. Финанс мәсьәләсендә барысы да көйле генә барыр. Иң мөһиме – зур процентларга өметләнеп, акчаны каядыр урнаштырудан сак булыгыз.

3. Акча табу өчен җиң сызганып эшләргә туры килер. Әмма хезмәтегез югары бәяләнер.

4. Матди хәлегез яхшырыр. Өстәмә акча эшләү чыганагы табылыр яки карьера баскычыннан югарырак күтәрелү мөмкинлеге килеп чыгар.

5. Акчагыз сәяхәтләргә дә, башкасына да җитәр! Матди өлкәгә бәйле барлык хыялларыгыз тормышка ашар.

6. Кыйммәтле әйберләр сатып алуны кичектереп тору хәерле. Кыскасы, акчаны кысыбрак тоту кирәк булыр.

7. Акчаны юкка исраф итмәскә тырышыгыз! Әмма бик шәп матди мөмкинлекне дә кулдан ычкындырмагыз.

8. Мошенниклардан сак булыгыз, финанс хәлегезне какшатырга мөмкиннәр. Бигрәк тә – елның беренче яртысында.

9. Бу елда барысы да шома, көйле барыр. Зур чыгымнар көтелми. Акчага интекмичә, рәхәтләнеп яшәрсез.

10. Акча җыярга өйрәнерсез һәм кыйммәтле зур әйбер сатып алырсыз.

11. Акчага бәйле беренди кыенлык кичермәссез. Күңелегез нәрсә тели, шуны сатып алу өчен мөмкинлекләрегез читтән ашар.

12. Озакламый акчалы өстәмә эш тәкъдим итәрләр. Үз эшегезне уңышлы башлап җибәрүегез дә бар.

Тәмле булсын!



«КЫШ БАБАЙ БИЯЛӘЕ»

Нурлисә ШИҺАПОВАдан краб салаты рецепты

Кирәк: *2 кап краб таякчыгы, 5 пешкән йомырка, 1әр банка (кечкенә) яшел борчак һәм кукуруз, ярты стакан пешкән дөге, укроп, майонез, тәменчә тоз.*

Краб таякчыкларының кызгылт өлешен, шулай ук йомыркаларның агын салатны бизәү өчен читкә куеп торабыз. Крабның ак өлешен һәм йомырка сарысын турап (яки уып), тирән эчле савытка салабыз. Башка ингредиентларны өстәп, салат ясыйбыз. Болгатып, салатны яссы тәлинкәгә бияләй рәвешенә китереп урнаштырабыз. Крабның кызгылт өлешен угыч аша уып, «бияләй» өстенә сибәбез. Йомырка агын уып, «кайма»сын куябыз. «Кыш бабай бияләе» әзер!

САБЫЙДАЙ САФ ИТКӘН СӘФӘР

Хаҗ кылу – исламның биш баганасының берсе. «Әл-Гыймран» сүрәсенең 97 нче аятендә: «Көче җиткән кешеләргә, Аллаһыга гыйбадәт өчен, хаҗ кылу фарыз булды», – диелә. Хаҗ кылу без – мөселманнар өчен тагын кайсы ягы белән әһәмиятле? Башкалар өчен дә хаҗ кылу рөхсәт ителәме?

«Рөстәм» мәчете имам-хатыйбы Исмәгыйль хәзрәт БИККИНИН белән шул хакта сөйләшәбез.

:: Исмәгыйль хәзрәт, сүзебезне хаҗ кылуның мөселманнар өчен ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын ачыклаудан башлыйк әле.

– Мөэмин мөселман өчен хаҗ ул – фарыз гамәл, ислам диненең бер баганасы. Ислам диненең күркәмлеген, аның мәгънәсен ача һәм мөселманлыкның куәтен күрсәтә торган гамәл. Калган фарыз гамәлләр кебек үк хаҗның төп максаты да Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешү, хаталарыбыздан пакь булу һәм җәннәткә ирешүдән гыйбарәт. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлләм бер хәдисендә: «Кем хаҗны үтәсә һәм шушы вакытта тартышу, талашулардан ерак торса, йортына яңа туган сабый сыман кайтыр», – диелә. Шәригать ягыннан караганда хаҗ ул – Мәккә, Гарәфә, Мөздәлифә, Мина җирлекләрендә махсус барып, Зөлхиҗҗә айларында гыйбадәт кылу.

:: Зур һәм кече хаҗның кайсы саваплырак?

– Савапны Аллаһы Тәгалә бирә. Аңа кешенең ни дәрәҗәдә ирешә алуын да бер ул гына белә. Шулай да фарыз гамәлләр дәрәҗәлерәк санала. Аның өчен кеше җәннәткә эләгә, хата-кимчелекләре гафу ителә. Хаҗ – безгә фарыз гамәл. Гомрә, ягъни кече хаҗ безгә сөннәт булып тора. Пәйгамбәребез: «Гомрәдән – гомрәгә, хаҗдан хаҗга үтәү кешенең хаталарын гафу итә. Шул ук вакытта аның фәкыйрьлеген юкка чыгара», – ди.

:: Үзең өчен генә түгел, башкалар өчен дә хаҗ кылу рөхсәт ителәме?

– Әгәр кеше үзе исеменнән гомрәне яки хаҗны үтәгән булса, киләсе елга туганы, кардәше, ягъни башка кеше исеменнән кыла ала. Ихрам хәленә кергәндә ул: «Я Раббым, ошбу хаҗны фәлән туганым, фәлән дустым исеменнән үтәргә ният кылдым», – дип ниятләргә тиеш.

:: Бурычка акча алып, яки кредит рәсмиләштереп, хаҗга бару – дөрес гамәлме?

– Аллаһы Тәгалә хаталардан, кимчелекләрдән пакь һәм бездән дә шундый хәрамсез гамәлләрне генә кабул итә. Әгәр кеше, кредит алып, хаҗ кылырга ниятләсә, аның хаҗы дөрес булмый. Кредит рәсмиләштерү, процентка акча алу динебездә катгый тыела. Әгәр кеше хаҗга барырга дип акча алып торган акчасын тиз арада кайтарырлык булса, ул очракта бу гамәл рөхсәт ителә. Әгәр ул аның өстенә зур йөкләмә булып ятса, ул вакытта бурычка акча алып сәфәргә чыгудан тыелырга кирәк. Көчең җитми икән – хаҗ кылмыйсың. Шул гына.

:: Хаҗ кылганда вафат булган кеше җәннәткә эләгә, дигән ышану яши. Бу сүзләр дөреслеккә туры киләме?

– Хаҗ кылганда вафат булган кеше гыйбадәттә үлгән санала. Аллаһы Тәгалә каршында алар зур дәрәҗәдә. Әгәр алар хаҗны ахырына кадәр үтәп бетермичә вафат булсалар, ул вакытта алар ихрам хәлендә күмелә. Пәйгамбәребез хәдисендә: «Алар кыямәт көнендә тәлбияләр (хаҗиларның зекерләре. – **Ред.**) әйтеп уяначак», – ди. Әгәр Аллаһы Тәгалә кешенең хаҗын кабул итсә, ул һичшиксез җәннәткә эләгә. Кеше әлеге изге сәфәрнең тәртипләренә өйрәнеп, анда барырга әзерләнә башлагач ук, хаҗга аяк баскан булып тора. Ул шушы вакытта вафат булса да, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешеп, җәннәткә эләгәчәк.



ХАҖ КЫЛЫРГА ҖЫЕНГАН КЕШЕ НӘРСӘЛӘРНЕ БЕЛЕРГӘ ТИЕШ?

✓Иң элек кешенең күңелендә ният булырга тиеш. Хаҗ ул – ял итеп кайту түгел, Аллаһы Тәгаләнең кушканын үтәү һәм киләчәктә аның әҗер-савабына өмет итү.

✓Кеше изге Мәккә шәһәренә бара һәм үзен әхлаклы рәвештә, чын мөселманча тотарга тырыша. Ник дигәндә, ул хаҗны кимчелексез, артык сүзсез, талашсыз үткәрә алса гына, аның дәрәҗәсенә, хаталарның гафу кылынуына ирешә ала.

✓Хаҗ кылу – сау-сәламәт, балигъ, үз акылында һәм юл чыгымнарын күтәрергә мөмкинлеге булган һәр мөселманның бурычы.

✓Дөньяви яктан карасак, хаҗ кылырга җыенган кешегә иң элек үзенең сәламәтлеген кайгыртырга кирәк. Хаҗ кылу өчен, кешенең ун ел гамәлдә булган биометрик чит ил паспорты да булырга тиеш.

:: Хаҗдан алып кайткан зәмзәм суын башка кешегә бүләк итү яки сату гөнаһ түгелме?

– Зәмзәм суы – Кәгъбәтулла каршында булган бер кое, изге чишмә. Исмәгыйль галәйһиссәләмнең аяк астыннан чыккан бер урын булып тора. Пәйгамбәребез үзенең бер хәдисендә: «Зәмзәм суы – сезгә эчемлек тә, ризык та», – ди. Бер сәхабә: «Мин Мәккә шәһәрендә яшәгәндә, пәйгамбәребезне көткән вакытта ашарга ризыгым юк иде, зәмзәм суын гына эчеп яшәдем. Ябыкмадым да, киресенчә, тәнемне ныгытып та җибәрдем», – дигән. Зәмзәм суы – хаҗиларның бер бүләге. Мәккәдән тагын нәрсә алып кайта аласың? Анда таш һәм чүл генә бар. Әмма без анннан менә шушы зәмзәм суын алып кайта алабыз. Шул рәвешле без аны кешегә бүләк итеп бирә алабыз. Аны сатарга да ярый. Галимнәр: «Әгәр кеше суны шешәләргә җыеп алса, ул аның хуҗасына әйләнә һәм аны сата да ала. Зәмзәм суы да искәрмә түгел. Монда аның хезмәте куела», – диләр. Дөрес, араларында, мөселманнарның хисләреннән файдаланып, зәмзәм суы дип ялган су сатучылар да бар. Бу – зур гөнаһ.

КОРЪӘНИ КӘРИМНЕ УКЫГАНДА ӘЧКЕ ӘДӘПЛӘР

1. Коръәни Кәримне бирелеп, мәгънәсенә төшенергә тырышып, фикерләп уку һәм аның белән гамәл кылырга тырышу. Раббыбыз Аллаһы Үзенең Изге Китабында болай дип әйтә: «[Коръәни Кәрим] Мөбарәк бер Китап ки, аны сиңа алар аның аятьләре хакында уйласыннар һәм [нәфесләренең бозык теләкләреннән арынган] аек акылга ия булганнар үгетләнсен дип индердек». «Сад», 38:29.

2. Коръәни Кәримне укыганда, аның кеше сүзе түгел, Аллаһы сүзе икәнлеген истә тотып уку.

3. Коръәни Кәримне төп максатын белеп уку, ягъни бу Китап савапка ирешер һәм гыйбрәт алыр өчен укыла.

4. «Мин инде Коръәни Кәримне шәп укыйм», – дип масаймау, тәкәбберләнмәү, бәлки, киресенчә, түбәнчелек белән укып, нәфесеңне тәрбияләү.

5. Коръәни Кәримне укыган кешене тыңлаганда аясә ишеткәндә, сөйләшмәү, игътибар белән тыңлап, калеб белән фикерләү. Коръәни Кәримдә Хак Тәгалә болай дип әйтә: «Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез [Аллаһы тарафыннан] рәхмәт ителерсез». «Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204.

6. Коръәннән булдыра алган хәтле ятлау һәм ятлаганын онытудан саклану, чөнки Коръәни Кәримне ятлау – сөннәт гамәл, ә ятлаганыңны онытмау – вәҗиб.

7. Коръәни Кәримне укыганнан соң дога кылу.

Бер уч туфрак

Бер адәм диңгез буенда кармак белән балык тота икән. Шуннан үтеп баручы патша аңа якын килә һәм болай ди: «Кармагыңа беренче нәрсә эләксә, аның авырлыгы кадәр алтын бирермен».

Бераздан кармакка бер сөяк эләгә. Хөкемдар балыкчыга: «Нишләмәк кирәк, кармагыңа авыррак нәрсә эләкмәде», – ди дә аның белән сараена китә. Сарайда сөякне үлчәүгә куялар. Икенче ягына алтын акчалар тезәләр: биш, ун, егерме, илле… әмма үлчәүнең сөяк салынган ягы барыбер дә кыймылдамый. Өстән караганда күп булса 4–5 алтын тәңкә авырлыгы кадәр сөяккә аңа караганда уннан артык алтын куялар, үлчәү тәлинкәсе тула, ә сөяк һаман кыймылдамый да.

Бер галимне чакырып, моның серен сорарга булалар. Ул, сөякне кулына алып, бер карый һәм болай ди: «Бу сөяк – саран кешенең күз чокырыдыр. Бөтен хәзинә куйсагыз да кыймылдамас, чөнки ул туймас. Әмма бер уч туфрак аны тутырыр».

Чыннан да бер уч туфракны үлчәүнең икенче ягына салгач, сөяк тәлинкәсе калкып, өскә күтәрелә.

Йәгез, бер дога!

ЗОЛЫМГА КАРШЫ УКЫЛА

«Раббәнә әхриҗнә мин һәзиһ илкарйәт из-залим әһлүһә үә-җгаль ләнә мин ләдүнкә үәлийән үәҗгаль ләнә мин ләдүнкә нәсыйрән».

Мәгънәсе: «Безгә явыз халык җиреннән китәргә мөмкинлек бир, Синең теләгән сакчыны, кайгыртучыны бир!»

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Ә син таныйсыңмы?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук. Тулы, дөрес итеп беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

Газетабызның узган санында чыккан җырчы һәм җырларны беренчеләрдән булып Арчадан ***Зөлфия Галәветдинова*** *танып алды. Афәрин! Бүләк – хуҗасында. Ә рәсемнәр астына Дилә Нигъмәтуллина башкаруындагы «Ком сәгате», Салават Фәтхетдиновның «Яратмасаң, яратырсың», Ришат Төхвәтуллин репертуарыннан «Аккошлар мәхәббәте» җырларын яшергән идек.*

Җырчы йөрәге түрендә яшәүче бераүне гомере буена җиллләрдән ышыкларга, күкне болытлар капласа, кояш булып балкырга вәгъдә бирә.

Синең белән очрашу аңа яратуның нинди икәнен белергә дә, бәхетен табарга да ярдәм иткән.

Бу җыр ике гашыйкның зифа буйлы агач утыртып, аннан шул агач төбендә аерылышулары турында. Җырчы ул агачтан гафу үтенә, рәнҗемәскә куша.

ДИНАРА ЗИННӘТОВА:

«ЮМОРДА ҺӘРКЕМ ҮЗ ЧИГЕН ҮЗЕ БИЛГЕЛИ»

Бүген без сәхифәбезгә кунакка социаль челтәрләрдәге «Че гуглит татар кызы» проектына нигез салучы, «Кара» проекты авторларының берсе, стендап-комикесса Динара ЗИННӘТОВАны дәштек. Татар интернетында бүген ниләр бар? Стендап – татарлар өчен яңа жанрмы? Татар юмористлары сәяси темаларга шаярамы? Без әнә шулар турында сөйләштек.

:: Ни хәл?

– Тәртип. Бу арада «Шалт, Мөхәммәтҗан» проектын төшереп мәш киләбез. Соңгы яңалыклардан – «Кара» проекты (татар телендәге мемнар. – **Авт.**) «Хатлар йорты» белән берлектә дүрт тәбрикләмә чыгарды. Гомумән, көндезге сәгатьләрем төп эшемдә – IT компаниядә узса, кичләрем «Че гуглит татар кызы» өчен постлар язып, «Кара» проекты авторлары белән фикер алышып, кыскасы, татар мохитендә үтә.

:: Килешәсеңдер, соңгы арада татар интернеты шактый үзгәрде, үзебезнең «тренд»лар барлыкка килә башлады.

– Әйе, чыннан да. Аерым алганда, интернеттагы юмор һәм, гомумән, татар юморы шактый үзгәрешләр кичерде. 2022 ел күпләр өчен борчулар елы булып истә калачак. Менә шушы шартларда кешеләр ниндидер тотрыклылык, бердәмлеккә, үзеңне өйдәге кебек хис итә торган юморга күбрәк тартылды. Гомумән, миңа калса, татарча юмор – кешеләргә гаилә мохите, җылылык бирә торган әйбер ул. Нәкъ менә гаилә һәм Татарстанда үзгәрми торган башка кыйммәтләргә бәйле юмор актуальрәк хәзер.

Юмордагы тагын бер «тренд» – борчулар һәм катлаулы ситуацияләрдән көлү. Нинди генә катлаулы ел булмасын, акылдан язмас өчен, без авырлыклардан көлә дә белергә тиеш. Кыен хәлләр, авыр кичерешләргә юмор күзлегеннән карыйбыз икән, безгә алар аша узу җиңелрәк булачак. Ничек кенә кыен булса да, тормышның матур якларын таба белү мөһим. Бүгенге юмор, шул исәптән, татарча юмор да шушы якка борылды һәм шушы функцияне үти башлады.



:: Алай да, татарча юмор юк ул, диючеләр табыла бит. Аны еш кына «Мунча ташы» белән чиклиләр.

– Кем әйтә икән аны? Миңа калса, ул инде күптәннән бар, бу турыда бәхәсләшүдән мәгънә юктыр. Аның форматлары да төрле. «Мунча ташы» узган гасырның 90 нчы елларында актуаль иде. Аны да бит бер генә түгел, әллә ничә формат кулланып эшләделәр. Хәзер инде форматлар тагын да күбрәк. Видео һәм телевизион тапшырулар форматында шактый гына проектлар тормышка ашырыла. Текст рәвешендәге юморга да мисаллар җитәрлек. Шул ук «Че гуглит татар кызы» һәм аңа охшаган башка проектлар. Хәтта рус телле медиа чаралары, әйтик, «ENTER» интернет-журналы кебек чыганаклар да татар юморын еш куллана.

:: Интернеттагы татарча юмор аша яшьләрдә татар теленә мәхәббәт уятып буламы?

– Әлбәттә. Безнең «Кара» проекты моны дәлилли. Гомумән, бу проектның төп максаты һәм функциясе – үзләренә якын булган форматлар ярдәмендә яшьләр арасында татар теленә мәхәббәт уяту. Соңгы арада, күпме генә пост чыгарсак та, һәркайсына бик күп яхшы фикерләр калдыралар, үзләренең сәхифәләренә урнаштыралар. Хәтта татар телен аңламаучы кешеләр дә тәрҗемәсен сорап яза башлады.

:: Син стендап жанрында чыгыш ясыйсың. Безнең өчен чагыштырмача яңа жанр. Әллә мин ялгышаммы?

– Аның сүзе генә яңа. Ул үзе татарларда электән үк бар инде. Әлеге дә баягы «Мунча ташы»н, йә булмаса, Җәвит Шакировны гына искә алыйк. Ул да, аягүрә басып, мәзәкләр сөйли иде. Яисә Салаватны (Фәтхетдинов. – **Авт.**)

алыйк. Әле бер көнне генә, ялгышмасам, 1998 нче елгы концертыннан видеоязма карадым. Ул да анда җырлары арасында ниндидер кызыклы хәлләр сөйли, шаярта. Моны да стендап форматына кертергә була, минемчә. Стендап та тормыш турында шаярудан гыйбарәт бит.

:: Синең чыгышларың күбесенчә татарларның үзенчәлекләре турында дип аңладым. Ул чыгышлар ничек языла? Нәрсәгә таянасың син?

– Тормышта булган хәлләргә нигезләнәм. Андый хәлләр булган саен, аларны йә теркәм куям, йә мәзәген язганда искә төшерергә тырышам. Мин бит инде – татар мохитендә үскән, һәр җәен авылда уздырган бала, андый хәлләр шактый искә төшә.



«Кара-журнал»

:: Татар комиклары, республика җитәкчеләренә пародияне исәпкә алмаганда, сәясәт темасына шаяртамы?

– Сәясәт турындагы шаяртулар күп түгел, аларны гадәттә камерага төшерелми торган «ачык микрофон» форматындагы кичәләрдә ишетеп була. Бу тема белән күпләр саграк булырга тырыша, бигрәк тә бүгенге вазгыятьтә. Аннан соң, тамашачылар да бит юмор кичәләренә ял итәргә килә, сәяси яңалыкларны алар өйдә дә укып-карап туйган.

ӘҢГӘМӘНЕҢ ТУЛЫ ВАРИАНТЫ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

21 декабрь | Чәршәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «СВОЙ ЧУЖОЙ СЫН» 12+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «25 ННЕ СӘГАТЬ» (Татар телендә) 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Если хочешь быть здоровым» 12+
14.15 «Туган авылым» 6+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бәргәләп өйрәник» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Локомотив» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Спортивная среда» 6+
00.20 «Соотечественники». Фешин. Монолог художника 12+
00.45 «Рыцари вечности». Пушкинское общество XIX века в Казани 12+
01.00 «Фолиант в столетнем переплете». К 355-летию Дж.Свифта 12+
00.15 «Таяну ноктасы» 16+
01.45 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җавит» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ» 12+
08.40, 23.05, 05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+
09.40 «Ачыктан-ачык» 12+
10.40 «Туган авылым» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
12.35 «Ватандашлар» 6+
15.30, 00.15 «Яшьләр тукталышы» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Уткәннәр сагындыра» 6+
18.50, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» 12+
04.20 «Әниемнең җылы кочагы» 6+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «КАЗАНОВА В РОССИИ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 «Без права на славу» 16+
00.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Елена Яковлева, Сергей Перегудов, Александр Балуев, Ирина Таранник, Александр Дзюба. «ДАМА С СОБАЧКОЙ» 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
04.00 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 16.20, 18.30 Новости
07.05, 14.25, 18.35, 21.50, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00 Специальный репортаж 12+
10.25 Профессиональный бокс. Теренс Кроуфорд против Давида Аванесяна. Бой за титул чемпиона мира по версии WBO в полусреднем весе. Трансляция из США 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «Вид сверху» 12+
13.50, 05.30 «Футбол на все времена» 12+
16.25 Профессиональный бокс. Алексей Мазур против Павла Маликова. Прямая трансляция из Москвы
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. СКА (Санкт-Петербург) – ЦСКА. Прямая трансляция
22.55 Футбол. Кубок Испании. 1/32 финала. «Хувентуд Торремолинос» – «Севилья». Прямая трансляция
01.50 Профессиональный бокс. IBA Champions' Night. Баходир Жалолов против Даниса Латыпова. Трансляция из ОАЭ 16+
02.55 Новости 0+
03.00 Лёгкая атлетика. Всероссийские соревнования на призы Ирины Приваловой. Трансляция из Москвы 0+
05.00 «География спорта. Катар» 12+

НТВ
04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «АДМИРАЛЫ РАЙОНА» (S) 16+
22.10, 00.00 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
00.45 «Основано на реальных событиях» 16+
02.15 Сериал «МЕЧ» (S) 16+
04.30 «Их нравы» 0+

ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.10 «Давай разведёмся!» 16+
10.10 «Тест на отцовство» 16+
12.25 «Понять. Простить» 16+
13.30 «Порча». «На волоске» 16+
14.00 «Знахарка» 16+
14.35 «Верну любимого» 16+
15.05 «КОГДА УМРЁТ ЛЮБОВЬ» 16+
19.00 «ЛЮБОВЬ С ЗАКРЫТЫМИ ГЛАЗАМИ» 16+
22.55 «Порча». «Ранящий до крови». «Кормящая мать» 16+
00.00 «Знахарка» 16+
00.30 «Верну любимого» 16+
01.00 «Понять. Простить» 16+
01.50 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
02.40 «Тест на отцовство» 16+
04.20 «Давай разведёмся!» 16+
05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.10 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!» 7-я и 8-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 23.25 «ВАРИАНТ «ОМЕГА». 3-я серия 12+
10.45, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25, 15.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. КРЫМ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Битва оружейников». Док. сериал. «Ракетные крейсеры. Проекты 58 и 1134 против «Леги» и «Белкнап». Премьера! 16+
19.40 «Секретные материалы». Док. сериал 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
00.45 «СИЦИЛИАНСКАЯ ЗАЩИТА» 12+
02.10 «Нюрнберг». Док. сериал 16+
03.30 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. КРЫМ». 1-я и 2-я серии 16+

22 декабрь | Пәнҗешәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 16.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «СВОЙ ЧУЖОЙ СЫН»12+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 17.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «25 ННЕ СӘГАТЬ» (Татар телендә) 16+
13.00 «Кәмит Җавит». Юмористик тапшыру 16+
14.00 «Туган авылым» 6+
14.15 «Рыцари вечности» 12+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Алты хәреф» 0+
17.30 «Трибуна «Нового Века» 12+
19.00 «Точка опоры» 16+
20.00 «АЛМАШ» 12+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Муса Гареев. Дважды герой 12+
00.40 «Рыцари вечности». Корней Чуковский 12+
00.55 «Фолиант в столетнем переплете». К 125-летию И.Ильфа 12+
01.10 «Ком сәгате» 12+
02.05 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Башваткыч» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 18.20, 21.25 «АЛМАШ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Кәмит Җавит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БиТ шоу» 12+
10.40 «Туган авылым» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Таяну ноктасы» 16+
12.35 «Ватандашлар» 6+
15.30, 00.15 «Халкым минем» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Уткәннәр сагындыра» 6+
18.50, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 ТВ фондыннан. «Утырып уйлар уйладым». Харис Якупов 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «КАЗАНОВА В РОССИИ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 «Горячий лед». Чемпионат России по фигурному катанию. Мужчины. Короткая программа. Пары. Короткая программа (S) 0+
01.15 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Елена Яковлева, Сергей Перегудов, Александр Балуев, Ирина Таранник, Александр Дзюба. «ДАМА С СОБАЧКОЙ» 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
04.00 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 16.20 Новости
07.05, 14.25, 19.15, 21.50, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00 Специальный репортаж 12+
10.25 Karate Combat 2022. Трансляция из США 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20 «Что по спорту? Кемерово» 12+
13.50, 05.30 «Футбол на все времена» 12+
16.25 «География спорта. Катар» 12+
16.55 Хоккей. OLIMPBET Чемпионат МХЛ. МХК «Динамо» (Москва) – «СКА-Варяги» (Ленинградская область). Прямая трансляция
19.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Локомотив-Кубань» (Краснодар) – «ПАРМА-ПАРИ» (Пермский край). Прямая трансляция
22.55 Футбол. Кубок Испании. 1/32 финала. «Арентейро» – «Атлетико». Прямая трансляция
01.50 Профессиональный бокс. Теренс Кроуфорд против Давида Аванесяна. Бой за титул чемпиона мира по версии WBO в полусреднем весе. Трансляция из США 16+
02.55 Новости 0+
03.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Астана» (Казахстан) – УНИКС (Казань) 0+
05.00 «Ты в бане!» 12+

НТВ
04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «АДМИРАЛЫ РАЙОНА» (S) 16+
22.10, 00.00 Остросюжетный сериал «ПЁС» (S) 16+
00.45 «Поздняков» 16+
01.00 «Мы и наука. Наука и мы» 12+
01.50 Сериал «МЕЧ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.20 «Давай разведёмся!» 16+
09.25 «Тест на отцовство» 16+
11.40 «Понять. Простить» 16+
12.45 «Порча». «Незнакомый человек» 16+
13.15 «Знахарка» 16+
13.50 «Верну любимого» 16+
14.25 «ЛЮБОВЬ ПО КОНТРАКТУ» 16+
18.45 «Спасите мою кухню» 16+
19.00 «НИКОГДА НЕ БЫВАЕТ ПОЗДНО» 16+
22.55 «Порча». «Тяжкое бремя». «Тринадцать бед» 16+
00.00 «Знахарка» 16+
00.30 «Верну любимого» 16+
01.00 «Понять. Простить» 16+
01.50 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
02.40 «Тест на отцовство» 16+
04.20 «Давай разведёмся!» 16+
05.10 «6 кадров» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. КРЫМ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15 «ВАРИАНТ «ОМЕГА». 4-я серия 12+
10.45, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25, 15.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. КРЫМ». 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Битва оружейников». Док. сериал. «Тяжелые истребители. Су-27 против F-15 «Игл» 16+
19.40 «Код доступа» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «ВАРИАНТ «ОМЕГА». 4-я и 5-я серии 12+
02.05 «Нюрнберг». Док. сериал 16+
04.00 «Военный врач Иван Косачев. Две пустыни: огонь и лед». Док. фильм 16+

23 декабрь | Җомга

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести – Татарстан

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 12+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
11.00 «Нәсыйхәт» 6+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «25 ННЕ СӘГАТЬ» 12+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тизрәк! Алга! Житезрәк!» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Аулак өй» 6+
16.30 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Родная земля» 12+
19.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Витязь» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «КВН РТ-2022» 12+
00.00 «БЕЗ ТОРМОЗОВ» 16+
01.30 «Соотечественники». Зарисовки из жизни Хариса Якупова 12+
01.55 «Рыцари вечности». Габдулла Тукай 12+
02.10 «Фолиант в столетнем переплете». Виды Казани, рисованные с натуры 12+
02.25 «Янам мәхәббәт дулкынында». Марат Фәйрушин 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җавит» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
08.00 «Уткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Ком сәгате» 12+
09.40, 15.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казанның – Казанга» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 ТВ фондыннан. «Утырып уйлар уйладым». Харис Якупов 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Уткәннәр сагындыра» 6+
17.30 «Калеб» 6+
18.20 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
19.15 «Родная земля» 12+
19.40 «Заман көзгесе» 6+
20.10, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
21.25 ТВ фондыннан. «Ихлас». Харис Якупов 6+
22.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
00.40 «Калеб» 6+
01.05 З.Хәким. «КАРАК». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.40 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
19.45 «Поле чудес» (S) 16+
21.00 «Время»
21.45 «Голос.Дети». 10-й юбилейный сезон (S) 0+
23.20 «Горячий лед». Чемпионат России по фигурному катанию (S) 0+
00.40 Премьера. «Олег Целков. Единственный из многих» 12+
01.35 Информационный канал» 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.15 Местное время. Вести-Татарстан
21.30 Премьера. «Дуэты» 12+
00.05 «Улыбка на ночь» 16+
01.10 Анна Миклош, Алексей Осипов. «МОЁ ЛЮБИМОЕ ЧУДОВИЩЕ» 12+

МАТЧ ТВ
06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 16.20, 19.20 Новости
07.05, 16.25, 19.25, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 Специальный репортаж 12+
10.25 Смешанные единоборства. UFC. Джаред Каннонир против Шона Стрикланда. Трансляция из США 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00 «Лица страны» 12+
13.20 «Ты в бане!» 12+
13.50, 05.30 «Футбол на все времена» 12+
14.25 Баскетбол. PARI Кубок России. Женщины. «Финал 4-х». 1/2 финала. «Динамо» (Курск) – МБА (Москва). Прямая трансляция из Сыктывкара
16.55 «Что по спорту? Кемерово» 12+
17.25 Баскетбол. PARI Кубок России. Женщины. «Финал 4-х». 1/2 финала. УГМК (Екатеринбург) – «НИКА» (Сыктывкар). Прямая трансляция из Сыктывкара
20.00 Смешанные единоборства. ACA. Алихан Сулейманов против Ислама Омарова. Прямая трансляция из Москвы
23.50 Автоспорт. Российская Дрифт серия. Гран-при 2022. Итоги сезона 0+
01.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Женщины. «Тулица» (Тульская область) – «Динамо» (Краснодар) 0+
02.55 Новости 0+
03.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. МБА (Москва) – ЦСКА 0+
05.00 «Вид сверху» 12+

НТВ
04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» 6+
09.25 «Следствие вели…» 16+
10.35 «Следствие вели…» 16+
11.00 «Дороги будущего». Научное расследование Сергея Малозёмова 12+
12.00 «ДедСад» 0+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «ДНК» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 «АДМИРАЛЫ РАЙОНА» (S) 16+
22.10 «ПЁС» (S) 16+
00.00 «Своя правда» с Романом Бабаяном 16+
01.55 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
02.20 «Квартирный вопрос» 0+
03.10 Сериал «МЕЧ» (S) 16+
04.40 «Их нравы» 0+

ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «ЛЮБОВЬ С ЗАКРЫТЫМИ ГЛАЗАМИ» 16+
19.00 «ЧУЖОЙ РЕБЁНОК» 16+
23.05 «Порча» 16+
00.10 «Знахарка» 16+
00.40 «Верну любимого» 16+
01.10 «Понять. Простить» 16+
02.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
02.50 «Тест на отцовство» 16+
04.30 «Давай разведёмся!» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
06.15 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. КРЫМ». 7-я и 8-серии 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20 «ВАРИАНТ «ОМЕГА». 5-я серия 12+
10.45 «23 декабря – День дальней авиации ВКС России». Док. фильм. Премьера! 16+
11.20 «ОТРЯД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 12+
13.20 «Москва фронту» 16+
13.45, 15.05 «22 МИНУТЫ» 16+
15.00 Военные новости 16+
15.25 «ГОРЯЧИЙ СНЕГ» 12+
18.45 «Битва оружейников» 16+
19.40 «КЛАССИК» 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.00 «Музыка+». Премьера! 12+
00.00 «ТРАКТИР НА ПЯТНИЦКОЙ» 12+
01.30 «НОЧНОЙ ПАТРУЛЬ» 12+

24 декабрь | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Sиңа Миннән Sәлам». Музыкаль котлаулар 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Айдар Шәйхин 12+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Туган авылым» 6+
11.30 «Казаннан – Казанга» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
13.30 «Татар халык җырлары» 0+
14.00 «АЛМАШ» 12+
15.00 Г.Камал. «БАНКРОТ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
17.30 «Татар халык җырлары» 0+
18.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «Кунак БиТ шоу». Илназ Баһ һәм Гүзәл Идрисова 12+
23.00 «РОЖДЕСТВО В ШОКОЛАДЕ» 16+
00.30 «МАРАФОН ЖЕЛАНИЙ» 12+
02.15 «Вехи истории». Начало великих перемен 12+
02.40 «Спортивная среда» 6+
03.05 «Татар халык җырлары» 0+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 Г.Кариев. «АРТИСТ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
07.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым» 6+
13.20 П.Коэльо. «АЛХИМИК». Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театры спектакле 12+
17.10 «Казаннан – Казанга» 12+
17.45 «Халкым минем» 12+
18.15 «Башваткыч» 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Челтер чишмә буенда». Татарстанның халык артисты Асаф Вәлиевнең юбилей концерты 6+
22.50 Т.Миңнуллин. «ШУЛАЙ БУЛДЫ ШУЛ». Салават башкорт дәүләт драма театры спектакле 12+
01.00 З.Хәким. «ЧАПТЫ АТЫМ КАЗАНГА». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
03.00 «Башваткыч» 12+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
05.05 «Халкым минем» 12+
05.30 «Нәсыйхәт» 6+

1 КАНАЛ

06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Премьера. «ПроУют» (S) 0+
11.10 Премьера. «Поехали!» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Премьера. «Бог войны. Укротители огня» 12+
12.55 «Видели видео?» 0+
15.00 «Горячий лед». Чемпионат России по фигурному катанию. Пары. Произвольная программа. Прямой эфир (S)
16.15 «Горячий лед». Чемпионат России по фигурному катанию. Женщины. Произвольная программа. Прямой эфир (S)
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Премьера. «Снова вместе. Ледниковый период» (S) 0+
21.00 «Время»
21.35 «Клуб Веселых и Находчивых». Высшая лига (S) 16+
23.55 Мадонна, Антонио Бандерас. «ЭВИТА» (S) 12+
02.25 «Моя родословная» 12+
03.05 «Наедине со всеми» 16+
04.30 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Большие перемены»
12.35 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
18.00 «Привет, Андрей!» Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
21.00 Премьера. Алексей Демидов, Ева Розанова, Дарья Урсуляк, Николай Ковбас, Сергей Колесников, Сергей Ланбамин. «НАРОДНЫЙ АРТИСТ» 12+
00.50 Пелагея Невзорова, Евгений Шириков, Анастасия Груздева, Сергей Ланбамин. «ПРОВИНЦИАЛЬНАЯ МАДОННА» 12+
04.10 Дарья Щербакова, Андрей Фролов, Павел Харланчук-Южаков, Любовь Германова, Михаил Крылов, Алеся Пуховая. «СКАЗКИ РУБЛЁВСКОГО ЛЕСА» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 16.00, 21.55 Новости
07.05, 11.35, 14.05, 16.05, 18.50, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 «Команда МАТЧ». Анимационный сериал 0+
10.20 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Суперспринт. Мужчины. Прямая трансляция из Рязани
11.55 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Суперспринт. Женщины. Прямая трансляция из Рязани
13.10 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Суперспринт. Мужчины. Финал. Прямая трансляция из Рязани
14.25 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Суперспринт. Женщины. Финал. Прямая трансляция из Рязани
15.20 Матч! Парад 16+
16.55 Волейбол. БЕТСИТИ Кубок России. Мужчины. «Финал 4-х». 1/2 финала. «Локомотив» (Новосибирск) – «Факел» (Новый Уренгой). Прямая трансляция из Нового Уренгоя
19.55 Мини-футбол. Чемпионат России. PARI-Суперлига. КПРФ (Москва) – «Сибиряк» (Новосибирск). Прямая трансляция
22.00 Баскетбол 1х1. Лига Ставок - B1BOX. Прямая трансляция из Москвы
01.00 Волейбол. БЕТСИТИ Кубок России. Мужчины. «Финал 4-х». 1/2 финала. «Зенит-Казань» – «Белогорье» (Белгород). Трансляция из Нового Уренгоя 0+
02.55 Новости 0+
03.00 «Реал» Мадрид. Кубок №12». Док. фильм 12+
05.00 «Что по спорту? Кемерово» 12+
05.30 «Территория спорта» 12+

НТВ

05.05 «Спето в СССР» 12+
05.50 Боевик «БОЙ С ТЕНЬЮ-3: ПОСЛЕДНИЙ РАУНД» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 0+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 Леонид Куравлев «АФОНЯ» 0+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение» с Вадимом Такменевым
20.10 «Секрет на миллион» 16+
22.15 Премьера. «35 лет на льду». Ледовое шоу Евгения Плющенко (S) 6+
00.20 «Международная пилорама» с Тиграном Кеосаяном 16+
01.00 «Квартирник НТВ у Маргулиса». Группа «7Б» (S) 16+
02.20 «Дачный ответ» 0+
03.10 Сериал «МЕЧ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Предсказания 2.2.» 16+
07.15 «ОДНА ЛОЖЬ НА ДВОИХ» 16+
11.10 «ВОЗВРАЩЕНИЕ». 1-я – 8-я серии 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 85-я – 88-я серии 16+
22.20 «ВТОРАЯ ПЕРВАЯ ЛЮБОВЬ» 16+
01.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ». 1-я – 4-я серии 16+
04.55 «Нотариус» 16+

ЗВЕЗДА

05.45 «ЮНГА СО ШХУНЫ «КОЛУМБ» 6+
07.00, 08.15 «ЛЕДЯНАЯ ВНУЧКА» 6+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.35 «УСАТЫЙ НЯНЬ» 12+
10.00, 04.15 «ЗИГЗАГ УДАЧИ» 12+
11.45 «Легенды музыки». «Новогодние хиты» 12+
12.10 «Легенды кино». Александр Белявский 12+
13.15 «Время героев». Премьера! 16+
13.35 «Главный день» 16+
14.20 «СССР. Знак качества» с Иваном Охлобыстиным» 12+
15.10 «Не факт!» 12+
15.35 «Война миров». Док. сериал. «Битва калибров. Советская артиллерия против немецкой» 16+
16.30, 18.30 «КЛАССИК» 16+
19.05 «22 МИНУТЫ» 16+
20.50 «Легендарные матчи» 12+
23.50 «БЕЗ ПРАВИЛ» 16+
02.55 «СВИНАРКА И ПАСТУХ» 12+
05.40 «Сделано в СССР» 12+

25 декабрь | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Син минем тиң ярым». Зинира һәм Ризат Рамазановлар 6+
08.00 «Адымнар» 12+
08.30 «Зебра полосатая» 0+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы- шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Ачыктан-ачык». Миләүшә Таминдарова 12+
11.15 «Янам мәхәббәт дулкынында». Марат Фәйрушин 6+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество»12+
13.00 «Адымнар» 12+
13.30 «Видеоспорт» 12+
14.00 «Безнең Республика – безнең гамәл» 12+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
16.00 «Ком сәгате» 12+
17.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. ХК «Сочи» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
19.30 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
21.00 «Профсоюз – союз сильных» 12+
21.15 «Батырлар» 6+
21.30 «Болгар радиосы» концерты 6+
22.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
23.00 «ЗА ГРАНЬЮ РЕАЛЬНОСТИ» 12+
00.50 «Ком сәгате» 12+
01.40 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
07.00 «Адымнар» 12+
07.30 «Җырларым-моңнарым тик сезнең өчен». Марсель Иванов җырларыннан концерт 6+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә». М.Хәбибуллин турында телеочерк 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Туган авылым» 6+
13.20 К.Тинчурин. «ҖИЛКӘНСЕЗЛӘР». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
16.20 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
18.10 «Кәмит Җәвит» 16+
19.05 «Ком сәгате» 12+
20.00 «Семь дней» 12+
21.10 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
22.00 Х.Ибраһимов. «Җизнәкәй». Уфа «Нур» татар дәүләт драма театры спектакле 12+
00.40 «Яшьләр тукталышы» 12+
01.05 «Манзара» 6+
02.40 «Адымнар» 12+
03.10 Ф.Бурнаш. «Яшь йөрәкләр». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+

1 КАНАЛ

05.00 Фильм «Егерь» (S) 12+
06.00 Новости
06.10 «Егерь» (S) 12+
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» (S) 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» (S) 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Премьера. «Жизнь своих» (S) 12+
11.10 «Повара на колесах» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «Видели видео?» 0+
14.35 «Горячий лед». Чемпионат России по фигурному катанию. Показательные выступления (S) 0+
16.05 Наталья Андрейченко, Альберт Филозов, Лариса Удовиченко. «МЭРИ ПОППИНС, ДО СВИДАНИЯ» 0+
18.50 Премьера. Церемония вручения народной премии «Золотой граммофон» (S) 16+
21.00 «Время»
22.35 «Что? Где? Когда?» Финал года (S) 16+
00.20 «Романовы» (S) 12+
01.20 «Моя родословная» 12+
02.10 «Наедине со всеми» 16+
03.40 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

06.15 Карина Андоленко, Евгений Пронин. «КИТАЙСКИЙ НОВЫЙ ГОД» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым»
09.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00, 16.00 Вести
11.50 Елена Валюшкина, Ингрид Олеринская, Станислав Бондаренко. «И В СЧАСТЬЕ И В БЕДЕ» 12+
17.00 Премьера. «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
19.00 Вести недели
21.00 Премьера. «Красный проект». К 100-летию СССР. Фильм Д. Киселёва 12+
23.00 Москва. Кремль. Путин
23.35 «Воскресный вечер» 12+
02.25 «Судьба человека» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. АСА. Алихан Сулейманов против Ислама Омарова. Трансляция из Москвы 16+
07.00, 10.00, 16.00, 21.55 Новости
07.05, 16.05, 18.50, 22.00, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 «Команда МАТЧ». Анимационный сериал 0+
10.20 «Матч-реванш». Мультипликационный фильм 0+
10.40 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Масс-старт. Мужчины. Прямая трансляция из Рязани
11.55 Биатлон с Дмитрием Губерниевым
12.50 Биатлон. Pari Кубок Содружества. Масс-старт. Женщины. Прямая трансляция из Рязани
13.55 Волейбол. БЕТСИТИ Кубок России. Мужчины. «Финал 4-х». Финал. Прямая трансляция из Нового Уренгоя
16.55 Баскетбол. PARI Кубок России. Женщины. «Финал 4-х». Финал. Прямая трансляция из Сыктывкара
19.55 «Здесь был Тимур» 12+
22.30 Бильярд. «BetBoom Лига Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
01.00 Волейбол. БЕТСИТИ Кубок России. Мужчины. «Финал 4-х». Финал. Трансляция из Нового Уренгоя 0+
02.55 Новости 0+
03.00 «С мячом в Британию». Документальный фильм 6+
05.00 «Неизведанная хоккейная Россия» 12+

НТВ

05.15 Детективный сериал «ИНСПЕКТОР КУПЕР» (S) 16+
06.45 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
11.55 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «Суперстар! Возвращение». Новый сезон (S) 16+
23.30 «Главный бой». Прямая трансляция 16+
02.10 «ЯРОСТЬ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «ВТОРАЯ ПЕРВАЯ ЛЮБОВЬ» 16+
10.30 «НИКОГДА НЕ БЫВАЕТ ПОЗДНО» 16+
14.35 «ЧУЖОЙ РЕБЁНОК» 16+
18.45 «Пять ужинов» 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 89-я – 92-я серии 16+
22.20 «ОДНА ЛОЖЬ НА ДВОИХ» 16+
01.45 «ВОЗВРАЩЕНИЕ». 5-я – 8-я серии 16+
04.45 «Нотариус» 16+
06.25 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.55 «ОТРЯД ОСОБОГО НАЗНАЧЕНИЯ» 12+
07.10 «ГОРЯЧИЙ СНЕГ» 12+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.45 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №124» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.15 «Легенды армии» с Александром Маршалом. Михаил Наумов 12+
13.00 «Специальный репортаж» 16+
13.35 «Москва фронту». Док. сериал 16+
14.00 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. УДАРНАЯ ВОЛНА». 1-я – 4-я серии 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.40 «Холодная война. Битва экономик». Док. сериал. 1-я - 4-я серии 16+
22.50 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
23.00 «Фетисов». Ток-шоу 12+
23.45 «ПО ДАННЫМ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА...» 12+
01.05 «Без свидетелей. Павел Фитин против Шелленберга». Док. фильм 12+
01.50 «Война и мир театра Российской Армии». Док. фильм 16+
03.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. УДАРНАЯ ВОЛНА». 1-я и 2-я серии 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 19 декабрь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Юллар чатында»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10 Атилла Расих. «Каһәр суккан тел». Моноспектакль
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Шигърият». Резеда Вәлиева әсәрләре
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 20 декабрь

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Вокаль һәм инструменталь дуэтлар чыгышы

Чәршәмбе, 21 декабрь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Фасил Әхмәтов әсәрләреннән концерт

Пәнҗешәмбе, 22 декабрь

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 «Газиз тавышлар». Таһир Якупов язмалары

Җомга, 23 декабрь

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на удмуртском языке).
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Алинә һәм Азат Кәримовлар концерты

Шимбә, 24 декабрь

8.10 Литературно-музыкальная композиция
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Табигать дуслары»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында».
15.10 Рөстәм Галиуллин. «Хикмәтле туган көн». Әдәби спектакль

Якшәмбе, 25 декабрь

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10, 16.10 Заһир Бигиев. «Зур гөнаһлар». Радиоспектакль премьерасы

С 17 по 21 декабря 2022 года
РАСПРОДАЖА
УНТЫ

ИЗ ЯКУТИИ
из оленины (камус)
женские и мужские
цена от 5000
г. Казань, Вахитовский район, улица ВИШНЕВСКОГО, д. 12
(вход слева от магазина «Йола»), ориентир – магазин «Все инструменты», расположен рядом с помещением, остановка «ул. Калинина».
реклама 16+

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ӘНИЛӘР РӨХСӘТ ИТСӘ...

Бүген мәктәпләрдә укучыларны эшкә җәлеп итәргә ярамый. Дәүләт Думасының Мәгариф комитеты рәисе Ольга Казакова, әти-әниләрнең ризалыгы белән балаларга эшләргә рөхсәт итәргә кирәк, дип, «Мәгариф турында»гы Законга үзгәрешләр кертергә тәкъдим иткән. Мәктәпкә хезмәт тәрбиясе кайтырмы?

Ольга Казакова «мәктәпләрдә укучыларны хезмәткә тартырга ярамый» дигән маддәне «әти-әниләр рөхсәте белән ярый» дип үзгәртергә тәкъдим итте. Депутат әйтүенчә, хәзерге вакытта класс бүлмәсен җыештырган саен, укытучы әти-әнидән ризалык сорарга тиеш. Тәзәтмә кабул ителгән очракта исә әти-әниләрдән бер мәртәбә – бала укырга кергәндә ризалык алу да җитәчәк.

«Без кәбестә ашамыйбыз»

– Моннан ике ел элек мәктәп яны бакчасына җир казырга алып чыккан өчен 10 нчы сыйныф кызлары минем өстән Прокуратурага шикаять язды. Кабинетыма кереп: «Ник сез безне эшләтәсез?» – дип видеога төшерделәр. Бакчада үскән әйберне өйгә ташыганым юк, кәбестәсен дә, башкасын да табынга куябыз бит, дип аңлаттым. Юк, без кәбестә ашамыйбыз, диләр. Шуннан соң тикшерүчеләр: «Нишләп законны бозасыз?» – дип мине тикшереп йөрделәр. Тагын бер малай бар иде әле. Бакчага чыга да, закон буенча мин эшләргә тиеш түгел, дип, тик басып тора. Ә ашарга барысы да яраталар. Балалар үзләре теләмәсә, эшләтергә хакыбыз юк. Такта сөртергә дә, идән юдырта да алмыйбыз, – ди Биектау районы Дөбьяз мәктәбе директоры Ринат Хәсәнов. – Бу депутат тәкъдименең файдасы бар дип уйлыйм. Әгәр бала эшләргә теләмәсә дә, әти-әни риза булса, аны эшләтеп булачак. Ләкин бу әле ярты гына адым. Хезмәт тәрбиясен болай гына кайтарып булмый.

Казан мәктәбендә укучы Ралинә Галимуллинаның да мәктәп яны бакчасында практика үтәсе килми. Бер караганда, бер атна күп тә түгел инде.

– Авыр эш кушмыйлар. Чәчәкләргә су сибәсе, чүп утыйсы, баскычларны юасы. Эшлисең килмәсә, мәктәпкә уку кирәк-яраклары алып бирәсең. 8 нче сыйныфка җитеп, минем бер мәртәбә дә эшләгәнем юк. Сыйныфтан бары берничә кыз гына практикага йөри. Без мәктәпкә эшләргә түгел, укырга киләбез, – ди Ралинә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Фикер

Алмаз ГАЛИМОВ, КФУның психология һәм мәгариф институты директорының укыту эшләре буенча урынбасары, педагогика фәннәре докторы:
– Минем белүемчә, хәзер дә әти-әниләрнең һәм баланың ризалыгы буенча эшкә җәлеп итәргә була. Балаларның хезмәткә тартылуына уңай карыйм. Барыбыз да эшләп үстек. Ләкин баланы эшкә тарту һәрвакытта да хезмәт тәрбиясе дигән сүз түгел. Теләсә кайсы тәрбия чарасы кебек, хезмәт тәрбиясе дә уңай эмоциональ мохиттә башкарылырга тиеш. Аның үз шартлары бар. Законга 2–3 сүз өстәп кенә хезмәт тәрбиясен каядыр яңа үрләргә күтәреп булмый. Бу инициативаның кая таба юнәлтелгәнен мин бик аңлап бетермим әле.

Сездә ничек?

Мәктәптә хезмәт тәрбиясенә карата «Ел укытучысы – 2018» бәйгесе җиңүчесе, Казандагы 108 нче мәктәпнең физика укытучысы Радик Хәбировның да фикерен белештек.

– Соңгы вакытта укучылардан такта сөрттергәнем юк диярлек. Ни өчен дигәндә, маркерлы тактада эшлибез. Тиз генә язасың да, вакытны әрәм итмәс өчен, үзең сөртеп аласың. Әгәр акбур белән язудан туктап, маркер тактасына күчсәк, проблема тумас. Минем тәҗрибәдә: «Ник такта сөртерәсең?» – диюче әти-әниләр булмады. Идән юыга килгәндә, аны әти-әни үзе хәл итәргә тиеш дип саныйм. Без укыганда кизү тора идек. Хәзер замана икенче бит. Әти-әни баласын мәктәпкә укырга дип җибәрә. Юридик якны карасаң, алар хаклы. Әти-әниләр каршы түгел икән, иң яхшысы – ел башында коллектив килешүе төзү. Риза булсалар, хет кар көрәргә чыксыннар, хет идән юсыннар. Хәзер идән юучы балаларны күргәнем юк. Ә менә кар көрәргә чыгарга атлыгып торучылар бар. Укытучылар әти-әни белән аңлашып эшләгәндә, хезмәткә тарту проблемасы тумый, – ди Радик Хәбиров.

Яшел Үзән районы Осиново мәктәбе директоры Гөлинә Саттарова әйтүенчә, әти-әнидән гариза алу бүген генә чыккан әйбер түгел. Укучылар әллә нәрсә эшләми, нибары такта, тузан сөртә. Моңа бер әти-әни дә каршы килми икән.

– Тәрәзә юдыртмыйбыз, ни өчен дигәндә, куркыныч. Мәктәптә балаларга идән сөрттерергә каршы мин. Идән юучыларга зыян өчен акча түләнә. Дөресен генә әйткәндә, бар якта ялтырап торсын, вирус, бактерия булмасын дисәк, аны үз эшенең остасы башкарсын дип саныйм, – ди Гөлинә Саттарова.

Әнисә Миннәхмәтова Мамадыш районының Түбән Ушма мәктәбендә башлангыч сыйныфларны укыта. Аның укучылары гөлләргә су сибә, тәрәзә төпләренең тузанын, такта сөртә...

– Әти-әниләрдән ризалык алмыйбыз. Бу язылмаган кагыйдә кебек бара. Балаларны эшләтүгә кагылышлы проблеманың бервакытта да туганы юк. Укучылар ашханәдә кизү тора. Ашагач, үз артларыннан җыештыралар. Һәр чирек ахырында сыйныфны яхшылап җыештырып китәбез. Хәзер экологик проблема дип чаң кагалар. Үз артыннан җыештырган кеше беркайчан да чүпләми. Үз агымында бара торган эшне катлауландырмасыннар иде, – ди укытучы.

ЮРИСТ СҮЗЕ

– Балаларны мәктәпләрдә хезмәткә җәлеп итүгә килгәндә, РФ «Мәгариф турында»гы Закон нигезендә, әти-әниләрнең рөхсәтеннән һәм укучыларның ризалыгыннан башка балигъ булмаган балаларны белем бирү программасында каралмаган хезмәткә җәлеп итү тыела.

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте дә (Роспотребнадзор) 18 яшь тулмаган затларны зарарлы яки куркыныч эшләрдә эшләтүне тыя. Хәзерге вакытта РФ Хезмәт кодексының 63 нче статьясы нигезендә, хезмәт килешүе 16 яшь тулган затлар белән төзелә ала. Шулай ук бүген ата-аналарның берсе һәм опека органнары рөхсәте белән 14 яшькә җиткән зат белән җиңел эшләр башкару өчен хезмәт килешүе төзелергә мөмкин. 14 яшькә кадәрге балалар кинематография, театр оешмаларында экранлаштыруда һәм куелышларда катнашуга җәлеп ителергә мөмкин, әмма мондый эш баланың сәламәтлегенә зыян китермәсә генә ата-аналарның һәм опека органының рөхсәте булса гына мөмкин.

Сәрия МИФТАХОВА

Гаугалы «күчтәнәч»

Редакциягә Теләче районыннан мөрәҗәгать иттеләр. «Узган ел декабрь аенда республика укытучылары 50–60 мең сум премия алды. Быел да саллы акча көтә дип ишеттек. Ә безгә нигә юк?» – дип язган район мәктәпләренең директор урынбасарлары. Сүз ел ахырында бирелә торган федераль акча турында бара. Әлеге мәсьәләгә Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы белән ачыклык керттек.

Теләчедән килгән хатта директор урынбасарлары үзләре башкарган эшнең күплегеннән зарланган. «Урынбасар вазыйфасын гына башкарып калмыйча, дәресләр дә укытабыз. Укытучылар кебек курсларда белемнәребезне күтәрәбез, аттестация үтәбез. Эш күп, өстәвенә хисап өчен җавап бирергә кирәк. Шуңа күрә безгә мондый премиянең бирелмәвен гаделсезлек дип саныйбыз», – дип язган алар. Бу уңайдан Теләчедәге мәктәп директорлары, бакча мөдирләре зарларын район хакимиятенә дә белдергән икән. Анда район казнасында өстәмә акча каралмаган, дип аңлатканнар. Яңа елдан исә мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хаклары артачак дип тынычландырганнар. Шулай ук район башлыгы исеменнән Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллинга хат язганнар. Әлегә җавап килмәгән.

Хатны алгач, Теләче районы мәктәпләрендәге завучларга шалтыратып, хәлләрен белештек. Алар исемнәрен күрсәтмәвебезне үтенде.

– Узган ел районда укытучылар премияне 50 мең сумнан да ким алмады. Көнләшү түгел бу. Тигезсезлеккә карата үпкәбез бар. Без дә атнага 12шәр дәрес укытабыз бит. Авыл мәктәпләрендә исә бу сәгатьләр тагын да күбрәк. Ник шулай аералар? Шул укыткан сәгатьләр өчен булса да түләсеннәр иде. 5 мең сумга да сөенер идек. Өстәвенә районындагы завучларны сыйныф җитәкчесе вазыйфасыннан да азат иттеләр. Янәсе, ярамый. Башка районнарда алар эшләвен дәвам итә, – диде урынбасарларның берсе.

Без әлеге премиянең бары тик укытучыларга гына бирелүен беләбез. Быел аны бирү тәртибенә үзгәреш кертелмәгәнме? Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан шул хакта сораштык.

– «Май указлары» (Путин түләүләре) буенча түләүләр педагогик хезмәткәрләрнең уртача хезмәт хакын төбәк буенча уртача хезмәт хакы дәрәҗәсенә җиткерү өчен бирелә. Бер тапкыр бирелә торган премия мәгариф оешмалары директорлары һәм урынбасарларга каралмаган, чөнки әлеге вазыйфалар «административ персонал» төркеменә керә, – диделәр министрлыкта.

Бу акчаны һәр укытучы тигез алачакмы? Министрлыкта аңлатуларынча, акча районнарга бүлеп бирелә. Анда исә түләү күләмен мәгариф оешмалары җитәкчеләре билгели. Премия төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча башкарылган эш күләменә карап түләнә.

Кайбер районнарда директор, урынбасарларның да кәефен күтәрү җаен тапканнар. Мәсәлән, Сарманда. Анда барысын да тигез күрергә тырышалар. Директор һәм урынбасарларга район хакимияте премиясе бирелә. Узган ел бу сумма 15 мең сум булса, быел – 15–20 мең сум тирәсе. Район хакимияте декабрь аенда яшь укытучыларны да 25 мең сум премия белән сөендерә.

– «Май указлары» буенча бирелә торган федераль акчаның директор һәм завучларга түләнмәвен башыма сыйдыра алмыйм. Ни өчен дигәндә, иң күп эш шуларга йөкләнә. Өстәвенә алар дәрес тә алып бара. Директор һәм урынбасарларны укытучылардан аерып, премиясез калдыру зур хата дип саныйм, – ди Сарман районы мәгариф бүлеге башлыгы Гөлшат Идрисова. – Укытучылар быел федераль премияне алмады әле. Күләмен әйтә алмыйм, төрле укытучыны төрлечә. Әмма аз акча түгел.

«БЕЗ ВАТАН АЛДЫНДА АНТ БИРДЕК...»

РОССИЯ ГЕРОЕ РӨСТӘМ СӘЙФУЛЛИННЫҢ ТОРМЫШ СӘХИФӘЛӘРЕ

Махсус хәрби операция барышында иң югары бүләккә лаек булучылар арасында Татарстаннан читтә туып-үскән милләттәшләребез дә бар. Шуларның берсе – Төмән өлкәсендәге Вагай авылында туып-үскән Рөстәм СӘЙФУЛЛИН.

Ул бүген Мәскәүдә, академик Николай Бурденко исемендәге баш хәрби клиник госпитальдә тернәкләндерү курслары уза. Сөенечле яңалыгы да бар: тездән астарак өзелгән уң аягына протез ясаганнар, хәзер ул таяклар ярдәмендә беренче адымнарын атлый. Сул аягы, табанына операцияләр ясалганнан соң, элеккечә Илизаров аппаратына куелган.

Без Геройның үзе, Вагай районы Абаул авылында яшәүче туганнары, Карагай мәктәбендә укыткан укытучылары белән сөйләшеп, тормышның мәгънәсе турында фәлсәфә кордык, батырлар ничек туа дигән сорауга җавап эзләдек.

Әгаделлек кайда?

Рөстәм Сәйфуллин сөйләгәннәрдән. Россия Герое исеме бирелү хакында госпитальдә ятканда ишеттем. Хезмәттәшләрем әйтте. Уникe операция кичергәнгә, хәлем әллә ни түгел иде, шуңа мин бу хәбәрне беренче мизгелләрдә тулаем кабул итә алмадым да кебек. Күңелдә горурлык хисе пәйда булды, әлбәттә. Әмма мондый бүләкнең беренче чиратта зур җаваплылык өстәве бер секундка да истән чыкмады. Авыр яралануга карамастан, отставкага китү турында уйлаганым юк бит әле. Димәк, бу исемгә чын мәгънәсендә лаек булырга кирәк. Төмән югары хәрби инженерлык команда училищесын тәмамлаганнан соң, миңа гел кайнар нокталарда хезмәт итәргә туры килде: башта Чечняда, аннан Көньяк Осетиядә, махсус хәрби операция зонасында... Гел командир булдым. Башта взвод командиры, ротаныкы, батальонныкы, соңгы вакытта полкны җитәкләдем. Димәк, мин үз кулым астында хезмәт итүчеләрнең тормышы өчен теләсә нинди вазгыятьтә дә җавап бирәм дигән сүз бу. Ул бит гади тормышта гына җитәкче үз оешмасында эшләүчене куркыта ала, эштән дә җибәрергә мөмкин. Ә сугышта бөтенләй башка кыйммәтләр. Анда битлек киеп йөреп булмый, янәшәңдәге һәр кешене кем икәнен,ниләр уйлаганын үтәли күрәсең. Операциягә, һөҗүмгә барганда, аннан кире кайтмый калу ихтималын һәркем бик яхшы аңлый. Теләсә кайсы адымга алар командирларына ышанып баралар. Әгәр бу ышанычны югалтасың икән, синең абруең, әлбәттә инде, бетте дигән сүз. Сугышчыларны артыңнан ияртә алмаска да мөмкинсең. Ә мондый хөрмәткә ия булу өчен акыл да, белем дә, ихтыяр көче дә, физик, рухи яктан нык булу да кирәк. Без Ватан алдында ант бирдек. Димәк, аны саклау өчен гомеребезне дә кызганмаска тиешбез.

Сапер бер генә ялгыша, дигән гыйбарә белән килешеп бетә алмыйм. Аякларын өздергән егетләр арасында протез куйдырганнан соң яңадан сафка әйләнеп кайтучылар бар. Әйтергә кирәк, бу хезмәт бик үзенчәлекле. Саперлар өчен сугыш тиз генә туктый алмый. Мәсәлән, Бөек Ватан сугышы тәмамланганга тиздән 80 ел була. Ә яу кырларында миналар бүген дә шартлый, чистарту эшләре бүген дә бара. Шартлы рәвештә генә күз алдына китерик әле: имеш, бер заман ниндидер сәбәпләр белән Җир шарында хәрби конфликтлар бөтенләйгә тукталды ди, ул җирләрне чистартып бетерү өчен саперларга якынча гына алганда да 300 ел тирәсе вакыт кирәк булачак.

Төмән өлкәсе губернаторы урынбасары Эдуард Бакиев якташын Геройлар көне белән котлый.

Минем хәрби хезмәткә тартылуыма беренче чиратта, мөгаен, Бөек Ватан сугышы турындагы әдәби әсәрләр тәэсир иткәндер дип уйлыйм. Безнең бабаларыбыз нинди авыр чорда да сынмаганнар, сыгылмаганнар, үлем белән күзгә-күз очрашып, җиңү яулаганнар. Бары тик Ватанны саклау турында гына уйлаганнар. Мин аларның батырлыгына, түземлегенә хәзер дә хәйран калам. Әтием ягыннан бабам Миначетдин да 1940 елда хезмәткә алынып, сугыш юлларын үтеп, Япония самурайларын тар-мар итеп, туган йортына 1947 елда гына әйләнеп кайткан. Ә тылда калган әбиләребез ничек хезмәт иткән?! Алар бит күңел ачуның ни икәнен дә белмәгәннәр, ач-ялангач килеш эшләгәннәр дә эшләгәннәр. Мин җиденче сыйныфка укырга барган елны гаиләбез Абаул авылына күченде. 12 чакрым ераклыктагы бабаларым яшәгән Карагай мәктәбендә укырга, шунда яшәргә туры килде. Бабамның холкы корырак булса да, ни дәрәҗәдә нык ихтыярлы, гадел булуына соклана идем.

Хәзерге буынга әнә шул гаделлек җитми. Хезмәт кешенең тормышын мәгънәле итә. Шуны барыбыз да аңлыйбыз кебек. Әмма күп әти-әни үзләре үк баласын иркәләп үстерә. Хәрби операциягә барудан куркып, чит илләргә чыгып китүчеләр арасында да әнә шундый дөрес тәрбия алмаучылар күбрәк дип фаразлыйм. Уйланырлык урын бар бит: берәү куркып кача, аның урынына икенче кеше барырга тиеш булып чыга, ә ни өчен? Гаделлек кайда?

Үз балаларым барысын да аңлап, чын милләтпәрвәр булып үссеннәр иде дип хыялланам. Хәләл җефетем Наталья белән өч бала үстерәбез. Әлегә барысы да мәктәп яшендә. Соңгы вакыйгалар безнең араларны тагын да якынайтты кебек. Гарнизоннарда, тулай торакларда яшәгәндә ул һәрвакыт янәшәмдә, төп терәгем булды. Үз хезмәтебез белән тапканга шөкер кылып яшибез. Матди байлыгыбыз юк, аның каравы рухи яктан бай без, дусларыбыз, туганнарыбыз күп.

Күпләр миннән киләчәккә планнарым турында сораша. Әлегә төгәл карар кабул иткәнем юк. Барысы да сәламәтлегемә, ни дәрәҗәдә тернәкләнүемә бәйле булачак. Оборона министры Сергей Шойгу үзем белем алган хәрби училищеда начальник урынбасары вазыйфасын тәкъдим иткән иде. Әйтергә кирәк, бу – бик җитди эш. Монда үз тәҗрибәңне яшьләргә тапшыра белергә кирәк. Теория белән гамәли эш үрелеп барырга тиеш, чөнки алар аерылгысыз.

«Аяклары гына исән булсын иде...»

Люция Аликаева сөйләгәннәрдән. Мин Рөстәмнең әтисе Нургалинең апасы булам. Сәламәтлеге азрак какшаганга, абыем янында яшәп, аңа ярдәм итәм. Рөстәм көн саен шалтыратып тора. Беләм, бик авырдыр инде үзенә, әмма йөзеннән һич кенә дә елмаю китмәс. Көчле ихтыярлы шул ул. Кечкенәдән үз көнен үзе күреп яшәргә өйрәнде. Терлек асрадык. Ул аларга җәй буе печән әзерләде. Күп итеп бәрәңге утырта идек. Аны җыючыларга тапшырып, акча тапты. Мүк җиләге, нарат җиләге – Себердә яшәүче халыкның төп керем чыганагы. Сезон башлангач, Рөстәм сазлыктан кайтып та керми торган иде. Җиләк саткан акчага өс-баш юнәтте, безгә дә булышты. Төмәндә укый башлагач та, гел кайтып йөрде.

Россия Герое исеменә лаек булуы турында безгә хатыны Наталья шалтыратып әйтте. Әтисе башта: «Герой исеме дә кирәкми, аяклары гына исән булсын иде», – дип бик кайгырды, ябыгып бетте. Бу хәлне бик авыр кичерде. Тора-бара, улының бик позитив рухта булуын күреп тынычланды кебек. Рөстәм белән булган хәлләрне ишеткәч тә, бәрән чалып, мулла чакырып, Коръән ашы үткәрдек. Аның энесе Хәйдәр Мәскәүдә хәрби академиядә белем ала. Тәмамларга җыена инде. Имтиханнарга әзерләнеп йөри. Бәла-казага юлыкмасын, исән-сау йөрсен дип, аңа багышлап та аш үткәрдек.

Күңелне кузгатып җибәрә ул

Галия Илчебакиева сөйләгәннәрдән. Рөстәм Карагай мәктәбенә укырга килгәч, аларның сыйныф җитәкчесе булдым. Үзем татар теле һәм әдәбияты укыттым. Вагайда татар теле дәресләре укытылмаган икән. Рөстәм аны шундый тиз үзләштерде. Мәктәпне дә гел «5ле» билгеләренә тәмамлады. Спорт белән шөгыльләнде, бөтен җирдә оештырып йөрде. Бер эштән дә тайчанмады. Истә калган вакыйгалар да күп. Шулай бервакыт дәресләргә соңга калып килә башлады бу. Кисәтү ясаган идем: «И, апа, мин иртүк торып, ике сыер савам бит», – ди. Әбисе авырып киткән икән. Рөстәм белән элемтәбез беркайчан да өзелмәде. «Апа, хәлләрегез ничек?» – дип биш минутка булса да кереп чыга иде. Бервакыт шулай армиядәге бабайлык күренеше турында сүз кузгаттым да: «Рөстәм, балам, кул астыңдагы хәрбиләр барысы да кемнеңдер баласы инде. Рәнҗетә күрмә, зинһар», – дим. Ул вакытта өйләнмәгән иде әле. «Апа, минем төркемдә контракт белән эшләүчеләр. Барысы да диярлек гаиләле. Балалары бар. Мин бик яхшы аңлыйм. Шуңа күрә минадан чистартырга да иң беренче үзем барам», – диде. Әллә ниләр белән күңелне кузгатып җибәрә ул. Берсендә өебезгә сыйныфташ кызлары килгән иде. Рөстәм дә керде. Керүе булды, Фатих Кәримнең «Ант» шигырен сөйләп җибәрде. Тәннәр чемердәп куйды шулчакта. Кызлар: «Без 1 нче сыйныфтан татар теле укысак та, онытканбыз, оят инде безгә», – диештеләр. Беренче тапкыр яраланганын ишеттем дә, олы кызым Хәйдәр белән укыган иде, шалтыратып белеш әле, дидем. Бераздан: «Апа, кайгырма, барысы да яхшы», – дип Рөстәм үзе элемтәгә чыкты. Ә Россия Герое исеме бирелгәнен ирем район үзәгеннән ишетеп кайтты. Шатлыгыбызның иге-чиге булмады.

39 яшьлек Рөстәм Сәйфуллин махсус хәрби операциядә беренче көннәрдән үк катнаша. Аның подразделениесе кичүләрне торгызу белән шөгыльләнә. Ул яу кырында ике тапкыр яралана. Беренчесендә тәненә снаряд кыйпылчыклары кадала. Икенчесендә полковник авыр яра ала, әмма сугышчыларын калдырып китми. Аның подразделениесе куелган приказны үти: Десна елгасы аша салынган йөзмә күперне дошманның артиллерия утыннан саклап кала. Нәтиҗәдә гаскәргә алга таба барырга юл ачыла. «Бомба аяк астына ук төште. Каным күп китеп, аңым югалмасын өчен, автоматтан каешны салдырып алдым да нык итеп бәйләп куйдым. Ярдәмгә тиз килеп җиттеләр», – дип сөйли батыр егет үзе бу хакта соңрак. Мөһим кичүне саклап калуда күрсәткән батырлыклары өчен милләттәшебез «Алтын Йолдыз» медале белән бүләкләнә һәм Россия Герое исеменә лаек була. «Бу бүләк минеке генә түгел, барлык полкташларымныкы да», – ди герой бу уңайдан.

Карагай мәктәбенең горурланырлыгы бар. 2022 елның 1 сентябреннән ул үз укучысы, полковник, Россия Герое Рөстәм Сәйфуллин исемен йөртә. Шулай ук аның исеме белән авылда парк-аллея ачыла. Ә Төмәндәге ул белем алган хәрби училищеның диварына куелган истәлек тактасында геройның исеме уелып языла.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ТЫЛСЫМЧЫ ЛИЛИЯ

Яңа ел бәйрәме якынлаша. Өлкәннәрнең күңеле башка уйлар белән тулган булса да, сабыйлар Кыш бабайны көтә. Ничек итсә дә итсен, әмма килеп җитсен! Сабыйлар шуны тели. Арчада яшәүче Лилия Шәфыйкова өч ел инде физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен «Үзенчәлекле Кыш бабай» дигән марафон уздыра. Шулай дип аталса да, сабыйларны күбрәк Кар кызлары сөендерә икән.

– Моннан дүрт ел элек мин бер хәйрия фондының, Яңа ел алдыннан бүләк таратып, сабыйларны сөендергәнен күреп алдым. Үземнең дә шуны эшләп карыйсы килде. Бу эш нидән гыйбарәтме? Син башта бүләк алырга теләүче сабыйларны барлыйсың, аннары шул исемлекне интернетка куеп, аларны сөендерергә әзер кешеләрне табасың. Беренче елны каушап калдым. Моны эшли алмадым, – дип искә ала Лилия. – Әмма икенче елга алдан ук әзерләнеп, балалар исемлеген төзедем. Аларның Кыш бабайдан сорыйсы килгән әйберләре була. Кемдер смартфон, колакчыннар, төрле уенчыклар, рәсем ясау кирәк-ярагы сорыйлар. Беренче елны 50дән артык баланы сөендердек. Икенче юлы аларның саны 60ка җитте. Быел 40 бала могҗиза булуын көтә. Әлеге марафонда хәзер Арча балаларына гына түгел, Балтач, Әтнәдә яшәүчеләргә дә бүләк таратабыз.

Лилия уздырган марафонда үземнең дә катнашканым бар. Берьюлы өч баланы сөендергән идем. Чынлап та, кечкенә генә бүләкләр ул сабыйларның бөтен дөньясын үзгәртә дә куя. Алар гына түгел, бөтен гаиләләре шатлана. Ә әниләренең рәхмәт сүзләре сиңа тагын канат куя. Ирексездән, яңадан Яңа ел килгәнне көтә башлыйсың. Лилия дә шулай ди. Әлеге эшен нәкъ менә күңеленә рәхәт булганга башкара икән. Сабыйларның шат елмаюлары бәхет өсти, ди ул. Ә бит аның үз күңеле дә буш түгел. Без аның белән кызы Адиләгә ярдәм кирәк чакта танышкан идек.

– Кызым 2020 елда кинәт кенә авырып китте. Анда тромб барлыкка килү куркынычы бар. Шуңа да инде сабыем 4 операция кичерде. Безнең табиблар аңа ярдәм итә алмагач, ул чакта мин дә, интернет аша акча җыеп, чит илгә дәваланырга чыгып киткән идем. Быел июньдә дүртенче операцияне ясадылар. Аллага шөкер, яхшы якка үзгәрешләр бар. Әйтергә дә куркам инде, күз тияр, дим. Балам сау-сәламәт булсын өчен мин барысына да риза, – ди Лилия. – 2024 елда тагын бер операция кирәк булачак. Адиләне саклап кына яшәтәбез. Сызланулары бар. Аяклары авырта, веналары гел ялкынсынып тора. Ул чакта төрле мазьлар ярдәм итә. Шөкер, табиблар күзәтеп торгач, күңелем тыныч.

2020 ел Лилия өчен сынаулы була. Ул тормыш иптәше белән аерылыша. Хәзер ике баласын ялгызы тәрбияли. Улы Фәнискә – 13, кызына – 7 яшь. Улы футбол, йөзү түгәрәгенә йөри. Оста итеп гитарада уйный икән. Адилә дә тик тормый. Ул биюгә, вокалга, йөзүгә йөри. Төрле матурлык бәйгеләрендә катнаша. Әниләре исә, кешенекен генә түгел, үз сабыйларын да гел шатландырып тора.

– Бу эшкә кушылырга теләүчеләр шактый. Иптәш кызымның да киләсе елда сабыйларны сөендерәсе килә. Ярдәм итәм дип торучы тылсымчылар да күп. Бергә-бергә әллә ниләр эшләп булганын аңладым инде мин. Иң мөһиме – теләк кирәк. Изге эшкә тотынсаң, булышучысы табыла, – ди Лилия. – Физик мөмкинлеге чикле сабыйларны сөендерүдән тыш, без быел бәйрәм алдыннан Арча районының Яңа Кенәр авылындагы интернатка да барырга җыенабыз. Әкренләп акча җыя башладык инде. Шул балаларга бәйрәм ясавыбызны сораучы кешеләр бик күп. Андагыларны да сөендерә алсак, Яңа елга тыныч күңел белән керер идек.

Лилия үз эшләре турында кыенсынып кына сөйли. Иң мөһиме – бу эшем үземә ошый, ди ул. Эти-әниләр исә тылсымчыларга чиксез рәхмәтле. Әйтик, Балтач районының Кариле авылында яшәүче Лилия улына җибәргән бүләк өчен җылы сүзләрен җиткерде.

– Игелегегез үзегезгә меңе белән кайтсын! Балаларыгыз авырмасын. Ана өчен иң мөһиме – шул. Кар кызы бүләк иткән уенчык улыма бик ошады, – ди ул.

Мондый язмалардан соң, яхшылыкны сөйләп йөрмиләр, диючеләр дә очрап куйгалый. Ә мин изге гамәлләрне кешегә җиткерү яклы. Бер-берсеннән күреп, күпме кеше игелек кыла ала бит. Кыш бабай белән Кар кызыннан бүләк алган сабыйның елмаюлы йөзе тылсымчыларның дөрес юлда икәненә шик калдырмый.

ТОРМЫШ КӨЗЕ

Өлкән яшьтәге кешеләр белән даими аралашып торырга туры килә. Күбрәк үзләре мөрәҗәгать итә. Берсенә табиб кушкан даруны бирмиләр, икенчесенә субсидиясен китермәгәннәр, өченчесенә исә күңелен бушатырга кирәк.

Без редакциягә шалтыраткан кешеләргә ничек тә ярдәм итәргә тырышабыз. Әле менә шушы көннәрдә «ВТ»ны күптән алдыручы укучыбыз шалтыратты. Ул да ярдәм сорый. Картлыгын тыныч уздырасы килә. Үзен берәр җиргә урнаштыруны үтенә.

«Бөтенесе файда эзли»

Без аның исем-фамилиясен үзгәртеп бирергә булдык. Начар ниятле кешеләр зыян салмасын өчен шулай эшлибез. Казанда яши ул, Фатыйма апа 80нең теге ягына чыккан инде. Тормышта төрлесен күргән. Балачагы бик авыр уза аның. Борчулары да күп була, авырулар да өелеп килә. Әмма сер бирми әле – ничек тә яшәргә тырыша. Үз аягында йөри, тик утырмый: бәйли дә, тегә дә. Сәламәтлегенә шөкер итә. Әмма Фатыйма апаның кешеләргә ышанычы беткән. Аның ялгыз яшәвен белеп алуга, шуннан үзләренә файда эзләүчеләр бар икән.

– Ишегалдында утырганда, бер хатын белән таныштык. Өч баласы бар, кибетче булып эшли. Кайчак миңа кирәк-яраклар да алып кайтып бирә иде. Бервакыт бурычка акча сорады. Үз кеше дип уйладым, ышандым инде. Бер айдан кайтарам дигән иде, ярты ел узды, акчаны да, үзен дә күргән юк. Кибеттән дә киткән. Кул селтәдем: акча була да бетә ул. Исәнлек кирәк, – ди Фатыйма апа. – Бар ышанычым дәүләттә. Картайган көнемдә берәр җылы урында яшәргә иде. Ялгызлыктан арыдым. Мине кая булса да урнаштырыгыз әле.

Балалары юк аның. Ерак булса да, туганнары бар икән. Аларга үзен кайда җирлисен васыять әйтеп, үлемтекләрен тапшырып куйган инде. «Әмма яшисе килә әле. Күпме калганын бер Ходай гына белә. Бар теләгем: исән чагында кадер-хөрмәттә яшисе килә. Шуңа күрә сездән киңәш сорыйм», – ди ул.

Баксаң, Казанда түләүле пансионатлар күп булып чыкты. Иң беренче булып шалтыратканында матур гына эндәштеләр. Телефондагы кыз үзләре хакында шулкадәр матур итеп сөйли. Эреп китми чак түзәсең. Бирердә бер тәүлек яшәү бәясе – 1200 сум. Биш тапкыр ашатуларын, кирәк чакта табиб ярдәме барлыгын, үзләрендә күңелле чаралар узуын да әйттеләр. Икенчесенә шалтыраттык. Мондагылар да Фатыйма апаны бишкуллап алырга риза. Иң мөһиме – акчасын гына түләсен. Аның үз аягында йөрүен, үз акылында икәнен белгәч, тагын да кызыксынып киттеләр. Өченчесендә бер тәүлек яшәр өчен кимендә 1800 сум акчаңны бирергә кирәк.

– Без – Мәскәү оешмасы. Кызганыч, әлегә Казанда бүлекләребез юк. Әмма тиздән ачарбыз дип торабыз. Нәкъ безнең оешмага килергә теләүчеләр күп. Күпләр инсульт кичергәннән соң урынга калган. Паркинсон авырулары да бар. Хәтерләрен югалтучылар да күп. Тәүлек буе мохтаҗ кешеләр өчен күбрәк түлисе. Барысын да килешү төзеп хәл итәбез, – ди үзен Наташа дип таныштырган ханым. – Бездә торучыларның барысының да балалары, туганнары бар. Әмма олыгайган кешене карыйсылары килми. Аларны да аңлыйм мин. Эшләргә кирәк бит. Яшәү кыйммәтләнде. Үзем әниемне исә беркайчан да мондый җиргә илтеп тапшырмас идем.

Гомер көзләрен Казандагы Хосписта уздыручылар да бар. Алар анда түләп яши. Анжела Вавилова исемендәге хәйрия фонды рәисе Владимир Вавилов сүзләренә караганда, аларга килергә теләүчеләр аз түгел.

– Миңа шалтыратучылар да, яныма килүчеләр дә байтак. Без аларның һәркайсы белән сөйләшәбез. Балаларыгыз кайда, туганнарыгыз юкмы, дип сорыйбыз. Безгә авыру кешеләр килә. Кулларында документлы булганнарны кире бормыйбыз. Алар бездә яшәп бакыйлыкка күчә, – ди Владимир Вавилов. – Фатыйма апа белән элемтәгә керермен. Күрешеп сөйләшергә кирәк. Башка чарасы булмаса, бәлки, аңа бездә урын табылыр.

Бала күңеле кайларда?

Картлар йортына илтеп куегыз! Олыгайган кеше авызыннан бу сүзләр еш чыккалый. Күңелләре төшеп, кәефләре китсә, бигрәк тә. Ничек кенә кырыс сүз булса да, анда әлегүнең дә үз тәртибе бар. Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат үзәге җитәкчесе Рафаил Гыйниятуллин аңлатканча, өлкән кешене картлар йортына озатканчы, ул кешенең чынлап та социаль ярдәмгә мохтаҗмы-юкмы икәнен ачыклыйлар.

– Әгәр кеше үз-үзен йөртә алмый, авыруы аркасында тормыш итәргә яраксызлана икән, бу очракта ул үз районының социаль яклау бүлеге аша үзен дәүләт оешмаларына урнаштыруларын сорый да. Өлкән кешегә гаиләсендә куркыныч янаган очракта да, билгеле, дәүләт аңа ярдәм кулы суза, – ди Рафаил Гыйниятуллин.

Татарстанда өлкәннәр һәм инвалидлар өчен 25 оешма бар. Алар 1905 кешегә исәпләнгән. Андагы шартлар турында ничек кенә матур итеп сөйләсәләр дә, үз өеңә, үз балаң тәрбиясенә җитәме соң? Тик монысы инде – яшьлектә салынган орлык җимеше. Кызганыч, бөтенесе дә татлы булмый.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ОЯСЫЗ КОШЛАР

ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ ҖЫР ҺӘМ БИЮ АНСАМБЛЕ 85 ЕЛЛЫГЫН БИЛГЕЛӘП ҮТТЕ

Бернигә дә карамастан. Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбленең юбилей концертыннан соң күңелдә туган беренче җөмлә әнә шул. 85 ел сәхнәсез булуга карамастан. Үтә тыйнак булуга карамастан. Яңа номер әзерләп өлгермәүгә карамастан. Яңа костюмнар тектерүгә акча булмауга карамастан... Саный китсәң, карамастаннар шактый күп икән шул ул. Безнең йөзек кашы булган коллектив шуларның барысын да җиңеп, үзенә һәм тамашачысына бәйрәм бүләк итә алды. Ә күңелдә юшкын калды.

Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле матбугат үзәге

Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле һәрвакыт юлда. Быел гына да алар 125 җирдә концерт куйган, ансамбльнең автобусы 30 мең чакрым юл үткән. Барлык юлларны, булган илләрне дә кертеп санасаң, Җир шарын әйләнеп чыгарга да күп калмаган икән.

Ә менә Казан тамашачысы аны бик тансыкка гына, гадәттә юбилей елларында зур сәхнәдә күрә. Быел 85 еллыкларын үзләренә тиң сәхнәдә – Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында билгеләп үттеләр. Концертны үзенчәлекле итеп оештырганнар. Башланганда ук ансамбльнең сәнгать җитәкчесе Айрат Хәмитов залда ветераннар утырганлыгын искәртте һәм аларга «сез булмасагыз, без булмас идек» дигән сүзләр белән рәхмәтен җиткерде. Ветераннарны сәхнәдә дә күреп булды. Мәсәлән, Татарстанның халык артисты Рәшит Мостафин Айрат Хәйруллин, Марсель Вахитов белән бергәләп «Арча»ны уйнады. Гармунчыларның бу номеры алкышларга, рәхмәт сүзләренә күмелде. Менә кайда ул энергетика! Менә кайда ул буыннар алмашына матур үрнәк! Хәер, буыннар алмашы димәктән, бәйрәмдә күп кенә чыгышларда ансамбль каршында эшләп килүче балалар вокал-хореография студиясе дә катнашты. Алар арасында иң матуры – «Гармун-гармун» композициясе булгандыр, мөгаен. Зур артистларның һәр хәрәкәтен балалар кабатлагач, күпләрнең күңелендә өмет уянгандыр. Һәрхәлдә, тиеш иде. Әмма бу кичәдә өмет белән беррәттән, башка хис тә уянды. Әллә ачу ул шунда, әллә оялу, белмәссең.

Кадерле кадерсезләр

Без аларны белмибез икән. «Бөркет турында баллада» башкарган Айдар Мөхәммәтгалиевне дә, «Казаннарда тайлар» белән уйландырган Фәрит Гафиятуллинны да, «Рәйхан»ны акапелла башкарып, аксакал Шамил Әхмәтҗановны рәхмәт әйтергә сәхнәгә күтәрелергә мәҗбүр иткән, залны аягүрә бастырган Фәнил Фәйзуллинны да белеп бетермибез. Нәфисә Назарова, Диләрә Палатова, Зоя Борисова, Илнар Каюмов, Илнур Нуриев та тамашачы игътибарына иркәләнгән җырчылар түгел. Аларны халыкка танытуның юлы бик гади юкса: аз гына радиодан ишетелсәләр, телевидениедән күренсәләр, ансамбльнең социаль челтәрләренә чыгышларын, һич булмаса өзекләрен элсәләр, белерләр иде үзләрен. Күкрәп торган тавыш, чын музыка, үзебезнең моң әллә тәэсир итми дип уйлыйлармы икән? Ай-һай, ялгышалар! Тавышы булмаганга акырып җырлаучылар түйдырды бит инде. Чыксын инде мәйданга чын тавышлар, чын сәнгать!

> Ансамбльне болай да беләләр, дип уйлаучылар чын күңелдән ялгыша. Аны фольклор музыкасы ансамбле белән дә, Тәминдарова хоры белән дә рәхәтләндерәп бутыйлар. Ә бит бу коллективта күпме шәхес тәрбияләнгән! Әлфия Авзалова, Таһир Якупов, Нәфисә Васыйлова, Ания Туишева исемнәрен атасак та, мөгаен, җитәдер. Алар – халык күңелендә мәңге онытылмаслык урын биләгән җырчылар. Таныганнар бит аларны, йөргәннәр бит аларга, нишләп ансамбльнең хәзерге башкаручыларын Татарстанның визит карточкасы итмәскә?

Кошка сайрар өчен ботак кирәк дигәндәй, ансамбльгә үз эшчәнлеген тулы куәтенә җәелдерергә сәхнә җитми. Татарстанның халык артисты Шамил Әхмәтҗанов аларны юкка гына оясыз кошлар дип атамый:

– 1937 елда оешкан ансамбльнең Татарстан өчен башкарган эше бәяләп бетергесез. Шуңа аларны, кадерлеләр, дип әйтәләр. Ә мин аларны, кадерле кадерсезләр, дим. 85 ел сәхнәсез яшәтеп кара әле син солистлары һәм, хореография төркемен генә алсаң да, 100дән артык кешесе булган коллективны! Оясыз кошлар, чит ояга йомырка салып йөрүче күкеләр алар. Мин әллә оныттылармы икән аларны, дип тә уйлыйм. Ник дигәндә, министрлык вәкиле сәхнәдән 75 еллык юбилей белән котлап китте. Ярый инде Президент исеменнән берничә солистка атказанган исеме бирделәр. Хәер, ул исем хәзер кемнәрдә генә юк инде... Кадерсез бер нәрсәгә әйләнде. Ә аннары профсоюз бүләкләрен бирделәр. Күрәсең, ансамбльгә мөнәсәбәт шул дәрәҗәдә.

Бүләксез туган көн

Туган көнгә матур күлмәк тектерү гадәти булырга тиеш бит инде. Ә менә ансамбльнең 85 еллыгына бер генә дә яңа костюм тегелмәгән. Яңа хореографик әсәр дә куелмаган. Болар барысы да финансламау аркасында. Уйлап карасаң, безнең дөнья төрле-төрле параллельләрдән тора кебек. Менә супер зиннәтле «Татар кызы» бәйгесе үтә. Аннары 18 миллион сумлык бюджетлы «Татар җыры» көтелә. Оештыручылар булдырганнар, афәрин, ә менә ансамбль нишләптер булдыра алмаган. Чөнки алар коммерция юлына баса алмый, аларга ярдәм кирәк. Бу җәһәттән коллективның баш балетмейстеры Раилә Гарипова авыр заманда финанс ярдәме сорау да оят дигән фикердә:

– Без бүген фондтагы иң көчле композицияләрне күрсәттек. Болар – «Туй» дигән программадан өзекләр, себерчә бию, «Тезмә», «Яз килде», «Гармун-гармун» һәм башкалар. Кубесенә үзебез тәрбияләгән балаларны керттек. Алар – безнең өметебез, киләчәгебез. Безгә – 85 яшь, без бик күп йөрибез. Әйтик, менә бүген генә Мәскәүдән кайттык, кичен Казан тамашачысына концерт куябыз. Гомеребез гастрольләрдә уза. Шуңа да яңа биюләр чыгара алмадык, костюмнар тегәргә өлгермәдек. Хәзер инде финанслау белән тоткарланып торабыз. Яшерен-батырын түгел, вазгыять катлаулы, сорарга да оялабыз. Ә болай, 4–5 яңа биюебез бар.

Сәхнә турында сүз чыккач, баш балетмейстер ни дип җавап бирергә белмәде:

– Һич югы опера театры сәхнәсен ешрак бирсәләр дә, бик риза булыр идек. Чыгышлар нинди соклангыч бит. Безнең ансамбльгә шушы сәхнә генә килешә, башкаларга сыеша алмыйбыз без. Моннан берничә ел элек Камал театрында «Туй» программасын күрсәттек. Ул сәхнәне дә яратабыз. Әлбәттә, ул кечерәк, ләкин...

Камал театры сәхнәсе дигәннән. Менә алар яңа йортка күченәчәк бит инде. Ә нигә әлеге бинаны безнең оясыз кошларыбызга бирмәскә? Бүген яшьләргә мәйдан һәм игътибар юк дип әйтергә тел әйләнми. Бәлки тәҗрибәләрдән туктап торып, нигезне кайгыртырга да вакыт җиткәндер? Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле – нигез ул.

Мәскәүчә Гөлҗамал

Концерт ахырында сәхнәгә «Беренче канал»ның «Голос» проекты җиңүчесе Динә Гарипова чыкты. Ул татар халык җыры «Гөлҗамал»ны башкарды, әлбәттә, хор көчәйтеп, ярдәм итеп торды. Җырчы чыгышыннан соң: «Талантыгыз һәм ярдәмчеллегегез өчен рәхмәт сезгә! Мин инде ничә ел татар альбомын әзерлим, сез – бу эштә тугры дусларым», – дип рәхмәтен җиткерде. Бик матур чыгыш булды. Ул хәттә башка чыгышлардан аерыла иде. Тавыш һәм яңгыраш җәһәтеннән әйтүем. Ансамбльнең һәр чыгышы шундый яхшы сыйфатлы аранжировкага лаек юкса.

Мин бу ансамбльне бик яратам. Җанлы музыка җанны дәвалый дип тикмәгә әйтмиләр бит, алар әнә шундый үзлеккә дә ия. Ләкин аларны карау биш елдан биш елга гына эләгә. Юбилей елларында. Дөрес, 16 декабрьдә «Әкият» курчак театры бинасында чыгыш ясыйсылары бар. Раилә Гарипова моны сөенеп әйтте. Мин көенеп кабул иттем. Зур мөнбәрләргә лаек коллектив лабаса сез!

Фикер

Рамил ТӨХВӘТУЛЛИН, Татарстан Дәүләт Советы депутаты:
– Дәүләт ансамбленең язмышы белән даими кызыксынам, аларның бина мәсьәләсен комитет утырышында да күтәрдем, үзләре белән очрашуда да булдым. Белүемчә, әлеге бинаны ремонтларга дигән карар чыгарылган. Игътибар җәлеп ителәр, ә бу – иң мөһиме, тора-бара башка мәсьәләләр дә хәл ителер дип уйлыйм. Ансамбльгә, мәсьәләне хәл итүнең тагын бер юлы булярак, башка биналар да карала. Минемчә, боз кузгалды.

Салават ФӘТХЕТДИНОВ, Татарстанның һәм Башкортстанның халык, Россиянең атказанган артисты, Казан дәүләт мәдәният институты профессоры:
– Татарстан урамы, 1 йортта Камал театры яңа бинага күченеп киткән очракта, әлеге бинада Татарстан дәүләт ансамблен күрәм. Безнең йөзек кашы дип сөйләп йөрибез икән инде, коллективны статусына лаеклы биналы итү дә кирәк. Икенче вариант – Татар дәүләт филармониясе. Алар бергә көченсә, филармония бинасына ансамбль урнаша ала. Өченче вариант юк, булырга да мөмкин түгел.

Бу әсәрне мин бик күптән – теге заманда, 1956 елда ук яза башлаган идем. Иң әүвәл уйланылганча, ул вакытта мин бөтен дөньяны таң калдырырга тиеш булган киң күләмле, тирән эчтәлекле роман-эпопея иҗат итәргә тиеш идем. Роман-эпопея кимендә дүрт кисәктән торырга һәм сугыштан соңгы еллардагы татар тормышын чагылдырырга тиеш иде. Мин тормышны әз генә дә бозмыйча, бизәмичә күрсәтергә, һәрнәрсәдә, аеруча халык тормышын һәм милли мөнәсәбәтләрне тасвирлаганда дөреслекне ярып салырга тиеш идем.

Роман баштарак «Таяныч» дип, соңга таба беркадәр китапчарак «Хыял вә хәят» дип аталды. Әлеге исемнәрдән үк күренеп торганча, өстебезгә бик авыр йөк алмакчы идек без. Ләкин нихәл итмәк кирәк, чынбарлык хәтта хыялдан да көчлерәк булып чыкты. «Хыял вә хәят»не 1963 елга кадәр яздым да, ары дәвам итәргә куәтем җитмичә, туктап калдым. Ул елларда бар нәрсәне буып торган милли террор һәм рәхимсез мохтаҗлык әсәремне тиешенчә очлап чыгарга ирек бирмәде дисәм, мондый сүзләр хәзер аклану булып аңлашылмас дип уйлыйм. Чөнки дөресе шулай.

Утыз елдан артык вакыт үткәч, элекке кулъязмаларны яңадан карап чыктым һәм романның беренче кисәген укучыга тәкъдим итәргә ярый дигән фикергә килдем. Бүген инде аны, әлбәттә, элекке хәлендә калдыра алмадым – беркадәр үзгәрттем, тулыландырдым һәм зур әсәрнең бер кисәге итеп түгел, бәлки, аерым роман итеп эшләргә тырыштым. Романның күләме дә, колачы да башта уйланылганга караганда шактый кысыла төште. Шуңа күрә аның исеме дә тарайды һәм конкретлашты. Берничә кисәктән торган «эпопея»ны хәзер яшьлеккә хас бер хыял итеп кенә искә төшерергә туры килә. Шулай да, «Хыял вә хәят»тән үсеп, бүленеп чыккан шушы кыйпылчыкта күпмедер дәрәҗәдә безнең яшьлек еллары чагылыш таба алган булса, анысы өчен дә мин үземне чиксез бәхетле санар идем.

Август, 1990, Казан

НУРИХАН ФӘТТАХ

КИЧҮ

(РОМАННАН ӨЗЕК)

Яңавыл татар урта мәктәбе укучыларының күбесе кебек, Габделхәй дә үзләренең директорын яратып җиткермәде. Ни өчен яратмаганлыгын ул, күрәсең, үзе дә тиешенчә аңлатып бирә алмас иде. Василий Михайловичны күрдеме, шундук анда нидәндер куркү, сагаю һәм үз-үзен якларга әзер булу тойгысы барлыкка килде. Менә әле дә, каршысында директорны күргәч, ул, ниндидер ярамаган эш өстендә тотылган кебек, куркуга якын бер тынычсызлык кичерде.

– Исәнмесез, Василий Михайлович! – диде ул, беренче булып, ясалма бер күтәренкелек белән.

Василий Михайлович та елмайгандай итте, парта арасыннан чыгып үзенә таба атлаган укучысына беренче булып кул бирде.

– А-а, Мухутдинов! Исәнмесез, исәнмесез, – диде.

Мондый көтелмәгән хәлдән Габделхәй тәмам каушап калды, кабаланып, ике куллап директорның сөякчел каты кулын тотып алды.

– Исәнмесез, Василий Михайлович! – диде, тагын да ялагайланып. – Күптән кайттыгызмы, Василий Михайлович? Без сезне көттек!

– Көткәнсездер – беләм, – диде директор.

Шулай диде дә нидер өстәмәкче булды, ләкин вакытында тыелып калды. Габделхәй аның ниндидер кирәкле сүз әйтергә укталып та әйтми калуын бик яхшы аңлады. Ул хәтта директорның нәрсә әйтергә тиешлеген дә белде. Бу, әлбәттә, "аттестат" булырга тиеш иде. Имтиханнарның барысын да Габделхәй «бишле»гә бирде. Уфага да документлар гел «бишле» белән китте. Василий Михайлович Габделхәйгә аттестат кына түгел, алтын медаль дә алып кайтырга тиеш иде. Бу хакта әллә ни шауламадылар, ләкин унынчылар да, укытучылар да, Габделхәй кебек үк, директорның алтын медаль белән кайтуын көттеләр. Яңавыл татар урта мәктәбеннән әле беркемнең дә алтын медаль алганы юк иде. Дөрес, моңарчы аның алтын медальгә торырлык укучысы булмады. Быел менә андый укучы бар. Ул да булса Габделхәй. Бар өмет Габделхәйдә. Алтын медаль ул Габделхәйнең үзе өчен генә түгел, бөтен мәктәп өчен, барлык укытучылар коллективы өчен үзе бер бәйрәм булыр иде. Мәктәпнең дәрәҗәсе бермә-бер артыр иде.

Әйе, Василий Михайлович кайткан, әнә ул каршыда гына, якында гына басып тора, ләкин аның йөзеннән дә, сүзләреннән дә нишләптер бернинди куаныч тәэсире сизелми. Габделхәй моны бөтен күңеле белән тойды. Имтиханнарны тапшырып бетергәннән соң, Василий Михайлович документларны алып киткәннән соң төн йокыларын калдырган татлы хыяллар, бәхет, дан – барысы да кинәт юкка чыкты. Аның урынына күңелдә шыксыз, борчулы бушлык хасил булды.

Шулай итеп, директор әйтәсе сүзен әйтмәде, Габделхәйнең исә сорарга йөрәге җитмәде. Василий Михайлович партадагы дәфтәргә күз төшереп алды.

– Сез һаман шигырь язасыз икән, – диде ул.

– Язган булам шунда, Василий Михайлович, – диде Габделхәй, бөтенләй чит нәрсә турында сөйләнгән кебек. – Ошамый әле. Кичкә өлгертергә кирәк.

– М-да, – диде директор, берни аңлатмый торган бер мөңгерәү белән. – Кирәк дисез инде?..

Аттестат, медаль турында сүз кузгату урынсыз булган кебек, хәзер менә шигырь турында да сүз куерту урынсыз иканлеген сизеп, Габделхәй сүзне тизрәк икенчегә борырга ашыкты.

– Бер-ике атна эчендә сез бик үзгәргәнсез, Василий Михайлович. Юлда йөрү килешкән сезгә, – диде ул, кирәгеннән артык кыюланып, ярарга тырышып.

– М-да, Мухутдинов, – диде тагын да директор. – Шигырь шигырь инде ул. Но, однако, сезгә бүген шигырь белән генә ярамый. Выпускной кичәрдә бүген Сафин иптәш тә булачак.

– Шулаймыни?! – диде Габделхәй. – Без бит аңа делегация белән барганыек. Безне аның янына кертмәделәр. Әйттергән, киләлмим, вакытым юк, дигән.

– Делегация оештыруыгыз дөрес булмаган, Мухутдинов, – диде Василий Михайлович, ярым шелтә белән. – Но, однако, Мунавир Мухлисович киләчәк. Мин үзем сөйләштем аның белән. Үзем.

– Шәп булган, Василий Михайлович! – диде Габделхәй, куанып.

– Шәбен шәп тә, ул анда сезнең шигырегезгә тыңлар өчен килмәячәк, – диде Василий Михайлович. – Выступление әзерләргә кирәк. И непременно урысча. Политически выдержанный. Йөзгә кызыллык китерерлек булмасын.

Мунавир Мухлисович райкомның беренче секретаре иде. Аның чыгарылыш кичәсенә килергә ризалык бирүе бик зур яңалык, бик зур шатлык иде, әлбәттә. Чыннан да, ул килә-нитә калса, барлык унынчылар өчен, бөтен мәктәп өчен бу чиксез зур дәрәҗә һәм тантана була иде. Мунавир Мухлисовичның хатыны Галия апа яисә Галя Гатовна элегрәк Яңавыл татар урта мәктәбендә башлангыч классларда укытучы булган. Аны монда әле дә беләләр. Ләкин ире беренче секретарь булгач та, Галия апа балалар укытуын ташлаган һәм хәзер өйдә генә ята, беркайда эшләми бугай. Хатыны укытучы, үзе икенче секретарь чагында иптәш Сафин да мәктәпкә еш килгән. Беренче булгач менә килми башлаган. Бит алар, өстәгеләр беркайчан астагылар, түбәндәгеләр белән буталмаска һәм һәрвакыт саф һәм дәрәҗәле килеш калырга тырышалар. Быел әнә килмәкче була икән. Ник? Бәлки, Василий Михайлович алтын медаль алып кайткандыр да медальне дә, аттестатны да беренче секретарь алдында бирергә җыенадыр? Бик астыртын кеше инде ул Василий Михайлович. Хәзер әнә берни сиздермәгән булып кылана. Анысы ярый, ләкин нишләп «выступление»не урысча әзерләргә куша соң ул? Беренче секретарь – татар, хатыны – татар, кунаклар – татар, укытучылардан Антонина Семеновна да, немец теле укытучысы гына – урыслар.

– Ләкин ни бит, Василий Михайлович... – диде Габделхәй, нәрсәдер каршы әйтергә җыенып.

– Никаких «ни»! – диде Василий Михайлович, кырт кисеп. – Әйтелгән – эшләгез!

Ялтыратылган күн итекләре белән шыгырт-шыгырт басып, директор ишеккә таба атлады. Тагып куйган кебек, Габделхәй аның артыннан иярде.

– Язып бетергәч тә минем янга керегез, – диде Василий Михайлович коридорга чыккач, ләкин шундук фикерен үзгәртте дә: – Впрочем, хәзер үк керегез. Бер биш кенә минутка, – диде.

Үзара сөйләшкәндә директор «Василий Михайлович» булса да, чынлыкта ул урыс та, керәшен дә яки анда чуаш та, мари да түгел иде. Ул чеп-чи татар иде. Аның чын исеме – Вәсби, атасының Муллахан иде, фамилиясе бик борынгыдан килә торган Суяргуллар затыннан иде. Шул борынгыдан килә торган Суяргуллар затыннан булган Муллахан карт кайдадыр Борай ягында гомере буена җир тырнап иген иккән, мал-туар асраган ярлы гына, кара гына бер кеше булган. Күрәсең, атасы шундый кара игенче булганга, улы Вәсби шундый ак кеше булырга тырышкандыр да инде. Исемен бозып, урысчалатып әйткәнгә ул әз генә дә үпкәләми, ачуланмый да. Киресенчә, болай әйтү аның дәрәҗәсен генә күтәреп җибәрә сыман иде. Үзенең яңа исеменә ул шул дәрәҗәдә күнегеп беткән иде, әгәр дә мәгәр берәр укучы «Василий Михайлович» димичә, «Вәсби абый» яки анда «Вәсби Муллаханович» дисә, директор абый, артык кызмыйча гына, шулай да җаңга тия торган итеп, сеңдереп кыздырырга тотына торган иде.

Дәвамы бар >

КОТЛЫЙБЫЗ!

Мәгариф системасын үстерүдәге казанышлары һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе өчен «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең очу аппаратлары производствосы кафедрасы мөдире **Халиулин** Валентин Илдар улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты Милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе баш киңәшчесе **Шакирова** Гүзәл Риф кызы, Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе коррупциягә каршы тикшерүләр бүлеге мөдире **Шрша** Равия Бәдретдин кызы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы хезмәткәрләре: мәгълүмат куркынычсызлыгы бүлеге әйдәүче белгече **Воронкова** Наталья Васильевна, бюджет өлкәсе тармакларында бюджет сәясәте бүлеге әйдәүче белгече **Гыйбадуллина** Нэля Шамил кызы, бюджет өлкәсе тармакларында бюджет сәясәте бүлеге әйдәүче белгече **Исламова** Эльмира Булат кызы, идарә аппаратының финанслау бүлеге башлыгы урынбасары **Кондрева** Ирина Владимировна, икътисад тармакларын финанслау бүлеге әйдәүче белгече **Миндубаева** Нурия Равил кызы, икътисадый анализ бүлеге әйдәүче консультанты **Шәйхетдинова** Клара Шамил кызы; «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең автоматика һәм идарә кафедрасы профессоры **Дегтярев** Геннадий Лукич, «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең гомуми физика кафедрасы мөдире **Тимеркәев** Борис Ахун улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең җылылык техникасы һәм энергетика машиналары төзү кафедрасы профессоры **Алтунин** Виталий Алексеевичка **«Татарстан Республикасының атказанган уйлап табучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Зеленодольск проект-конструкторлык бюросы» акционер җәмгыяте генераль директорының икътисад һәм финанслар буенча урынбасары **Григорьева** Елена Геннадьевнага, «Казанның 1 номерлы пассажир автотранспорты предприятиесе» акционер җәмгыяте генераль директорының икътисад һәм финанслар буенча урынбасары – баш бухгалтеры **Нурисламова** Лилия Газәлҗан кызына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Азнакай районы һәм Азнакай шәһәре территориаль бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары **Сәмигуллина** Зөлфия Хәтим кызына, Татарстан Республикасы Конституция судының финанс-икътисад бүлеге башлыгы **Сафиуллина** Эльмира Хәмзә кызына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Икътисадый анализ һәм фаразлау идарәсе башлыгы **Хәбибуллина** Гүзәл Мөнип кызына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Казан шәһәре территориаль бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары **Чикурина** Надежда Владимировнага, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе 2 номерлы камераль контроль бүлеге башлыгы урынбасары **Хисмәтуллина** Альмира Ваяс кызына; Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе 24 номерлы бүлеге башлыгы **Якимова** Любовь Петровнага **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Белдерү

ҖИТӘКЧЕ ХАЛЫКНЫ КАБУЛ ИТӘ

21 декабрь көнне Татарстан Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына дәүләт күзәтчелеге (Гостехнадзор) Казан бүлегендә халыкны күчмә кабул итү оештырыла. Кабул итү вакыты – **9.00** сәгатьтән **12.00** сәгатькә кадәр.

Чараны Гостехнадзорның Татарстандагы идарәсе башлыгы – Татарстан Республикасы Гостехнадзорның баш дәүләт инженер-инспекторы Борһанов Альберт Шамил улы үткәрә.

Белешмәләр алу өчен телефон:
8 (843) 221-77-85.

Кабул итү түбәндәге адрес буенча булачак: **Казан ш., Спорт ур., 33 й.**

БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1 **ЯЗЫЛ!**
2023 елның беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына язул

2 **КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!**

89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 **БҮЛӘККӘ**
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.

П2435
җомга саны
512 сум 70 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
1143 сум 96 тиен

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 2023 елның 20 гыйнварына кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru

16+

реклама



Әз-мәз мәзәк

– Синең тёщаңа нәрсә булды ул?
– Сыер тибеп үтерде.
– Ә бу халык аны озатырга җыелдымы?
– Юк, сыер сатып алырга килгәннәр.

* * *

– Без күпфункцияле режимда эшлибез.
– «Бардак» сүзенә матур алмаш тапкан сез.

* * *

– Әгәр дә кем дә булса борчыла һәм курка икән, ул тизрәк тынычлансын өчен, мин аңа кычкыра башлыйм. Мине әти-әнием шулай өйрәтте.

* * *

– Сез кем булып эшлисез?
– Мин – политолог.
– Сез сәясәтне аңларга ярдәм итәсезме?
– Юк, мин аның белән акча эшлим.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Яшкин, сарымсак, Ошо, Луи, алпавыт, март, угры, рагу, фа, ал, Онегин, ятак, ияр, окулист, чыра, го, сирәк, башлам, Си, Сәрия, иләк, без, атом, син, кәттә, шатлану, әр, Ясминә, Низамов.

Вертикаль: уфолог, аршын, карлыган, кобальт, остаз, сыра, ыргылыш, Камил, Наум, аслы, Ниссан, аут, ятим, Уяв, яки, яр, Марат, чәчәк, бәрмә, Кола, алачык, иш, Сикертән, ноутбук, Талия, әрәм.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Ай-ли, замана!

- Узып баручы ел – үз эченә иң күп икелене сыйдырган ел.
- Мәгариф өлкәсе алга бара: метрода хәзер хәтта онлайн укыту дипломнарын саталар.
- Социаль лифтка утырган идем, ниндидер сәрхушләр белән беренче катта ватылып калдым.
- Кайвакыт, кыек юл белән киттем, ахры, дип, артка борылып карыйсың: юк, тигез юл.
- Һәр класста икенче елга калсагыз, армиягә алмаячаклар.
- 100 процентка ышандырган кешеләр кайвакыт 200 процентка алдый.
- Кайберәүләрнең тормышны яхшырту өчен эшләгән иң зур эшләре – бокал күтәреп, тост әйтү.
- 30 яшьтән соң будильник кирәкми, проблемалар сине үзләре уятачак.
- Аның каравы былтыргы дөнья чемпионатында Россия футбол җыелмасы бер генә уенны да оттырмады!

Беләсең килсә...

1 Җырчы Алсу Әбелханова ике көн элек ничә яшь тулды?
а) 44;
б) 45;
в) 46.

2 «Полундра» сүзе нәрсәне аңлата?
а) суыклар килү турында кисәтү;
б) куркыныч хәл турында кисәтү;
в) нәрсәнеңдер икегә бүленүе.

3 Бу шәһәрне икенче төрле Крестоград дип атыйлар.
а) Ставрополь;
б) Севастополь;
в) Симферополь.

4 Менделеев уйлап тапкан системада 1 нче урында нинди химик элемент тора?
а) азот;
б) водород;
в) йод.

1. в); 2. б); 3. а); 4. б).

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15344 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 386

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+